PRESSA.RU

1926–1991 елларда АЗАТ ХАТЫН



2018 ФЕВРАЛЬ № 2

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398



БИЛДӘ – КАЕШ
ватанны саклау кем эше

АЛАР БУЙСЫНГАННЫ ЯРАТА
иргә ярау серләре

ЛӘЙСӘН ФӘЙЗУЛЛИНА СЫЙЛЫЙ
рибай

Килендәшләр Гөлфия белән Рәшидә:

ТУГАННАР ТАТУЛЫГЫ БАЙЛЫКТАН АРТЫК...

PRESSA.RU

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Минем өчен син һаман да 17 дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә...
...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Роберт МИҢНУЛЛИН

ТӨНГЕ УРАМДА

К-га

Төнге урам.
Учларыңа ак кар ява.
Тып-тын гына
Вак кар ява.

Тәрәзәләр бездән микән
Оялалар:
Кинәт кенә йә сүнәләр,
Йә яналар.

Артыбызда ап-ак булып
Эзләр кала.
Безгә елмаеп караган
Йөзләр кала.
«Нинди бәхетле пар!» дигән
Сүзләр кала.

Алда тормыш,
Алда шатлык
Әллә күпме...
Йолдызларның берсе әнә
Җирне үпте!

Рәсемдә: шагыйрьнең
хатыны Клара. 1967 ел.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2018

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



2’2018

Фото: Газинур Хафизов

Җитәкче-баш мөхәррир
Гөлнара Ильяс кызы САБИРОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Рәшидә һәм Гөлфия Әгъләмовалар
Фото: Юлия Сажнева

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Фәнзилә Мостафина
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Равил Газизов

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 31.01.2018 ел.
Заказ Е-211.
Тираж 5416.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77


Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



PRESSA.RU





Нурия ИЗМАЙЛОВА

Зәңгәр кар киче

Шундый хозур, шундый зәңгәр бу кич!
Мин дә зәңгәр микән бу мәлдә?
Ак карлар да, җиргә төшкәч, түзми –
Әверелеп китә зәңгәргә.

Азмы миндә моңсу, ямьсез төсләр! –
Бер көнемдә генә мең төс бар.
Бар да чума йомшак зәңгәрлеккә –
Бар дөньямны күмә керсез кар.

Зәңгәр таулар булганмындыр инде –
Әкиятләр чынга ашканнар! –
Зәңгәр кошлар оча күзләремнән,
Зәңгәр гөлләр чыккан ак кардан...
Күңел тәрәзәм зәңгәр генә бугай –
Бүтәннәрен кошлар ватканнар.







Фото: Газинур Хафизов

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

* * *

Кар көртләре кыйгач-кыйгач,
Күренми дә авылым.
Көртләргә күмәсе килә
Кайчак җанның давылын.
Кар көртләре кыйгач-кыйгач,
Әле – тау, әле – упкын.
Күңелдә – кыш, җанда – буран,
Җанымда – җылы дулкын!

Бәйрәм

Табигатьтә бүген бәйрәм –
Ак күлмәкләр бәйрәме.
Тын һавада, парлап-парлап,
Энҗе карлар әйләнә.
Бер сыгыла, бер бөгелә
Чыршыларның керфеге.
Мең төскә кереп җемелди
Ак карның һәр бөртеге.
Ак дөньяның бизәгеннән
Күзләр ничек камаша!
Җанга ята ак наз булып
Илаһи бу тамаша.
Табигатьтә бүген бәйрәм,
Аклык та, сафлык кына.
Бар дөньяга аклык иңә –
Җаннарга шатлык куна.

PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА



20 СЕБЕР ҮЗЕБЕЗНЕКЕ
Гөлнур Сафиуллина

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



6 АКЧАЛЫ БӘБИЛӘР
Мәдинә Авзалова





12 «БЕЗНЕ ТЕАТР КОТКАРАЧАК!»
Раил Садриев



10 НЕЧКӘ БИЛДӘ – СОЛДАТ КАЕШЫ
Ландыш Әбүдәрова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





24 КЫШКАР ЙОЛДЫЗЫ
Лилия Гәрәева

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ




28 ЛИЛИЯ – ГӨЛНЕҢ ЧӘЧӘГЕ
Эльмира Закирова

ЯШӘЕШ




38 «АЕРЫЛМАГЫЗ!» – БЕЗНЕҢ ҖЫР
Зөлфия Афзалова-Нигъмәтҗанова



46 ИКЕ ТӨРЛЕ СЕРБИЯ
Альбина Хәкимуллина

ШУЛАЙ УК:


34 ЯРАТУДАН АЛДАШУ
Фирүзә Җамалетдинова

40 ҮГИ АНА ОЯСЫ
Люция Фаршатова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ




60 АЛ ЯРАН, КЫЗЫЛ ЯРАН...

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА:

ТОРМЫШ КЫЙММӘТЛӘРЕ. САИМӘ ИБРАҺИМОВА.


БӘЙЛӘНҮМЕ, ӘЛЛӘ ГАП-ГАДИ ИГЪТИБАРМЫ? ФИКЕР.

«ЮЛДАШЛАР» ГӨЛҮСӘ ЗАКИРОВА. ХИКӘЯ.

БОЗ ҺӘМ... УТ ИЛЕ. МИН АЧКАН ДӨНЬЯ.



PRESSA.RU



РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ ДЕМОГРАФИК ПРОГРАММАСЫ НИГЕЗЕНДӘ БАЛАЛЫ ГАИЛӘЛӘРГӘ ЯРДӘМ КҮРСӘТҮНЕҢ ЯҢА ТӨРЛӘРЕ ЭШЛИ БАШЛАДЫ.

Фото: www.pixabay

АКЧАЛЫ БӘБИЛӘР

Мәдинә АВЗАЛОВА

Хәер, эшләр күптән шуңа бара иде инде. Илдәге демографик хәлне көйләү өчен берсеннән-берсе саллырак, җитдирәк нинди генә чаралар кулланмыйк, вазгыять барыбер безнең файдага эшләми. Балалар туу, инде уңай якка үзгәрде дип, куанырга да өлгермибез, саннар тагын түбәнгә тәгәри, үлем-китемнәр бераз кими башласа да, монда да тынычланырга иртәрәк әле. Югыйсә шаукымы бүгенгәчә озата килгән Бөек Ватан сугышы да, 90 нчы еллар да сәбәпче түгел моңа. Демографик кризисның алда торган иң кискен проблемаларның берсе булуын 2003 елны илбашы да үзенең юлламасында әйтеп үткән иде. Ул чагында кризистан чыгуның мөһим юнәлеше итеп халык сәламәтлеген ныгыту, наркоманиягә һәм сукбайлыкка каршы көрәш күрсәтелде. Билгеле инде, әлеге чаралар белән генә балалар санын арттырып булмый. Тагын өч елдан демографик проблеманы уңай хәл итүнең төп юнәлешләре тәгаенләнде: гаиләләрнең матди хәлен һәм торак шартларын яхшырту, өйдә бала белән утыручы әниләргә пособиеләрне арттыру, икенче бала тудыруга кызыксындыру чараларын табу, ягъни ана капиталы түли башлау. 2006 елдан икенче баласын тапкан әниләргә 250 мең сум күләмендә акча бирелә

башлады. Аны ипотека буенча торак йорт сатып алганда беренче кертемне түләүгә, балага белем бирүгә тотарга яки әни пенсиясенең тупланма өлешенә күчерергә була иде. Хәтерегездә булса, Россия Президенты Указы белән, ана капиталы эшли башлауның икенче елында ук, 2025 елга кадәрге чорга илнең Демографик сәясәт концепциясе дә расланган иде. Шунда ук икенче, өченче балалары туган гаиләләргә өстәмә ярдәм турында да билгеләп үтелгән иде. Болары – үткәнебез. Кеше кадерен белүгә, балалы гаиләләр хәлен яхшыртуга юнәлтелгән чараларның күңелгә өмет салырдай әйбәт кенә нәтиҗәләр бирүе, дөрес юлдан баруыбызны раслады. Димәк, моннан унбер ел элек кабул ителгән законнар бүген дә уңышлы эшли. Шулай булгач, халык санын арттыруга таба алган юлыбызны нигә әле бүген дә дәвам итмәскә? Илбашының яңа демографик программасы нәкъ менә шуны күздә тота да бит.

Яңалык ачарга җыенмыйм. Бу сүзләрне озын-озак еллар дәвамында кабатлап килдек. Ә менә мәгънәсенә әле генә төшендек бугай. Чөнки җимергеч тәэсире булган демографик проблемага болай җитди караганыбыз юк иде әле. Башыңа төшсә, белерсең дә... Бер уйласаң, бу кризистан котылу юлларын эзләмәдек түгел, эзләдек. Ул берара әйбәт кенә нәтиҗәләр дә бирә башлаган иде. Кызганыч, хәл янә киеренке. Алдагы ун елда халык саны кимергә тиеш түгел. Илбашы шулай дип белдерде. «Балачак унъеллыгы»ның игълан ителүе дә тикмәгә булмады. Димәк, яшь әниләр алдында дәүләт күләмендәге зур бурычлар тора. Тапсыннар гына әниләр, ә дәүләт аларны ташламас. Күп балалы һәм керемнәре аз булган гаиләләргә ярдәм, икенче һәм өченче бала табу өчен өстәмә кызыксындыру чаралары турында бара сүзебез. Матди мөмкинлеге булмау сәбәпле, бала табуны кичектереп торган яшь гаиләләргә дә кагыла бу. Нинди алар? Кемгә һәм ничек кагыла? Алты өлештән торган яңа демографик программаның эчтәлеге нидән гыйбарәт?

1 «Ана капиталы»н – 2022 елга чаклы

Икенче баласын табарга җыенган әниләргә Яңа елның иң зур бүләге ул. Ә бит бу программа быелның ахырына тәмамланырга тиеш иде. Бүгенге көндә ана капиталының күләме 453026 сум тәшкил итә. Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан бүлеге идарәчесе урынбасары Асия Вәлиуллинаның әйтүенә караганда, былтыр мондый шәп мөмкинлектән 243 мең гаилә файдаланган. Хәзер ул капиталны куллану мөмкинлекләре дә киңәйде.

– 2018 елда туган икенче балага яисә тәрбиягә алган икенче балага, ул 1,5 яшькә җиткәнче, ана капиталы исәбеннән 8490 сум күләмендә айлык түләү кертелде, – ди идарә җитәкчесе урынбасары. – Кирәксенсә, әни кеше түләүләрне туктата һәм калган акчасын башка максатка да файдалана ала.

Ләкин капиталны өлешләп алырга теләгән бөтен әниләргә дә рөхсәт ителми. Ә матди авырлык кичергән, акчага тилмереп яшәгән гаиләләргә генә... Тагын бер мөһим нәрсәне исегезгә төшерәбез: түләүләр ай саен кредит учреждениесендә ачылган шәхси счетка күчерелеп барылачак. Ә пособие бер елга билгеләнәчәк. Аннан соң әни кеше аны балага 1,5 яшь булганчыга кадәр озайта ала. Моның өчен янә яшәгән урындагы социаль яклау органнарына түбәндәге документлар тапшырылырга тиеш: туу турында яки тәрбиягә алу турында таныклык; гаиләнең 12 айлык кереме турында мәгълүмат; банкта ачылган счет реквизитлары һәм, әлбәттә инде, гариза бирүченең паспорты. Шунысын да онытмагыз: түләүләр хакында бала туганнан соң алты айга кадәр мөрәҗәгать итсәгез, пособие бала туган көннән башлап бирелә. Әгәр инде алты ай үткәч килсәгез, түләүләрне мөрәҗәгать иткән көннән ала башлыйсыз. Ә алдагы айлар өчен түләнми.

Балалар тагын да күбрәк тусын, яхшырак яшәсен. Чөнки алар – илнең киләчәге.

2 Беренчегә дә ярдәм

Белмим, кемгә ничектер, әмма мин үзем бу хәбәргә бик сөендем. Танышымның тиздән беренче бәбиен алып кайтырга җыенган кызы өчен күңелем тыныч хәзер. Владимир Путинның беренче балага да айлык түләүләр кертеләчәге хакында белдерүе тормышларын көч-хәл белән алып барган бу гаилә өчен күктән иңгән бәхет кебек тоелды. Әле кайчан гына: «Ирсез бала алып кайтырга җыена. Ничек үстерербез? Айлык керемебез, икебезнекен кушсаң да, 25 меңгә дә җыелмый», – дип зар елаган танышым бүген, үзе әйтмешли, «бу бәла»гә башкачарак карый. «Дәүләт үстерешә бит хәзер балачаганы», – дип кенә җибәрә. Әйе, үстерешә, әмма бу очракта да ярдәм адреслы – фәкыйрь тормышлы, аеруча мохтаҗларга, ягъни гаиләнең җан башына туры килгән кереме яшәү минимумыннан 1,5 тапкырга артып китәргә тиеш түгел. Аның күләме һәр төбәктә үзенчә. Әйтик, Татарстанда бүген яшәү минимумы 9142 сум тәшкил итә, ди. Әгәр дә гаиләдә өч кеше икән, уртача керем 41139 сум (9142 сумны 1,5 кә тапкырлыйсың, килеп чыккан санны тагын 3 кә тапкырлыйсың) булачак. Гаилә кереме бу суммадан артып китүчеләргә беренче бала өчен акча бирелми. Илкүләм алганда, әлеге программаны гамәлгә ашыру өчен өч елга 144,5 миллиард сум акча каралган. Бу – бик кирәкле, урынлы чара. Ник дигәндә, безнең илдә минималь хезмәт хакы алып эшләүчеләр 4,9 миллион тирәсе. Бу сан хәтта яшәү минимумыннан да түбәнрәк. Илдә урта хәллеләргә караганда, фәкыйрьләр күбрәк, дигән сүз бу. Шуны уйлыйсың да, бала тапкан өчен акча биргәнче, дәүләтебез һәр гаиләнең хәл-хәятен яхшырту, тормыш дәрәҗәсен күтәрү хакында уйланса, уңай фатирларда яшәп, күп акча алып эшләгән әниләребез үзләре үк бала табарга атлыгып торыр иде, дип тә куясың.

PRESSA.RU

3 Фатир алуга ташламалар

2018 елда икенче йә өченче баласы туган гаиләгә ипотека буенча уртача ставка 10,5 процент тәшкил итәчәк. (Фатир аласы килгән очракта, әлбәттә.) Аның 4,5 процентын дәүләт түли, ә калган 6 процентын – гаилә. Башкача әйткәндә, дәүләт кредит бәясенең 4 процентыннан артыгын үз өстенә ала. Мәгълүматларга караганда, бу бишьеллыкта әлеге программага 500 мең гаилә кертеләчәк, дип көтелә.

Табаргамы? Тапмаскамы? Әлбәттә инде, моны әниләр үзләре, ир белән хатын хәл итә.

4 Бала сәламәтлеген кайгыртып

Илбашы балаларга медицина ярдәме күрсәтүне яхшырту, булган бөтен мөмкинлекләрне куллану, балалар поликлиникаларына капиталь ремонт үткәрү, заманча итеп яңаларын салу турында сөйләгәндә, Республика балалар клиник хастаханәсе күз алдына килеп баса. Шундый медицина учреждениеләре турында барадыр, мөгаен, сүз. Татарстанда гына түгел, илдә бер булган ул хастаханә алдынгы, камил җиһазлары белән генә аерылып тормый. Биредә дөньяга танылган белгечләр эшли. Бары шулай булганда гына бала тормышына куркыныч янамый. Үлем-китемнәрне киметү турында сөйләгәндә, без бит иң элек газиздән-газиз булган әнә шул сабыйларыбызны күз алдында тотабыз.

5 Әниләр – эшкә, нәниләр – яслегә

Декреттан эшкә иртә чыгасы килгән әниләргә дә тиздән, бик тиздән андый мөмкинлек булыр, дип уйлыйм. Балалар бакчаларына чиратны, нигездә, бетердек, дип саныйк. Соңгы елларда бала мәнфәгатьләренә төбәлгән милли стратегияне гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә (ул биш елга исәпләнгән иде) бу юнәлештә зур һәм уңай үзгәрешләр сизелә. «Ике айлыктан 3 яшькәчә балалар өчен яслеләргә чиратларны бетерергә кирәк, – диде Владимир Путин Координация советы утырышында. – Һәм бу мәсьәләне мөмкин булганча тизрәк хәл итәргә...» Инде бүген яслегә урын сорап, 326 мең ата-анадан гариза кергән. Ике ел дәвамында шулкадәрле урынга исәпләнгән яслеләр төзелеп, файдалануга тапшырылачак.

6 Федераль бюджеттан

Һәм соңгысы. Быелдан яңа туган өченче балага федераль бюджеттан пособие алучы регионнар саны киңәйтелде. Элек мондый мөмкинлектән 50 регион файдаланган булса, хәзер аның саны 60 ка җитте. Демографик хәле аеруча начар, ил буенча бала туулар уртачадан түбән булган төбәкләргә бирелә ул. Татарстан бу исәпкә кертелми.

– Әлеге чаралар хөкүмәтебезнең моңарчы күп балалы гаиләләр өчен гамәлдә булган льгота-ташламаларыннан тыш, өстәмә рәвештә кабул ителде, – диде Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова. – Ул ташламалар алга таба да гамәлдә булачак. Мисал өчен, коммуналь хезмәт күрсәтүгә 30 процент ташлама, укучы балага транспортта йөрүне бушлай итү, сәламәтләндерү лагерьларына бушлай юллама, бакчага йөрткән өчен гаиләдәге икенче балага – 50 процент, өченче балага 70 процент ташлама... барысы да элеккечә калачак.

Сүз дә юк, бала тууларны кискен арттыруга зур этәргеч, зур стимул бу. Кесәсе сай булган, бер яктан да акча керер урыны булмаган яшь әниләр өчен дә, өченче баласын табарга җыенган күп балалы әниләр өчен дә... Шулай да... без баланы дәүләт булышкан өчен генә тапмыйбыз. Без аны үзебез өчен табабыз. Күкрәккә кысып сөяр өчен, аның борчу-мәшәкатьләре, уңышшатлыклары, борчулары белән яшәр өчен табабыз. «Бала үз ризыгы белән туа», – дип, җидешәр-унышар бала тапкан әниләрне беләм. Бала үзе – киләчәкнең капиталы. Ә бит, чыннан да, үз ризыгы белән туа алар бүген! Быел дөньяга аваз салырга тиешле акчалы бәбиләрнең саны моңарчы күрелмәгән чикләрне үтеп чыгар сыман.

БЕРЕНЧЕЛӘР



■ Балтач районының Сизнер авылында яшәүче Вячеслав һәм Юлия Тарасовлар гаиләсендә – икеләтә бәйрәм. 4 гыйнвар көнне дөньяга килгән кыз балага исем кушарга да, районның социаль яклау бүлегенә барып пособие алу өчен кирәкле бөтен документларны да тапшырырга өлгергән инде алар. «Авыл җирендә эш хакы бик түбән. Иремнең әлегә даими эш урыны юк, төрле эшләргә йөри. Ай саен биреләчәк 8490 сум акча безнең өчен зур ярдәм ул», – ди яшь әни.

■ Татарстан авылларында яшәүче яшь әниләргә беренче һәм өченче баласын тапкан өчен бер мәртәбә 50 мең һәм 100 мең сум күләмендә акча түләнәчәк.

■ Татарстан Президенты йөкләмәсе буенча якын арада авыл җирендә яшәүче гаиләләр өчен өстәмә ярдәм чаралары эшләнәчәк.

Фото: ТИ/Салават Камалетдинов



Ирләргә генә түгел, хәтта машиналарга да без кирәк! Машина кабынмыймы? Хәзер этеп кабызабыз аны! Кар көртенә батып йә колеядан чыгып, кузгала алмый үкереп утырамы?.. Тагын без сикереп чыгабыз. Пальто итәкләрен җыеп, биек үкчәле итекләрдән кар көртенә батып... Утырып йөрергә яратсаң, машинаны да сөйрисең ул шулай! Без белмәгән эш юктыр да! Үзебез автомеханик, үзебез электрик... Печәнен дә чабабыз, утынын да ярабыз...
Ә менә безгә килгән чит ил кешеләре өчен гайре табигый тоела икән бу «кыланмышларыбыз». Безнең турыда менә нәрсәләр яза алар.
«О! Фантастика! Көчле хатыннар!.. Җиңел генә ирләр эшен башкаралар, ярдәм сорамыйлар».
«Балаларын да, ирләрен дә карыйлар, әти-әниләре янында да утыралар... Күзгә күренмәс бик күп мәсьәләләрне хәл итәләр, комфортсыз да яши алалар».
Швеция журналисты Эдит Пермен ярты ел Россиядә яшәп, хатын-кыз хокукларын өйрәнгән. «Монда хатын-кызлар гаҗәп дәрәҗәдә көчле. Мөгаен, дөньяның барлык башка илләрендәгеләргә караганда да көчлерәктер. Үз җилкәләрендә ниләр генә күтәрмиләр!» – дип язган ул.
Кызганыч, чамасыз күп эшләрне колачлап, «ирләр»гә әйләнәбез бугай... Аннары: «Ирләр юк хәзер!» – дип зарланабыз... Үз кадеребезне үзебез белмибез?!

Фото: Рамил Гали

PRESSA.RU

НЕЧКӘ БИЛДӘ – СОЛДАТ КАЕШЫ
















Фото Анастасия Асанова шәхси архивыннан



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

«ЯҢАЛЫКЛАРДАН КУРЫККАН КЕШЕГӘ ГОМЕР БУЕ БЕР УРЫНДА ТАПТАНУ КУРКЫНЫЧЫ ЯНЫЙ. КЫЕНЛЫКЛАРДАН ТҮГЕЛ, БЕРТӨРЛЕЛЕКТӘН КАЧАРГА КИРӘК», – ДИ АНАСТАСИЯ.

Әлек заманнарда хатын-кызлар кулларына ни сәбәпле корал алган булса, безнең көннәрдә бу сәбәпләр – бөтән, дип әйтеп булмый. Ватанны саклау – ирләр эше, хатын-кызның бурычы – гаилә учагын сүндермәү, дигән кагыйдә безнең геннарга ук салынган. Хәлбуки, Ватанны саклау кебек изге бурычны турыдан-туры үз җилкәләренә алган хатын-кызлар һәр заманда булган. Дөнья тарихындамы? Мисаллар җитәрлек.

Греклардан калган гадәт буенча, хатын-кыз-яугирләрне амазонкалар, диләр. Имештер, Кара диңгезнең көньяк ярында яшәгәннәр. Геродот аларны Скифия варислары, дип язып калдырган. Россиядә әлеге яугир кызларны поляница дип йөрткәннәр. Риваятьләргә караганда, алардан Алеша Попович белән Добрыня Никитич та куркып торган. Дөрес, Добрыня-баһадир аларның берсенә – Настасья исемлесенә өйләнгән дә.

Башта көрәш булган әле. Сәер көрәш. Добрыня, кызның артыннан килеп, бар көченә тукмагы белән тондырган, ди. Настасья селкенмәгән дә. Тагын бер тапкыр кизәнеп орган. Шуннан соң, Настасья борылган да: «Черки тешли дип торам, рус баһадирлары икән», – дигән. Һәм Добрыняны чәч бөдрәләреннән урап алып, капчыгына салган. «Ошасаң, миңа өйләнерсең, ошамасаң, солы белене ясармын», – дигән. Яшь баһадир Настасьяның күңеленә хуш килгән анысы...

Бүгенге көн амазонкалары нинди икән, дисезме? Бүген алар «билен кысып буган» гап-гади солдатлар. Сержант та, капитан да, майор, полковник та булалар...

Чаллы кызы кече сержант Анастасия Асанова бүгенге көндә Көньяк Осетиядә Көньяк хәрби округның 4 нче хәрби базасында хезмәт итә. Контракт буенча дүрт ел хезмәт иткән инде, тагын биш елга озайткан.

– 2012 елда Минзәлә медицина көллиятен тәмамлап, Чаллының инфекция сырхауханәсенә шәфкать туташы булып эшкә урнаштым. Тәҗрибә тупладым, ләкин торабара бертөрлелектән туя башладым.

Әле мәктәптә укыганда ук сыйныф җитәкчесенең контракт буенча армиягә баручы кызлар турында сөйләгәне искә төште. Тынгы бирми генә бит әлеге фикер! Түзмәдем, хәрби комиссариатка барып, белештем. Кыен булачак, син әзерме, диделәр. Ике дә уйламыйча, әзер, дидем. Мөмкинлекне кулдан ычкындыраммы соң?

«Личное дело»мны ачтылар, медицина комиссиясе уза башладым, физик әзерлек буенча нормативлар тапшырам... Казанга Хәрби комиссариатның контракт буенча армиягә сайлап алу пунктына бардык. Анда капитан Рөстәм Риф улы Сафиуллин (ул вакытта пункт башлыгы вазыйфаларын башкаручы) төрле урыннарга шалтыратып, кайда нинди вазыйфага кемнәр кирәк булуын белеште. Кыскасы, җавап көтәргә куштылар.

Бер елга якын вакыт узды, юктыр инде, дип күңел төшә башлаган иде, көннәрдән бер көнне: «Анастасия Валентиновна, тиз арада Казанга килеп җитегез, Мәскәүдән телеграмма бар», – дип шалтыраттылар. Җыенырга дүрт көн вакытым бар иде. Озату кичәсе уздырырга да өлгердем...

Әти-әниең?

– Бөтенесе шаккатты! Әти белән әни, әлбәттә, минем өчен бик борчылды, ләкин каршы килмәделәр.

Әнә шулай итеп, Анастасия Цхинвал шәһәренә юл тота. «Бу шәһәр турында ишеткән дә юк иде диярлек. 2008 елда Грузия белән бәрелеш булуы турында гына белә идем», – ди кече сержант.

Алга таба? – дим, кызыксынып. Иялэшү ничегрәк булды икән?

– Баштарак шүрләп калдым кебек. Ләкин бер мизгелгә генә. Хәрби база, катгый тәртип, вакыт минутлап исәпләнгән – һәр минутның үз эше...

Кадрлар бүлегендә татар кызы Рита Ринатовна эшли иде. Якташ, дип сөенеп куйдым. Мине вакытлыча 2 нче батальонның медицина взводына санинструктор итеп билгеләделәр. Бу вазыйфага кызларны куярга ярамый икән, мине разведка батальонына күчерделәр. Бик тә, бик тә ошый инде үземә! Дүртенче елымны хезмәт итәм. Кешеләре яхшы, комбат – искиткеч, начальник – кызы кебек күрә, бер зур гаилә кебек без монда!

Анастасия, сез хатын-кыз бит, дип юл куялармы, әллә таләпләр бертигезме?

– База командиры белән штаб начальнигы һәрвакыт искәртеп тора: «Армиягә килгәнсез икән, һәрнәрсәгә әзер булыгыз! Бу – армия!» – дип әйтәләр. Билгеле, таләпләр катгый, шулай да кайчак җәллиләр дә инде. Ансыз буламыни, без бит барыбер хатын-кыз булып калабыз.

Шәхси тормыш ничегрәк?

– Әлегә кияүдә түгелмен. Гаилә тормышына әзер түгел бугай мин. Мөстәкыйль булырга, кыенлыкларны үзем җиңеп чыгарга иялэшкәнмен. Бәлки, шуңа да холкымның шушы «үзем» дигән ягына түзәрлек кеше очратмаганмындыр да...

Сары толымлы гүзәл кызның әлеге сүзләре миңа Добрыня белән Настасья турындагы риваятьне искә төшерә. Баһадирлар очрар әле, сиңа, Анастасия, очрар!

PRESSA.RU

«БЕЗНЕ ТЕАТР КОТКАРАЧАК!»

Раил САДРИЕВның тормыш кагыйдәләре



Фото: Ксения Богданова

1995 елда, **29 ЯШЕМДӘ ТОРМЫШЫМДА КИСКЕН БОРЫЛЫШ БУЛДЫ. АҢА КАДӘР ӘТИ-ӘНИЛӘР НИЧЕК ЯШИ – ШУЛАЙ ЯШӘЛДЕ**. Университет бетерергә, аннан соң берәр җирдә эшләргә, дигәнрәк максатлар белән...

Мин комсомолда да эшләп чыккан кеше бит. **МИНЕМ ӨЧЕН КОМСОМОЛ БЕР ЗУР МӘЙДАН ИДЕ**. Райкомда комсомол секретаре булып эшләгәндә, хатыным белән таныштым.

90 нчы елларда бизнеска кереп кителде. Холкым белән мин эшмәкәр түгел, анда бик кырыс булырга кирәк бит. Бизнесның законнары үзенчәлекле, ә 90 нчы елларда кыргый законнар иде. Миңа ике тапкыр аттылар, шактый бурычлар җыелган иде, дус дигәннәрем дошманга әйләнә башлады, бизнес чәлпәрәмә килде. Мине милиция дә эзли, бандитлар да эзли. Күңел төшенке халәттә иде. **АЛЛАҺ КЕШЕГӘ НӘРСӘДЕР ӘЙТЕРГӘ ТЕЛӘГӘНДӘ, ШУНДЫЙ ВАЗГЫЯТЬКӘ КУЯ ИКӘН**.

ДОШМАННАР КҮП БУЛУ НАЧАР ТҮГЕЛ УЛ. Алар, дөресен әйткәндә, безгә тормыш сабагы бирүчеләр. Алар безне акны карадан аерырга өйрәтә.

Чир дә шулай. Ул адәм баласына нәрсәне дә булса аңлар өчен бирелә. Аңламасаң, ятып уйланыр өчен хастаханәгә үк кертеп яткыра. Яисә Аллаһы Тәгалә кешене шундый вазгыятькә куя, син уйланырга, үзгәрергә мәҗбүр буласың. **МИН БИЗНЕСТАН ШУЛАЙ ҮЗГӘРЕП ЧЫКТЫМ**. Иванов системасы буенча су коена башладым. Хатыным Эльмира да миңа иярде. Безнең 8 ел буе баласыз булмады бит. Тугыз елдан соң улыбыз Фәрит туды. Бала туарга өч көн кала, без бәкедә су коенып чыктык.

ФӘРИТКӘ ҖИДЕ КӨН ДИГӘНДӘ, МИН АНЫ ДА САЛКЫН СУ БЕЛӘН КОЕНДЫРА БАШЛАДЫМ. Бер айлык чагында аны мунчада чаптым да салкын карга чыгарып аттым. Әни шунда ук һушы китеп егылды, туганнар шаккатты. Ә хәзер ул пәһлевандай егет инде. Казанда яши, кытай телен өйрәнә.

Мин үзем, әти кеше буларак, әти-әниемә бөтәнчә карашта. **МИН – ӘНИНЕҢ ИҢ ЯКЫН БАЛАСЫ**. Ул мине гомер буе аңлый алмады.

Бездә гомер-гомергә шулай корылган инде: ике кеше бер-берсен ярата, бала тудыра. Һәм ул балага акционерлар шикелле көч салалар. Һәм бала үсеп җиткәч, гапгади кулланучылар кебек, аннан дивидендлар көтә башлыйлар. Ә бит **БАЛА БУ ҖИРГӘ ҮЗ БУРЫЧЫ БЕЛӘН КИЛӘ**. «Менә безнең нәселдә шушылай, безнең нәселдә укытучылар гына, бездән башка кеше чыга алмый», – дип, ата-анасы чикләр куя.

АКЧА миңа хыялларны тормышка ашыру өчен кирәк. **УЛ МИНЕМ ӨЧЕН СОЦИАЛЬ ЯГУЛЫК**.

Мин беләм: теге дөньяга үзең белән бернәрсәне дә алып китеп булмый. Үз-үземә моны көн саен искәртәм. **БЕЗНЕҢ БЕЛӘН ТЕГЕ ДӨНЬЯГА 9 ГРАММЛЫ ҖАН ДИГӘН ФЛЕШКА КИТӘ**. Ул бары тик безнең хискичерешләрдән тора. Хисләр уңай булган саен, флешка агара бара, нурга әйләнә.

КЕШЕ БУ ҖИРГӘ БУШ КИЛӘ, БУШ КИТӘ. Буш килү белән буш китү арасында адәм баласы үзе белән алып китә алмый торган әйберләрне җыеп, туплап, аның өчен көрәшеп, сугышып, судлашып, беркөнне китеп бара, ә багажы – юк.

Адәм баласы бер нәрсәне аңлап бетерми: тормыш ак һәм кара полосалардан тора. **КАРА – АКНЫҢ НӘРСӘ ИКӘНЕН АҢЛАР ӨЧЕН КИРӘК**. Дөньяны үз кулларына алам, дип яшәүчеләр һәрвакытта да киң, ак полоса булуын телиләр. Алар ул ак полосаны балаларыныкын, оныкларыныкын алалар, тегеләре аннан соң карада гына яши.

1975 елда мин бишенчедә укый идем әле. Географияне, тарихны ярата идем. Шунда бернәрсә истә калган: «Садриев, әйт әле, планетада ничә миллиард кеше яши?» – дип сорый укытучы. – «Өч миллиард ярым». Бүген – җиде миллиард. Менә шушы **ҖИДЕ МИЛЛИАРД ХАЛЫК КӨН САЕН АШЫЙ, ЧЫГАРА, ТҮГӘ, БӘРӘ**.

БЕЗ – КУЛЛАНУЧЫ. Җиде миллиард кешегә бер көнлек бәдрәф кәгазе җитештерү өчен 27 мең төп агач кисәргә кирәк икән. Халык Җир өчен бернәрсә эшләми, аның үзенә генә булсын.

Бүреләрне ерткыч, диләр. Әле **БЕР ГЕНӘ БҮРЕНЕҢ ДӘ ИКЕНЧЕ БҮРЕНЕ КӨТҮЕ БЕЛӘН ЮК ИТКӘНЕ ЮК**. Киекләр табигатьтән артыгын алмый, үзенә җитәрлекне генә ала. Адәм баласы исә бер-берсен юк итү белән шөгыльләнә.

ДИН БАР, ДИНИЛЕК БАР. ДИНИЛЕК – ХАЛӘТ. Дин исә – форма. Аллаһ кешене үзенә охшатып яралткан, диләр. Библиядә шундый сүзләр бар. Мин, киресенчә, адәм баласы Аллаһны үзенә охшатып уйлап чыгарган, дим.

МИНЕМ ӨЧЕН АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ ОКЕАН СЫМАН УЛ. Адәм балалары шул океандагы тамчылар. Китапта шундый сүзләр бар: «Аллаһ кешенең ни уйлыйсын, ни кыласын алдан белеп тора». Әлбәттә, океан тамчының ни уйлаганын белә, чөнки ул тамчыдан тора бит. Ә менә тамчы беркайчан да океанның масштабын күрә алмый.

Тамчы океанның бер өлеше икәнен белсә, ул океан гамәлләрен кыла ала. **АДӘМ БАЛАСЫ – АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ БЕР КИСӘГЕ**. Шуны истә тотып акыл йөртсә, кеше дөнья белән дә, үз-үзе белән дә гармониядә яшәр иде. Һәркемнең уе нәрсәдер үзгәртә.

PRESSA.RU

ТӘҮРАТТА ДА, КОРЪӘНДӘ ДӘ «доллар» да, «рубль» дә, «манат» та, «динар» сүзе дә юк. Анда **КЫРЫКТАН БЕР ӨЛЕШ, ДИГӘН СҮЗ ГЕНӘ БАР**. Кырыктан бер өлешнең күпме икәнен кеше үзе генә белә.

КЕШЕ ОРГАНИЗМЫНДА БЕР СЕКУНД ЭЧЕНДӘ ИКЕ МИЛЛИАРД ОПЕРАЦИЯ БАРА. Боларны кеше акылы иңләп бетерә алмый. Димәк, боларны кемдер уйлаган бит? Бөек көчләр, бөек акыл уйлаган моны.

ҮЛЕМ – ДӨНЬЯДАГЫ ИҢ КОНКРЕТ ТӨШЕНЧӘ. Сәясәтчеләр – алдарга, хатыннар, ирләр – хыянәт итәргә, дуслар сатарга мөмкин, хәтта һава торышы үзгәрә, ә менә үлем тотрыклы булып кала.

АДӘМ БАЛАСЫ ҮЛЕМГӘ ӘЗЕР ТҮГЕЛ, ӘЙТЕРСЕҢ ЛӘ, УЛ КҮРШЕГӘ ГЕНӘ КИЛӘ. Үзе белән алып китә алмый торган әйберләр җыя, шуның өчен көрәшә, сугыша, иманын җуя.

Минем театр белән шөгыльләнүем – кешеләр белән эшләргә өйрәнүем. **ТЕАТР – МИНЕМ ӨЧЕН МӘКТӘП УЛ**, чөнки киләчәктә – 60 яшьләрне узгач, үземне туган авылымда кешеләрне рухи сәламәтләндерүче бер карт итеп күз алдына китерәм. **ШУҢА ДА МИН КАРТЛЫКТАН КУРЫКМЫЙМ**.

ӘЙБӘТ ШАРТЛАРДА ӘЙБӘТ КЕШЕ БУЛУ ӘЙБӘТ УЛ, СИН НАЧАР ШАРТЛАРДА ӘЙБӘТ БУЛЫП КАРА!

Казанда шигырьдән генә торган «Сез әле мине белмисез» дигән программа белән чыгыш ясадым. 38 шигырь укыдым, шуның берсе – поэма. Филармония залы тулы иде. Тып-тын булып тыңладылар. 15 ел элек, сәхнәгә чыгып шигырь сөйләсәң, халык куып төшергән булыр иде.
Ә ХӘЗЕР СӘХНӘГӘ ЧЫГЫП ШИГЫРЬ СӨЙЛИ БАШЛАСАҢ, ХАЛЫК ТЫНЫП КАЛА, ТАГЫН СОРАП СӨЙЛӘТӘ.

БҮГЕН ЭШЛИ ТОРГАН ЭШНЕ БҮГЕН ЭШЛӘРГӘ КИРӘК.

Без 70 ел бер идеологиягә буйсынып яшәдек. **ТАГЫН БЕР УН ЕЛ ШУШЫ СИСТЕМАГА ТИМӘГӘН БУЛСАЛАР**, аның нәтиҗәләрен күрә башлаган булыр идек. Мин шулай дип уйлыйм. 60 нчы елларда без Галәмгә чыктык, Фәннәр академиясе ачыш арты ачыш ясады. Ә бит боларның нигезе 20-30 нчы елларда мәктәптә салынган булган. Бу ачышларның авторлары ул вакытта мәктәптә укыган.

Менә мин – совет кешесе. **МИНЕ ДУС БУЛЫРГА ӨЙРӘТТЕЛӘР, КЕШЕ БЕЛӘН БҮЛЕШЕРГӘ, БЕРГӘ ЭШЛӘРГӘ, МАТУРЛЫККА ОМТЫЛЫРГА, ЮГАРЫ СӘНГАТЬНЕ АҢЛАРГА ӨЙРӘТТЕЛӘР**. Мин генә түгел, 250 миллион халыкка өйрәтелгән болар. Начармыни?

РОССИЯ ХАЛКЫНЫҢ ГАДӘТЕ: БУЛГАННЫ ҖИМЕРЕП ТАШЛАП, ЯҢАНЫ ТӨЗҮ. Буыннар чылбыры өзелә. Ә бит булганга таянганда гына уңышка ирешеп була.

Зиннәтле шәрабны гади шәрабтан күнмәгән кеше ничек аера? Чын сәнгать әсәрен аера белүче кешеләр дә 5 процент кына. Ә калганы – гөбәдия, биг-мак. Калган **95 ПРОЦЕНТ КЕШЕ ӨЧЕН НӘРСӘДЕР БУЛЫРГА ТИЕШ БИТ**. Аларны тәрбияләргә кирәк.

ХАЛЫК ТУК ХӘЗЕР, ЛӘКИН КАНӘГАТЬ ТҮГЕЛ. БУ – ЧИР.

МИН КИЕНЕРГӘ ЯРАТАМ. Хәтта хатын көнләшеп тә карый, аласың да аласың, ди. Кием түгел, каймак чүлмәген дә матурны алырга тырыша кеше. Кеше төрле яклап матур булырга, шуңа омтылырга тиеш.

Мин кечкенәдән, матур әйбер күрсәм, туктап карап тора идем. **КЫЕКНЫ ТУРАЙТАСЫ, ВАТЫКНЫ ТӨЗӘТӘСЕ КИЛӘ ИДЕ**.

ТЕАТРНЫ ЯРАТУЫМ ДА МАТУРЛЫКНЫ ЯРАТУЫМНАН. Мин бераз гына сәхнәдә уйный, рәсем ясый, шигырь сөйли беләм. Җырлый белмим, ләкин гаиләдә җыр тыңлап үстем. Бездә гармунчылар күп.

ТЕАТР ТӘРБИЯЛИ. Ул үзенең диварлары, анда кешене китерүе белән, фойедагы рәсемнәре, утыргычлары, пәрдәсе белән үк тәрбияли. Артистларны әйтеп тә тормыйм.

БЕЗНЕҢ ХАЛЫК ҖЫЛЫ СҮЗГӘ САРАН. Мин үзем дә сирәк әйтәм аларны. Гәрчә һәркем көтә, ишетсә, рәхәт булып китә.

БЕЗНЕҢ ТАТАР ШУНДЫЙ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ХАЛЫК: аның әлгәре кире каккан әйберләре милли байлыгына әйләнә. Мәсәлән, театр сәнгате аныкы түгел, бу формада ул уйлап чыгармаган театрны. Ә бүген: «Менә безнең татар театры!» – дип күкрәк кага. Мескен артистларга көн булмаган чакларны искә төшерегез сез! Тальян гармуны – итальян гармуны. Бүген аны татарның уен коралы, диләр.

Безнең бабайлар бөек булган, дибез. Ә син үзең бөекме соң? **БӨЕК БУЛЫР ӨЧЕН СИН НӘРСӘ ЭШЛӘДЕҢ?**

БУА ТЕАТРЫна – 15 ел. УЛ БҮГЕН ХАЛЫКАРА АЭРОПОРТЫНДА ОЧАРГА ӘЗЕРЛӘНГӘН ЛАЙНЕР КЕБЕК.

Американы Голливуд коткарган булса, безне театр **КОТКАРАЧАК**. Бүгенге Америка – Голливуд моделе ул.

БҮГЕНГЕ КҮЛӘМ СЫЙФАТКА ӘЙЛӘНЕРГӘ ТИЕШ. Шушы вакыт җитеп килә.

Фикерләр тупланмасын Ландыш ӘБҮДӘРОВА теркәде.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

СТАТУСЫМ: БЕРАЗ ГЫНА 40+



Алмаз МИРГАЯЗОВ

Хатын-кызның яше турында сүз башлау, минемчə, ир-ат өчен иң куркыныч темаларның берседер.

Кайсыбер ханымнар, яшь турында сүз чыгуга, үзенең тормыш тəҗрибəсенə ишарəле башлый, эчке матурлык, тормышка яңа караш турында фəлсəфə корып җибəрə. Кемнеңдер еллар аша тагын да чибəррəк, затлырак, зыялырак күренергə өйрəнгəн йөзе караңгыланып китə, елмаюы моңсу төшенкелек хисе белəн алышына. Бер мизгел эчендə, ирексездəн, берəн-сəрəн сызылган маңгай сырын капшап куя, көзгесен алып, ялгыш күзенə күренгəн ике бөртек чал чəчен барлап ала. Уйлары белəн исə 10-15 елга килəчəккə йөгерə. Йөзе, гəүдəсе, ə иң мөһиме: əйлəнə-тирəдəге кешелəрнең үзенə карата мөнəсəбəтенең үзгəрү перспективаларын күз алдыннан кичерə. Бик еш аның фикеренчə, 20 яшьлек туташ белəн 40 яшьлек ханым арасында упкын хасил була. Ə тагын 20 елдан соң, аның өчен дөнья бөтенлəй бетəчəк...

Моның алай түгел икəненə ышану өчен тирə-якка күз салу җитə. Компьютерлар, кесə телефоннары ярдəмендə үзеңə тиңнəрне күзлəү, алар белəн аралашу өчен көн саен яңа мөмкинлеклəр ачылып тора. Одноклассники, Вконтакте, Инстаграм, WattsApp, Телеграм челтəрлəрендə бүген дистəлəрчə миллион хатын-кыз «яши». Кем генə юк анда...

Яшьлегенең бишенче дистəсен башлап килүче бериш ханымнарның профиль статусы «барысы да алда, тормыш əле яңа башлана» ише шигарьлəр белəн ачыла. Килешми булмый бит! Икенчелəренең виртуаль битеннəн исə «бер кат пешкəнче мең кат тикшерүең яхшырак» кебегрəк бераз акланулы тормыш девизлары күренə. Сурəтлəре күбесенчə үзлəренеке. Шагыйрьчəрəк əйтсəк, фотолары аша үз күзлəре белəн очкын сибəлəр. Кайбер очракта, аерымачык «аучы» киемнəрен киеп, кайчак күзне ярып керə торган макияжлары белəн безнең затны аптырашта калдыралар, ə иң аяныч фотоларда исə еллар узу белəн күбрəк сер булып калырга тиешле урыннары артык күп булып ишелеп төшə...

Бихисабы «актив эзлəнүдə» түгəрəк-түгəрəк акыллы цитаталар белəн «сөйлəшəлəр», күп вакытларын интернетта үздыралар, бик телəп үзара килде-китте хуҗалык темаларына гаммəви гəп куертып алырга да каршы түгеллəр. Оппонентлары, аеруча каршы җенес вəкиллəре белəн тартынмыйча, күп очракта мораль нормаларыннан һəм əхлак принципларыннан читкə китеп аралашырга күп сорамыйлар. Алар – чын, алар шундый, алар төрле яклап «азат». Тик һəр очракта диярлек, алар – ялгыз хатыннар...

Социаль челтəрлəрдə җылы гаилə кочагына кереп сеңгəн һəм шунда эреп «йокыга талган» хуҗабикəлəр дə бар. Аларга җылы, рəхəт: еллар буена кайнап береккəн үз ире, яшүсмер бала-чагасы, йорты, мал-туары, кош-корты, бакчасы, чүпрəк-чапрак, савыт-сабасы... Андыйларның сəхифəлəреннəн, кагыйдə буларак, моннан 6-7 ел элек төшереп элгəн гаилə фотолары яисə «Күрəсезме? Минеке!» ише ирле-парлы бəхетле фотолар елмая. Никах, ашлар, туган көн, Яңа ел ише кысан түгəрəкле гаилə бəйрəмнəреннəн репортажлар бихисап. Бер сүз белəн əйткəндə, болар – бəхетле ир хатыннары.

Тагын бер төр ханымнарның барысын бер итеп «Исеме ничек булса да, барыбер түгелмени» дип атап була. Андыйлар бик күп түгел. Беркайчан да үз сүзлəрен, хəлəхвəллəрен, хис-кичерешлəрен кешегə сөйлəмилəр. Тормыш, яшəеш, язмыш турында беркатлы цитаталар куялар. Аларның төп битендə фотографиялəр урынында берəр рəсем (ешрак мəче яисə башка йорт хайваны, ə иң киң таралган очракта кочак-кочак сары, кызыл, алсу, ап-ак чəчəк бəйлəмнəре) була. Ə үз фотолары юк.

Хатын-кызга үзе булып калырга, узган чорларны елмаеп озатырга, килгəн елларны оптимизм белəн каршы алырга нəрсə комачаулый соң? Бишенче дистəне ваклый башлау белəн гүзəл затларны сурəтлəрен песи белəн алыштырырга, йөзлəрен чəчəк арасына яшерергə мəҗбүр итүчелəр кем?

Без. Ир-атлар. Дөресрəге, безнең битарафлык, безнең игътибарсызлык...

Ничə яшьтə булуына карамастан, хатын-кыз һəрвакыт дөньяның иң гүзəл заты булып калачак. Еллар аңа зыялылык, кайчак ирлəреннəн артык акыл бүлəк итə, тормышны яңабаштан бəялəп, аңлап белү, бөтен матурлыгын, бөтен мөмкинлеклəрен кулланырга өйрəтə, җыерчыклары исə йөзлəренə җылы нурлы эчке балкыш кына өсти. Без моны күрəбез, сизəбез, тагын да ныграк яратабыз, əмма дəшмибез. Чөнки без – ирлəр. Безне дəшəргə, яратырга, сокланырга мəҗбүр итəргə кирəк. Сиздерми генə, хəйлəкəр генə итеп... Тормыш сезне иң беренче чиратта шуңа өйрəтə түгелме соң?

PRESSA.RU



НӘНИ ВӘХШИЛӘР



Мәдинә
АВЗАЛОВА

АЛАР СУГЫШАЛАР, КЫЙНАШАЛАР, УРЛЫЙЛАР, ТАЛЫЙЛАР... ХӘТТА ҮТЕРҮ-КӨЧЛӘҮЛӘРГӘ КАДӘР БАРЫП ҖИТӘЛӘР.

Ул очрашуны гомер онытасым юк. Чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган биек койманы да, йозакта торган катлы-катлы тимер ишекләрне дә... Һәм аны... Аның битараф йөзен, битараф кыяфәтен. Яшүсмерләр колониясе тәрбиячесе: «Журналист, дисәгез, сөйләшмәс, психолог дип әйтегез», – дип, алдан ук кисәтеп куйган иде. Сөйләшүнең авыр булачагын белеп бардым. Сүзне нидән башларга белми торганда, ул үзе: «Мин дә психологка укырга җыенам. Югары белем алсам, калганы... барысы да бар минем», – дип, беренче җөмләсеннән үк мине аяктан екты. Судта әнисен, әтисен, апасын пычак белән чәнчеп үтергән 17 яшьлек ул вәхшидән: «Ни өчен шундый җинаятькә бардың?» – дип сорагач: «Кирәк-яракка акча бирмәделәр. Срогымны тутырырмын да чыгармын, хәзер әнә өч бүлмәле фатир да, дача да, машина да минеке бит», – дип, судта катнашучыларны өнсез калдыра. Моңа инде ун елдан артык вакыт үтеп китте. «УДО буенча чыгарачаклар, мин монда үземне бик тәртипле тотам», – диде ул саубуллашканда. Күптән

чыккандыр инде. Тик менә кан өстендә корылган тормышның ахыры ни белән бетәсен генә берәү дә белми. Барысы өчен дә җавап тотасы көннәре алда әле аның.

Яшүсмерләрне рәхимсезлеге ягыннан тиңе булмаган мондый җинаятьләргә ни, нәрсә этәрә? Бер кизәнүдә үзләренең дә, корбаннарының да язмышын чәлпәрәмә китерер өчен нинди сәбәбе булырга тиеш аның? Юк андый сәбәпләр. Була да алмый. Берара журналыбызда өч егетнең (шуларның берсе – яшүсмер) 14 яшьлек кызны мәсхәрә итүләре турында язып чыккач, язма тирәсендә зур тавыш купты. Егетнең әниләре кызны гаепләде, янәсе ул үзе ризалык биргән. Шушы хәлләрдән аңларга була да гаилә тәрбиясенең бездә ни дәрәҗәдә торуын. Инде килеп, Пермь шәһәренең 127 нче мәктәбендә булган хәлләрне генә исегезгә төшерегез. Пычак белән коралланган ике яшүсмер 15 баланы җәрәхәтли. Укытучы белән унбер яшүсмер авыр хәлдә хастаханәгә озатыла. Бу эш белән хәзер Россия Федерациясенең Тикшерү комитеты, Үзәк Аппараттан җибәрелгән дистәләгән хезмәткәр шөгыльләнә.

Үтерү-көчләүләр яшүсмерне, әйткәнебезчә, биек коймa артына алып ташлый торган соңгы чик, соңгы адым. Ләкин бүген кыз һәм малайлар арасындагы элек-электән килгән бер-берсен үчекләү гадәте яңа, әйтер идем, тагын да куркынычрак төсмер ала бара. Яшүсмерләр арасында суицид темасына материал әзерләп йөргәндә, Казан мәктәпләренең берсендә укучы 13 яшьлек кыз бала белән сөйләшкәнем хәтердә.

– Әнием – эчкече, әтиемне белмим дә. Мәктәптә моны беләләр. Мине гел мыскыл итәләр, «алкаш кызы», дип үртиләр. Сыйныфташларым өчен мин бер ташландык нәрсә кебек. Ничә тапкыр үземә кул салырга җыенып карадым. Булдыра алмыйм, – дигән иде ул.

Баланың сыйныф җитәкчесе белән сөйләшкәндә, ул мине: «Әти-әниләрнең бөтен нәрсәдә укытучыны гаепли торган гадәте бар. Укучылар арасындагы низагларны күп вакыт күрмичәрәк калырга тырышабыз», – дип гаҗәпкә калдырды.

Белгечләр, баланың агрессиясен көчәйтүче сәбәпләрнең берсе итеп компьютер уеннарын, төрле фильмнарны, хәтта мультфильмнарны атыйлар. Субкультурага кагылышлы музыка да шундый ук тәэсиргә ия. Чит илләрдән кайтарылган төрле сәер уенчыклар, әйтик, вампирлар, монстрлар да баланы чынбарлыктан ераклаштыра. Үтерү, көчләү белән бәйле уеннар баланы нәрсәгә өйрәтә дип уйлыйсыз?

«Акча бирмәсәң, кыйныйм»

Узган елның декабрь ахырларында шушы темага багышланган матбугат конференцияләре шактый булды. Күрәсең, мәсьәлә, чыннан да, җитди. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре, балигъ булмаганнар эшләре буенча полициянең һәм бүлекчәләрнең участок вәкилләре эшчәнлеген оештыру идарәсе җитәкчесе урынбасары Лариса Осипова әйтүенә караганда, яшүсмерләр арасында җинаятьләр бераз кими төшсә дә, тынычланырга иртәрәк әле... Былтырның соңгы өч аенда гына да алар тарафыннан кылынган 102 җинаять эше теркәлгән. Балигъ булмаганнар арасындагы 325 җинаятьнең 322 се мәктәп балаларына туры килә. Узган ел тәртип бозучы 463 яшүсмер вакытлыча яшәтеп тоту үзәкләренә озатылган.

Саннар шуны сөйли. Ә саннар артында берсеннән-берсе тетрәндергеч вакыйгалар ята. Бер бездә – Татарстанда гына да бүгенге көндә 108 яшүсмерләр төркеме барлыгы ачыкланган. Талауларда, куркытып акча алуларда гаепләнгән ике төркемнең ун эпизод буенча расланган җинаять эше судта хәзер. Төркемнәргә керүче яшүсмерләрнең бишесе – Казанның 13, 32, 65 нче мәктәпләрендә укучы балалар. Кыз баланың муенына пычак терәп, аннан акча таләп итүченең үзе дә кыз кеше булуын күз алдына китерү дә кыен. Бала-



Наталья САБИРОВА, Казан шәһәренең балаларга һәм яшүсмерләргә психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтү «Сердәш» үзәге җитәкчесе:

Баладагы агрессиянең сәбәпләрен иң беренче гаиләдән эзләргә кирәк. Аңа наз-ярату җитмәү генә түгел, аны артык ярату, бертуктаусыз янында бөтерелү дә юньлегә китерми. Әгәр дә ата-ана баласының һәр адымын тикшереп тора икән, ул чагында аның күңелендә үзен шәхес буларак күрсәтү теләге уяна. Һәм ул еш кына моны тирәсендәгеләргә агрессия рәвешендә күрсәтә. «Сукыр мәхәббәт» тә үзен акламый бу очракта. Бала, миңа барысы да рөхсәт ителә, дип уйлый. Яшүсмернең начар компаниягә эләгүе, мәктәптә үзен аңламаулары да (әйтик, милләте башка, ул артык акыллы, матур яисә башкаларга охшамаган) баланы начар гамәл кылуга этәрергә мөмкин. Ата-ананың балага ятатуын күрсәтә белмәве, салкын мөнәсәбәте исә аңарда чит кеше кичерешләренә битарафлык тәрбияли. Кайчак баланың үз-үзен тотышындагы сәер, ә еш кына рәхимсезлек билгеләрен «күрмичә» калу да хәерле. Кайбер бала аны бер эшли дә оныта. Әгәр дә инде бу хәлләрдән зур тавыш чыгарсаң, кара әле, болай итеп тә үзеңә игътибар иттертеп була икән, дигән ялгыш нәтиҗә ясый.

Башка берәүне рәнҗетергә, аңа сугарга ярамаганлыгын өлкәннәр үз-үзләрен тотышлары белән күрсәтергә тиеш. Әгәр дә ир хатынына кул күтәрә икән, бу хәлләрне күреп торган бала да киләчәктә шуны кабатлаячак. Бала, «ярамый», дигән сүзләрне еш ишетә. Ә нәрсә ярый соң аңа?

Баланың күп вакыты мәктәптә уза. Педагоглар бер генә баланы да читкә кагарга, яратмавын күрсәтергә тиеш түгел. Кызганыч, тәҗрибә киресен раслап тора. Укытучы баланы сүз белән кимсетмәсә дә, «сөйкемсез» укучысын котырту, әзәрлекләү юлларын таба. Тора-бара башкалар да моңа кушыла. Соңгы вакытта яшүсмерләр бер-берсенә карата җәбер-золым кылу очракларын видеога төшереп, интернетка куя башладылар. Ата-ана баласына ышанса, аны хөрмәт итсә, уңышларына куанып, канатландырып торса, спорт, иҗади эшләр белән мавыгырга өндәсә, дуслары белән кызыксынса, һәм әлбәттә инде, компьютердан аерып, вакытын күбрәк баласы белән үткәрсә, тора-тора безне уйланырга, сагаерга мәҗбүр иткән куркыныч мисаллар да азрак булыр иде.

Фото: www.pixabay

PRESSA.RU



Наталья ЖЕЛЕЗКОВА, Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнарының балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясе җаваплы секретаре:

Моннан җиде еллар чамасы элек балаларга һәм яшьләргә социаль ярдәм күрсәтүче «Доверие» үзәге белән бу эшне башлап җибәргәндә, уй-теләкләребезнең шулай уңышлы барып чыгасына бигүк ышанып та җитмәгән идек. Хәзер республиканың 54 мәктәбендә килештерү хезмәте эшли. Балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясе әгъзалары, психологлар белән берлектә, яшүсмерләр арасында килеп чыккан низагны көйләү өстендә эшлиләр. Моның өчен гадел хөкем чыгару программасы эшләнде. Килештерү хезмәте вәкиле балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясенең һәр утырышында катнаша. Килештерү өчен төрле очраклар сайлап алына. Шуның нәтиҗәсендә яшүсмерләрнең бик күбесе исәптән төшерелде һәм яхшы якка үзгәрде, дип әйтә алабыз.

чага бер-берсен куркыту-мәсхәрә итүнең моңарчы күрелмәгән, «камилләшкән» юлларын уйлап таба. Казан шәһәренең 91 нче мәктәбендә укучы кыз бала икенче бер кызга бер ай дәвамында, «акча бирмәсәң, кыйныйм», дип, «смс»-хәбәрләр җибәреп ята.

Рәхимсезлек – мәктәп тормышында аерылгысыз бер күренешкә әверелеп бара.

Игътибарыбызны әлеге проблемага юнәлтергә мәҗбүр иткән тагын бер хәбәр: Нурлат шәһәрендә яшәүче 18 һәм 15 яшьлек ике яшүсмер 35 яшьлек ирне пәке белән чәнчеп үтерәләр. Бу ике яшь җинаятьче кулга алынды һәм аларга карата җинаять эше кузгатылды. Ел әнә шулай кайберәүләр өчен зур бәхетсезлекләр, ачы кайгы-хәсрәтләр белән башланып китте.

Күз карасыдай саклап, җил-яңгыр тидерми, кадерләп үстергән балаларыбыз ни өчен шундыйга әйләнеп бара соң безнең? Моның сәбәпләре нидә? Яшүсмерләр арасындагы безгә гайре табигый тоелган бу рәхимсез уеннарга ничек каршы торырга? Әлеге сорауларга җавапны бергә эзлибез.

«Улымны котырталар»

– Минем улым 7 нче сыйныфта укый, – ди Казан шәһәрендә яшәүче Нәзирә ханым. – Начар укый, дип әйтә алмыйм. Ир бала өчен әйбәт. Тәртипсезләнеп тә йөрми. Берара кәефе төшеп, безнең белән сөйләшми башлады. Әйтерсең, баланы алыштырып куйдылар. Сораштырып карыйм мәктәптәге хәлләрен. Нормально», – ди. Башка берни әйтми. Түземлеге беткәндер, күрәсең, көннәрдән бер көнне чишелде бала миңа: «Класста минем белән сөйләшмиләр. Үчектеләр миңа. Мыскыллы сүзләр әйтәләр, котырталар. Нигә икәнен аңламыйм», – ди. Икенче көнне кара канга батып кайтты. «Үзем сугыштым», – ди. Җыендым да мәктәпкә киттем. Сыйныф җитәкчесе: «Мин белмим, андый нәрсәне күргәнем юк», – дип, җилкәсен җыерып тик тора. Тәҗрибәле педагог үзе. Укучылар белән сөйләшә торгач, сәбәбенә төшендем. Бөтен проблема укытучының үзеннән башланган икән. Балага иптәшләре алдында мәсхәрәле сүзләр әйткән, калганнары шуны эләктереп алган. Мәсьәләне директор белән хәл итәргә туры килде. Дөресен әйткәндә, бала тик торганнан рәхимсезгә әйләнми. Оясында ни күрсә, диләр бит. Шуның шикелле инде.

...Яшүсмерләр арасында җәберзолым очраклары гел хөкем карары белән тәмамлана, дип уйласак, ялгышабыз. Өлкәннәр, эшне зурга җибәргәндә, җәберләүченең (ул да бала гына бит әле) киләчәгенә мөһер сугылачагын аңлыйлар. Һәм еш кына низаг ике арада килешү белән тәмамлана. Физик көчләүләр булмаганда, гаеплеләр, гомумән дә, җәзасыз кала. Шуны күздә тотыпмы, әллә инде тездән төшәргә дә өлгермәгән балаларның вәхшилегеннән гаҗиз калыпмы, Дәүләт Думасына, Федерация Советына, Президент администрациясенә, авыр җинаять кылучы бала-чаганы, балигъ булганын да көтмичә, хәтта ки 12 яшеннән үк, ирегеннән мәхрүм итүне сорап, хатлар килә башлады. Куркыныч булып китә. Шәхсән мин үзем моны күз алдына да китерә алмыйм. Ә бит эшләр яманга китсә, шундый законнар кабул итүләре дә ихтимал. Үзең нинди, балаң шундый, дисәм, яңалык әйтмәм. Балагызда агрессия чалымнары күренә башлады исә үз тәртибегезне карагыз. Ул сезне кабатламыймы? Яшүсмер чордагы тилелекләр бераздан бетәргә дә мөмкин. Бетми икән, психологларга мөрәҗәгать итегез!

ИГЪТИБАР

Балигъ булмаган балаларга карата кылынган авыр җинаять – ул Россия Федерациясенең Тикшерү комитеты органнары компетенциясендә. Мондый очракларны булдырмас өчен, Россия Федерациясенең Татарстан буенча Тикшерү комитеты «Балага куркыныч яный» дип аталган телефон линиясе дә булдырды. Аның номеры: 8 (843) 238-33-59 яки «123». Шалтыратып, үзегезнең яисә кемнеңдер баласын фаҗигадән саклап кала аласыз.



ШӘЙХЕТДИНОВА Миләүшә

Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты

Кызы Сөмбелне тәрбияли

Карьера: Камал театры артисты, «Бала-сити» мәктәбендә актерлык осталыгын укыта.

Тормыш шигаре: «Иң мөһиме: туктап калмаска, гел хәрәкәттә булырга!»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Күңелле мәшәкатьләр

Узган көз – 28 октябрьдә әтием Наил Шәйхетдиновка багышлап чыгарылган китапның тәкъдим итү кичәсен үткәрдек. Гомумән, былтыр әтинең «Мин сәхнәдә – рухани» дигән китабын чыгару мәшәкатьләре белән узды. Китапны басмага Илдар Кыямов әзерләде. Әнием Миңнегөл әтинең бөтен архивын туплап барган. Бөтенебезнең тырышлыгы белән 263 битлек китап чыкты. Тинчурин театрында зур кичә булды. Чирмешән районыннан якташларыбыз бик күп килде, әтине хөрмәт иткән тамашачылары җыелды. Зал туптулы иде. Шулай ук кызым Сөмбел быел тугызынчы сыйныфны тәмамлады. Имтиханнарга әзерләнү, әйбәт билгеләр алуы күңелле мәшәкатьләр булып истә калды.

#баламбагалмам

Узган елның соңгы айларында татар халкы тел мәсьәләсендә катлаулы хәлдә калды. Без дә театрда туган телне саклап калу өчен үзебез бүген үк нәрсә эшли алабыз, дип уйлаштык та #баламбагалмам хэштегы белән инстаграм челтәрендә акция башлап җибәрдек. Бу агитация дә, сәясәт тә түгел. Камал театрында яшь гаиләләр күп. Туган телне гаиләдә – балаларыбыз белән татарча сөйләшеп саклыйбыз. Шушы турыда кыска гына видеороликлар төшерәбез һәм челтәргә элүбез. Бу эшне Динә һәм Илнур Закировлар башлады, аларның аккаунтына бик күп кеше язылган. Башкалар иярде, хәтта фин татарлары да кушылды безгә. Хәзер инде иллегә якын шундый видеоролик эленеп тора интернетта.


Зур театрда – «Нуриев»

Ниһаять, Зур театрда «Нуриев» балетының күптән көтелгән премьерасы булды. Бу премьераның режиссеры – әлеге вакытта кулга алынып, өйдә утыручы Кирилл Серебренников. Шуңа да «Нуриев»ның сәхнәгә чыгуы тоткарланды, соңгы көнгәчә билгесезлектә калды. Ләкин бернигә карамыйча, бөтен дөньяга танылган шәхес, татар кешесе – Рудольф Нуриев турындагы балет илнең иң абруйлы сәхнәсенә менде, дөньякүләм масштабта мәдәни вакыйга ясады.

сөендерде








көендерде

сөендерде








көендерде

сөендерде







көендерде

Бер сүз җитә...

Адәм баласы яхшылыкка бик тиз ияләшә, ләкин үзе аңа бик озак бара. Кешеләр белән үзара ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен зур тырышлык куясың, моның өчен озак вакыт кирәк.
Һәм көннәрдән бер көнне мөнәсәбәтләр пирамидасы җимерелә дә куя. Бер сүз, бер караш, бер гамәл аркасында.
Мондый вакытта мин үзем шок хәлендә калам. Югыйсә кешеләр һәрдаим үсештә, алга барабыз, дибез. Адәм баласына тарих яки башка кешеләрнең хатасы гына түгел, үзе ясаган хаталар да сабак бирә алмый икән.

«Рубин»га ярдәм кирәк бугай

Мин – хоккей белән футбол фанаты. Гомумән, спорт дөньясы белән кызыксынып барам. Соңгы елларда «Рубин» командасының җиңүчеләр рәтеннән төшә баруына битараф кала алмыйм. Корбан Бердыев тренер булып кайткач, бик шатландым. Минем футбол җанатары икәнне белүчеләр хәтта шалтыратып котладылар ул вакытта. Күрәсең, «Рубин»ның финанс хәле мактанырлык түгел, югыйсә шундый шәп уенчыларны башка клубларга «сатмаслар» иде. Ә яхшы уенчылар булмаса, яхшы тренер үзе генә капкага туп кертә алмый. Европа чемпионатларында, Чемпионнар лигасында катнашкан, җиңгән команда бит ул «Рубин»!

Китәләр...

Соңгы айларда без яшәгән чорның символы булырлык шәхесләр арабыздан китте. Дмитрий Хворостовский, Владимир Шаинский, Леонид Броневой – болар бит үзләре бер дәверне гәүдәләндерә торган шәхесләр. Андыйлар йөз елга бер генә туа. Кызганыч, моның шулай икәнен алар вафат булгач кына аңлыйбыз.
Шулай ук 8 тапкыр Олимпия уеннары чемпионы, 11 тапкыр Дөнья чемпионы Хөсәен Болт спорттан китүе турында хәбәр итте. Исән генә булсын...

PRESSA.RU



СЕБЕР – ҮЗЕБЕЗНЕКЕ!

ГОМЕР БУЕ БЕРГӘ БУЛДЫК, БҮГЕН ГЕНӘ АЕРЫЛМЫЙБЫЗ... КИЛЕНДӘШЛӘР ШУЛАЙ КАРАР ИТТЕ – БЕЗ РИЗАЛАШТЫК.



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Тышлык турында әйтүем. Чынлыкта, дүртәү әле алар: бертөрле фикерләр, бер үк уй-ниятләр, хыяллар белән яшәп ятучы Рәшидә һәм Фазыл, Гөлфия һәм Миндар ӘГЪЛӘМОВлар. Алар турында бер-берсеннән аерып ничек сөйлисең?!
Әгъләмовлар җитәкләгән «Техтранссервис» компаниясе Сургутта гына түгел, бөтен Себергә, хәтта Россиягә билгеле. Ханты-Мансийск һәм Ямал-Ненец автономияле округларындагы эреле-ваклы мең ярымнан артык оешманы, «Сургутнефтегаз», «Газпром», «Роснефть», «Төмәнэнерго», «Лукойл-Көнбатыш Себер» кебек зур берләшмәләрне дә машина һәм тракторлар өчен запас частьлар белән алар тәэмин итә. Сургутта Әгъләмовларның «АвтоГалактика» кибетләрен табарга теләсәң, «Татарлар» кайда?» – дип кенә сорарга кирәк, юлны күрсәтәчәкләр. «Татарлар» кушаматы үзебезгә ошый, әмма шул ук вакытта җаваплылык та өсти – безнең аша милләткә бәя бирәләр», – ди алар.



Фото: Юлия Сажнева

Килү

– Әни безне – киленнәрне үз кызлары кебек күрде. Каядыр барырга җыенсак: «Матур киендегезме, ясандыгызмы?» – дип сорый иде гел. «Хатыннарыгыз ялт итеп йөрсен», – дия иде улларына. Әни – Бәркәтәнең Нурислам бай кызы. Әтисен 1921 елда Ташкентта икмәк алып кайтырга барган җирдән үтергәннәр. Безнекеләрнең канындагы малтабарлык шул тамырлардан киләдер... Әни, яшьли тол калып, җиде баланы аякка бастыра. Үткен, зирәк, акыллы хатын иде. Авылда күпләр аңа эч серен сөйләргә, киңәш сорарга йөрде. Балаларының гаҗәеп туган җанлы булуында да әнинең өлеше бик зур. Уртак эшләре булганга гына болар дүртесе якыннар дип уйламагыз – без һәрвакыт барыбыз бергә.

Сургутта алар берара биш туган яшиләр. Иң элек Фәргать җизнәләре белән Асия апалары килеп урнашкан. Алар янына – калганнар.

Гөлфия белән Миндарны да үз куышлары булганчы – «вагонка» тактадан йорт (заманасы өчен – коттедж!) салып чыкканчы Рәшидә белән Фазыл сыендыра. Бер ел бер гаилә булып яшиләр. Хәер, нигә бер генә ел?! Башта фатирлары янәшә була, инде менә йортларының тәрәзәләре бер-берсенә карап тора: бер капкадан икенчесенә кадәр нибары унбиш адым. Күңелләр исә тагын да якын! Рәшидәләрнең Илдарлары белән Рамиләләре дә, Гөлфияләрнең Айдарлары да: «Безнең ике әти, ике әни бар», – дип үскәннәр.

Яшермиләр – алар барысы да монда тайга исе иснәргә дип түгел, зур акчалар эшләргә, аякка басарга дип килгән. Тик килү белән зур акчаны кайда бирәләр?! Менә ни өчен Фазыл, дипломын өстәл тартмасына салып, ул чакта экскаваторга утыра, шофер да була.

Миндар Әгъзам улы, гади мастердан башлап берләшмәнең өлкән инженеры вазыйфасына кадәр күтәрелә. Аның кул астында мең ярымнан артык эшче була. Абыйсы – башта гараж, аннан ремонт остаханәләре башлыгы булып эшли, профсоюз оешмасын җитәкли. «Сургутнефтегаз»да эшләгән еллар – безнең өчен тормыш мәктәбе булды», – диләр.

Үз эшеңне башлау өчен бар яктан да өлгереп җиту кирәк...

Беренче адымнар

– Дүртебез дә «Сургутнефтегаз»да эшләдек, акцияләребез бар иде. Шуларны саттык. Эшләп киттек... Гөлфия беренче көннән үк безнең белән булды. Бухгалтерия эше аның өстендә иде. Бер кулы белән бала карый, аш пешерә, икенчесе белән исәп-хисап кәгазьләрен алып бара. Бераздан компьютерлы булдык. Берсендә, балалар уйнап, Гөлфиянең бөтен язуларын юкка чыгарды... 2000 елда банкротлыкка чыккан бер оешмадан шушы базаны сатып алдык. Бер тиен акчабыз калмады. Базада ут, су өзелгән, тәрәзәләр юк иде, әмма бездә шатлык!

Складларга читтән кешеләр ала башлаганчы, товарны алар әле озак вакыт үзләре җибәреп тора. Чиратлашып командировкага йөриләр: Чаллы, Түбән Новгород, Самара, Тольятти... Туксанынчы еллар бу. Куркыныч вакытлар. Товар төягән машина белән юлда туктап ял итәргә дә ярамый – талыйлар. («Бервакыт бик йокы килгәч, төнлә урман эченә кереп туктадык, – дип искә төшерә Миндар Әгъзам улы. – Иртән уянсак, алда да тәреләр, артта да... Зиратта төн кичкәнбез... Коймасы булмагач, кая барып кергәнне абайламаганбыз».) Барысы да була: аталар да, әзәрлеклиләр дә, куа да киләләр. Тик Ходай ташламый!

– «Крыша» өчен түләү заманы иде. Без беркайчан, беркемгә түләмәдек, – ди алар. – Тапкан малыбыз хәләл: элек тә шулай иде, хәзер дә. Берәүне дә алдамыйбыз. Машина хуҗасының ремонтка акчасы күп китә икән, ул чит ил машинасына күчәчәк – аны бөтенләйгә югалтачакбыз. Сыйфат – безнең өчен язылмаган беренче кагыйдә.

Язылмаган кагыйдәләр

Әгъләмовларда алар байтак.

Эш барсын дисәң, кул астындагыларга үзең үрнәк күрсәтергә тиешсең. Менә шуның өчен бөтенесеннән дә алда – иртәнге җидедә эшкә килеп, кичке җидедә генә китәләр.

Җитәкче: «Бөтен нәрсәне беләм, барысына ирештем», – дип уйлый икән, предприятие үсүдән туктый. Бу хезмәткәрләргә дә кагыла. Яңа эшкә урнашкан кеше укудан, яңалыкка өйрәнүдән беркайчан баш тартмый аларда: имтиханның чираттагысын биргән саен, хезмәт хакы өстәлә бара.

Эштә туган-тумачалык булырга тиеш түгел, таләпләр дә, шартлар да һәркем өчен бертигез. (Гөлфия белән Миндарның Мәскәү Югары икътисад мәктәбен тәмамлап кайткан уллары Айдар күптән түгел маркетинг бүлегендә эшли башлаган. Аңа берәү дә аерым кабинет әзерләмәгән.)

PRESSA.RU



Әгъләмовлар туган авыллары Әмирдә «Авыл көне»н инде биш ел рәттән оештырганнар. Шушы бәйрәмгә туры китереп, авылга инде туган яктан тамырлары өзелгәннәр дә кайта башлаган.

«Яшисе килә», – диючеләргә генә таянырга ярый. («Бер яшь гаилә эшли бездә. Егетнең әнисе безнең белән уйнап үсте. «Яшәмә келисезме?» – дип сорыйм шунын хатыныннан. Чистай мишәре ул кыз. «Юк, без яхшы яшәмә келибез!» – ди. Әйбәт машина, фатир дип хыялланса гына ул кеше белән эшләп була. Максатлы кеше генә тырыша».)

Һәркем күреп тора: байлык аларга күктән төшми.

Син үзең генә түгел, янәшәңдәгеләр дә баерга тиеш. («Бер мәҗлестә Миндар Әгъзамовичның: «Аллага шөкер, безнең балаларның барысы да фатир алды инде. Берне генә түгел, икене, өчне», – дип куанып сөйләвен ишетеп калдым. «Безнең балалар» дип, үзләрендә эшләүчеләр хакында әйтүен аңлагач, күзләремә яшь килде», – дип сөйләгән иде Сургуттагы бер танышым.)

Без – хуҗа түгел, җитәкчеләр. («Кул астында эшләүчеләр өчен без хуҗа булсак, алар кол буламыни?!»)

Һәркемгә хезмәтенчә түләнергә тиеш. («Ай саен, дүртәү утырып, хезмәт хакларын карап чыгабыз: кемнең сатуы күбрәк булган, кем имтихан биргән, ипотека алырга җыена... Рәшидә белән Гөлфияне бездә эшләүчеләрнең адвокатлары диярсең – алар сүзен тыңласаң, бар тапкан акчаны хезмәт хакына биреп бетерергә кирәк».)

Хезмәттәшләр

Лариса Солтан, склад мөдире: «Милләтем буенча мин – молдаван, әмма үземдә эшләүче Татарстан егетләре белән күптән: «Хәерле иртә!» – дип исәнләшәм. Татарча күп нәрсәне аңлыйм. «Техтранссервис»та инде 16 ел эшлим. Идән юучы булып кына урнашкан идем. Бераздан контроль-сак хезмәтенә алдылар, аннан складта эшләргә тәкъдим иттеләр. Куркып кына тотынсам да, өйрәндем. Ул чакта әле складта Фазыл һәм Миндар Әгъзамовичлар белән янәшә торып эшләдек. Бик таләпчән җитәкче алар: үзләре дә җигелеп эшли, бездән дә шуны көтә. Алар акыллы, зирәк булганга, кыска гына вакыт эчендә компаниябез Себергә танылырга өлгерде. (Ассортиментыбыз зур – 100 меңнән артык исемдә! Көн аралаш, товар төяп, Когалым, Нефтеюганск, Ханты-Мансийск шәһәрләрендә урнашкан филиалларыбызга машиналар чыгып китә.) Регионда көндәшләребез юк: күпләр, кризис башлангач, бөлгенлеккә төште. Ә бездә бер тапкыр да хезмәт хакы тоткарланмады!

Мәктәптә яхшы укысам да, әни иртә үлеп киткәч, институтларга керә алмадым. Директорлар минем бу хыялымны тормышка ашырырга ярдәм итте – укыттылар, хәзер мин югары белемле икътисадчы. Сеңлем дә биредә эшли, аңа да югары белем алырга булыштылар. Барыбызга карата бик игътибарлы алар: һәр көнне иртән складларны йөреп чыгалар һәм һәркем белән кул биреп исәнләшәләр! Барыбызны да таныйлар: кайда, ничек яшәгәнебезне, кемнең ипотекасы, кредиты барын беләләр, кирәк икән, ярдәм итәләр. Әти-әни кебек... Шуңа күрә барыбызның да директорларның ышанычын аклыйсы килә. Бүгенге көнем өчен аларга рәхмәтлемен: фатирыбыз менә дигән, өч балабыз үсә. Гаиләгә иң зур акчаны мин алып кайтам, аны ирем дә белә. 44 көн түләүле ял Себердә дә күп оешмаларда юк хәзер – бездә бар. Ялга туган якка кайту өчен билет хакы да түләнә. Төшке ашны бушлай ашыйбыз».

Алинә Гарфиева, маркетинг бүлеге белгече: «15 ел элек әтиемне югалткан идем. Директорыбызны әти кебек күрәм. Мин генә түгел, күпләр... Проблемам булса, аларга керә алганымны һәм ярдәмсез чыкмаячагымны беләм. Кайдан һәм кайчан фатир алырга, нинди машина сайларга – тәҗрибәләре зур, боларның барысы хакында да алар белән киңәшәбез. Эш өчен бөтен шартлар тудырылган: вахта белән алып киләләр, кайтаралар. Туган көннәребез белән котлыйлар, чәчәкләр һәм конверт бүләк итәләр, хәтта декрет ялында утыручыларга да. Безнең өчен бик матур бәйрәмнәр оештыралар. Балаларга Яңа ел чыршылары үткәрәләр, аларны бүләккә күмәләр.

Иртән – бер, төштән соң тагын бер мәртәбә складларны йөреп чыга Миндар Әгъзамович. Безнең бүлеккә дә кермичә калган көне юк! «Миннән берәр ярдәм кирәкмиме?» – аның иң беренче соравы шул».

Мәчет

– Эшебез бара, табыш килә, әмма күңелдә канәгатьлек юк... Абзый да: «Яхталар, чит илдә йортлар кирәкми безгә, милләт өчен нидер эшлисе иде», – дип уйлап йөргән икән. Һәрвакыттагыча дүртәү утырып киңәшләштек тә, туган якта мәчет салырга булдык. Бер кайтуда махсус Казанга, Диния нәзарәтенә киттем – мәчет өчен проект кирәк иде. Алар булышыр дип уйлыйм бит инде. Җомга көн иде ул. Камил хәзрәт Сәмигуллин үзе юк диделәр, урынбасарларын көтәм – ишек төбеннән эчкә уздырмадылар. Менә баскычта миңа кирәк кеше күренде. Ярдәмчеләре әйткәч, туктады, баскычтан төшмичә, өстән генә: «Ни йомыш?» – диде. Аңлаттым. «Мин проектлар белән шөгыльләнмим», – дип, кире

борылды. «Туктагыз инде!» – дим. Ул тагын: «Ни йомыш?» – дип кабатлады. «Мин йомышчы малай түгел, 40–50 миллионга чиркәү салырга җыенам дип барсам, поплар, мөгаен, кулларында гына күтәреп йөртерләр иде...» – дидем. Шушы сүзләремнән соң, бер телефон номеры бирде, әмма анда да ярдәм итүче булмады...

Мәчетнең эскизын ул башта үзе сыза (Казан авиация институтының конструкторлар әзерләү бүлеген тәмамлаган егет ләбаса!) Бөгелмәдәге бер танышлары проектны эшләп бетерә. Чирмешән район үзәгендә төзелүче бу мәчет әниләре Мөшбикә исемен йөртәчәк.

– Кирпечне Башкортстаннан кайтарттык, нигезен бизәргә дигән таш – Уралдан... Инде эчке эшләре генә калды. Материалларның иң яхшыларын гына сайларга тырышабыз. Быел гаеткә ачылыр, дип торабыз. Ихлас, иманлы имам эзлибез менә... Бу урынга күңелебезгә хуш килгән кешене тапсак, аңа йорт салып бирербез...

Тел

– Дин сакланыр, ә менә тел... Туган тел өчен борчылабыз бүген...

Татарстанны, бөтен татар дөньясын күз алдында тотып әйтүләре. Үзләрендә – «Техтранссервис»та – бу мәсьәләдә тәртип аларның! Киңәшмәләр вакытында әледән-әле татарчага күчеп китү биредә гадәти күренеш: күпләр, сөйләшмәсә дә, сүзнең ни хакында баруын аңлый. (Склад, кибетләрне карап, йөреп чыктык – безне һәркайда: «Исәнмесез!» – дип каршы алдылар. «Монысы – әрмән егете, монысы – рус, яһүд, үзбәк, кыргыз, – дип таныштыра Фазыл Әгъзам улы. – Кайткан саен Казаннан 20–25 «разговорник» алып киләм – сорыйлар».)

– Татарлар, балаларына исем кушканчы, башта кереп, безнең белән киңәшләшәләр. Сабыйларына матур, чын татар исеме кушучыларга премия язабыз... Кешенең исемен бозып әйтү гадәте юк бездә. Нинди генә авыр булса да! Бервакыт Динар исемле егет: «Өлкән сатучы миңа Дима дип дәшә», – ди. «Ә син аңа Наил Васильевич, дип әйтеп кара», – дидек. Тегесе бик аптыраган инде. «Ә миңа шулай әйтергә җиңел», – дигән Динар. Николай Васильевич шунда ук аңлаган...

Җәмил Шәрифуллин – бер урамда үскән авылдашлары. Бик озак еллар Бөгелмәдә яшәгән, соңгы ун елда аларда шофер-экспедитор булып эшли. «Улым Когалымдагы филиалга урнашты. Аның белән телефоннан татарча сөйләшәбез хәзер. Монда килгәч өйрәнде», – ди.

Авыл

Туган авыл Әмир – Әгъләмовларның тагын бер «баласы». Юк, Анасы! Туксанынчы еллар башында, шушында кайтып төпләнергә, җирдә эшләргә телибез, дип, Чирмешән районы башлыгына керәләр, әмма аларны кире боралар. (Әгәр шул чакта рөхсәт алсалар, республикабызның бу төбәге нинди булыр иде икән бүген?!)

– Бөтен уңайлыклары булган йорты булса, яшьләр авылда төпләнә ул. Хөкүмәт аларга йорт салырга булышсын иде, без дә ярдәм итәр идек...

Әлегә алар кулдан килгәнне эшли тора: баласы туган һәр яшь гаиләгә йөзәр мең сум акча бүләк итә. (Бер елны Әмирдә бер бәби дә тумаган – акчаны мәктәпкә тапшырганнар.) Мәктәпкә беренче тапкыр баручыларга да, аны тәмамлаучыларга да Сургуттан ук бүләк төяп кайталар. Боларның барысын да үзләре оештырган Сабан туенда – Авыл көнендә сәхнә түренә чакырып тапшыралар. Халык алдына шушы елны гомер бәйрәмнәрен билгеләп узучы абый-апаларны да чыгаралар. Гомер буе колхозда эшләп тә, үзләре әйтмешли, бер рәхмәт ишетмәгән өлкәннәр өчен Себердә яшәүче якташлары кулыннан бүләк алу, аннан бигрәк, җылы сүз ишетү зур вакыйгага әйләнә. Тол калып, ике баласын ялгыз аякка бастырган Гайшә апа әнә, дулкынланып, соңыннан бер атна чирләп яткан...

Әмир авылы яшәсен, үссен иде...

Туган авыл белән ике арага тузан кундырмыйлар. Анда – ике гаиләгә уртак йорт: җәйгә чиратлашып кайталар, бакча үстерәләр. Эш сорап килгән авылдашларын кире бормыйлар: таләп һәркемгә бер – тырышып эшләргә, эчмәскә, тартмаска, урламаска... (Хәер, соңгылары – предприятиедә, гомумән, булган хәл түгел.)

– Конфет ашап үсмәдек без... Җиде бала, юклык... Әти сугыш инвалиды иде – фронтта алган яраларыннан мантый алмый вафат булды. Дүртенчедә генә укый идем әле... Кибеткә хәлвә кайткан. Ялтыравыклы кәгазь белән тышланган. 36 тиен тора. Ул чакта зур акча! Өч шешә табып юып, тапшырдым да алып кайттым хәлвәне. Өйдә берүзем ашап утырам. Абзый күрде дә сорый башлады. Бирмәдем! Туйсам да, ашап бетердем. Соңгы кисәкне йоткач, күңелне үкенү биләп алды: «Нигә бүлешмәдем инде?!» Шуннан бирле хәлвә ашый алмыйм... Тормышта төрле хәлләр килеп чыга. Кемгәдер карата нәрсәнедер дөрес эшләмим кебек тоелса, тамагыма һәрвакыт шул хәлвә тыгылгандай була. Ул мине бүген дә ялгышлардан саклый...

«Техтранссервис» компаниясенең генераль директоры Миндар Әгъләмов сөйли моны.



■ Алия һәм Илсур Җиһаншиннар – авылдаш абыйлары кулыннан 100 мең сум акча алган бәхетле гаиләләрнең берсе.

PRESSA.RU









КЫШКАР ЙОЛДЫЗЫ



Лилия ГӘРӘЕВА

Ул безнең кумирыбыз иде. Гадәттә, авыл кызлары җырга хирыс була. Безнең кумир җырламый, ул – бии иде. Әле ниндиен диген?! Һинд биюен! Нәкъ Хема Малини инде! Клубта концерт булса, без, авылның яшүсмер кызлары, иң беренче төшеп утырабыз. Менә берзаман сәхнәдә ут сүнә, тәннәрне чемердәткән һинд көе башлана. Түшәм матчасына эленгән кызыллы-зәңгәрле лампочкалар көй тактына бер янып, бер сүнеп, сәхнәгә серлелек өсти. Тын да алырга онытып, Ләйсән апаның биюенә «чумабыз». Күз алдына Шридеви, Рекхалар килеп баса. Ләйсән апаның сөйгәне Фаиз абый (аларның гаилә коруларына да хәзер чирек гасырдан артык инде) безгә Митхун Чакрабортиның үзе булып тоела. Ул да аның кебек кара бөдрә чәчле, шундый ук зифа буйлы чибәр егет.

Быел Ләйсән Шәфигуллинаның Кышкар клубында эшли башлаганына утыз бер ел. Мәктәпне тәмамлаганда, авылда калырмын да клубта эшләрмен диген уе булмый югыйсә. Укырга китәм дип йөргәндә әтиләрен Чернобыльгә чакырып, повестка килеп төшә. Абзар тулы мал-туарны, бөтен тормышны бер әниләренә калдырып китсенме? И сөенә авыл Советы рәисе аның авылда калуына: «Кырык ел клуб мөдире булып эшләгән Үлмәскамал апа, урыныма кеше тап, дигән иде, әйбәт булды әле!»

Минем бу тынгысыз җан турында күптән язасым килә иде, кыймый тордым. Аның бөтен эшен колачларлык сүзләр таба алмам, дидем. Максатым аның бәхетле тормышын да (ә ул чынлап та бик бәхетле хатын-кыз!), инде үзләре гаиләле ике кызын да, нәрсәгә алынса, шул эшендә ярдәм итүче ире Фаиз абыйны да язу түгел. Үзе дә уен-көлкеле, киленгә булышмый булмый дип, кирәксә, кулына гармун алган, кирәксә, машинасын кабызып чыккан кайнатасы Тәлгать абый да, концертка Казаннан кунаклар да кайтасы дип, кичкә ашын куеп торган кайнанасы Дания белән әнисе Илсөя апа да, ул спектакленә нинди декорацияләр кирәк соң, дип, балта-пычкысына тотынган әтисе Җәүдәт абый да кермәс әле бу язмага. Максатым – Ләйсән Шәфигуллинаның эшен күрсәтү. Югыйсә клуб мөдире белән китапханәченең эшен авылда эшкә дә санап бетермиләр бит әле ул. «Күтәрми, төшерми, җырлап-биеп тик йөри», – диләр. Хәер, безнең Ләйсән ханым турында берәү дә болай әйтмәс. Кайдадыр клуб хәтта ачылмаган да заманда, Арча районының кеп-кечкенә Кышкар авылында елына өчәр спектакль, бәйрәм саен концерт куелу эш түгелмени?! Авыл бәйрәме, балалар Сабан туе, Нәүрүз, Уңыш бәйрәмнәре... «Иң кызык бәрәңге», «Иң зур кабак» күргәзмәләренә кадәр үтә бездә.

Хәтер йомгагын бер сүтеп, бер җыеп, Ләйсән апа белән үткәннәрдән урыйбыз. Кино кадрлары кебек, бер якка чүңкәйгән, шулай да тормыш кайнап торган иске клуб (борынгы мәдрәсә бинасы!), авылымның җор телле абый-апалары уза. Һәр хатирәсе – күңел дәфтәренең бер бите, кәгазьгә түгел, йөрәккә язылган көндәлекләр.

«...1987 елның ноябрь ае. Авыл яшьләре белән «Октябрь бәйрәме»нә әзерләнәбез. Артистлар ягыннан кыенлык юк анысы, авылда һәр ике кешенең берсе – гармунчы, икенчесе – җырчы. Сәхнәгә киеп чыгарга күлмәк тапсаң, җырлыйбыз, дип кенә торалар. Анысын гына җайларбыз, тирә-якта бай колхозлар күп, клубларында матур костюмнар булмый калмас».

Концертка дип килгән халык башта әле клубның үзен күреп «аһ» итә. Сырт-сырт калҗайган идәннәре – типтигез (әтисе ничә көн тырышып фанера җәйде бит аңа), тәрәзәләрдә – яңа пәрдәләр (өйдән алып төшкән)!

Әйбәт уза концерт. Хәлил Садыйров Казаннан бик матур ботинка киеп кайткан икән, үзе җырлап керә дә, тиз генә салып, икенче «артист»ка бирә. Зур булмасынга башына мамык тутырып, Айрат та киеп җырлый аны, Рафил дә... Унбер терәүле (бер килгәнендә Алмаз Хәмзин, сезнең клуб колонналы икән, дип шаярткан ди) дүрт мичле иске клуб тәрәзәләре алкышлардан зеңләп тора. «Абау, Ләйсән, маладис!» – дип таралыша авыл халкы.

«...1988 елның марты. Яшьләр белән Юныс Әминевнең «Язылмаган законнар»ын куярга йөрибез. Яшьләр дигәч тә, гел яшьләр генә түгел, арада Һиндия, Рәхимә, Әнисә апалар да бар. Иренең Әнисә апаны чыгарасы килми. И юмалыйм үзен: «Син бигрәк әйбәт кеше инде. Иң матур хатын синеке. Фәлән апаның шундый уйныйсы килә – ире чыгармый, син андый түгел, – дим. – Беренче рәттән урын алып калырмын үзеңә». Шулай дигәч, ризалаша тагын. Инде барысын да җайлап бетердем дисәм, тагын берсенең әнисе турсая: «Ашлык тарттырасы бар дип, шул бер шимбәне көтеп торган идек. Эш вакытында нинди театр, ди, тагын?» Бар булган сәләтеңне салып, хәзер аңа «тәмле» телләнәсең: «И, фәлән апа! Синең малаең кебек авылда тагын кем җырлый! Аннан башка ничек спектакль куеп булсын инде?» Кайсын ничек юмалап, артистларны тупладым. Әле аның белән генә эш бетми шул, һәркемнең уңай роль башкарасы килә. Үлә торган да булмасын, тискәре дә булмасын... Үпкәләшкә калмасын дип, рольләрне жирәбә сикертеп бүлештек. Авыл халкы бит ул һәр спектакльне чын-чынлап кабул итеп утыра. Әнә усал киленне уйнаган Әлфия һәм аның явыз анасын уйнаган Рәхимә апа белән икенче көнне исәнләшмәгәннәр дә.



«Ике кызым – ике куанычым. Олы кызыбыз Чулпан медицина юнәлешен сайлады – Казанда шәфкать туташы булып эшли. Кечесе Йолдыз – икътисадчы».

«Зөбәрҗәт»ләр авылда гына түгел, районда бер ул безнең. Кая чакыралар – төяләбез дә китәбез.

Яңа клубка күченгәч, бу спектакльне кабаттан куеп, элек уйнаган «труппа»ны кунакка чакырдык. Чакырдык, дим, чөнки мин үзем генә түгел. Ничә еллар инде уң кулым булган китапханә мөдире Гөлнара Ибраһимова бар. Җырга дисәң – җырга, сүзгә дисәң, сүзгә оста Радик Хәйретдинов, Эльмира Исламовалар бар. Яңа Кишеттән ике Надия (берсе – Йосыпова, берсе – Сәлахиева) менә, Симетбаштан Зилә Шәрәфиева төшә...»

Әйе шул, Кышкарда клуб яңа хәзер. 2002 елда борынгы мәчетне төзекләндергәч, иске клубны сүттеләр.

«...Клубны трактор белән су буена эттереп төшерделәр. Аның гасырлык бүрәнәләреннән чыктымы ул, минем йөрәгемнәнме – иңрәү тавышы килде. Үзем юган

PRESSA.RU

иске тәрәзә өлгеләренә кадәр ничек кадерле. Егерме чиләк брикет яксаң да идәнендә су ката торган шушы клуб ничә буынның яшьлек эзләрен саклады. Декорацияләр, костюмнар белән кечкенә генә китапханәгә сыендык. Клуб юк, дип булмый, эшләргә кирәк.

23 февральгә Әнгам Атнабайның «Ул кайтты» пьесасын куярга булдык. Ләүкә кадәр генә сәхнәгә ярты декорациябез сыймады да. Артистлар үз күренешләрен уйнагач, залга төшеп, мич артына качып тора иде. Йорт саен дигәндәй кереп, сәхнә күренешләренә әйбер җыйдым. Кемдә борынгырак өстәл бар, кемдә комод... Башка авылларга да күрсәттек аны.

Бу спектакльне видеога да яздырган идек. Клубка сыймаган кеше видеоязмадан карады. Үзеңне экраннан күрү кызык икән: күзгә иң беренче булып кимчелегең ташлана. Пәрдә артыннан кемнең аягы чыгып тора ул? Ә монысы көлмәгән алыштырырга оныткан!»

Авыл клубы мөдиренең тормышы әнә шундый күңелле дә, матавыклы да. Клуб эше генә түгел, үз хуҗалыгында да эше җитәрлек аның. Өстәвенә, төп йорт килене дә бит әле ул. Ә төп йорттан кунак өзелми. Кичен сыерын савып, бакчасына сулар сипкәч, эше бетте түгел, клубны ачып, яшьләргә дискотека оештырасы, берәр яңа чарага әзерләнә башлыйсы...

Дискотека димәктән, без, Кышкар яшьләре, күбебез Ләйсән апа мәктәбен узучылар. Һәркайсыбызны, «колагыннан сөйрәп» дигәндәй, сәхнәгә чыгарган, сәләтең бар, дип канатлар куйган, хәтта ярлар сайларга да өйрәткән дустыбыз да, сердәшебез дә булды ул.

Ләйсән апа белән Гөлнара Ибраһимова авылыбыз өчен тагын бер зур эш башкарды – Кышкарның тарихы, шушында туып-үскән, колхозда эшләгән кешеләр турында «Бар Казан артында бер авыл – Кышкар диләр» дигән китап бастырып чыгардылар.

Биергә әтием өйрәтте. Ул гармун уйный, апа белән без икәү биибез.

«...Авылдашыбыз Мәҗит абый Вәлиев кайткан. 30 нчы елларның корбаны булган нәсел баласы ул. Авылның элеккеге планын ясаган. Кызыксынып киттем. Безгә кадәр дә әллә кемнәр яшәгән, тырышкан, көч түккән. Авылдашларның һәркайсыннан сорашып, истәлекләрен, нәселләре тарихын барласак...»

215 биттән торган китап 2015 елда дөнья күрде. Китапның консультант-редакторы – күренекле авылдашыбыз, академик Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов.

Яңа елда кунакка кайткач, күктән ак энҗеләр коелган бер кичтә, яшьлек эзләремә баса-баса, клубка чыктым. Ләйсән апа, гадәттәгечә, эш урынында – авылга кунакка кайткан балалар өчен Чыршы бәйрәме уздыру хәстәре белән йөри иде. Сөенечле хәбәр белән каршы алды ул мине: клуб каршында эшләүче «Нур» драма театрына халык театры исемен биргәннәр. Килешәсездер, һәр авылда юк бит халык театры. Ә менә безнең йортлар саны йөзгә дә тулмаган авылыбызда бар!

«Ничек барысына да җитешәсең?» – дим, урын өстендәге кайнанасын да багуын истә тотып.

– Өендә тынычлык булгач, җитешәсең. Әгәр дә Фаиз урынында башка бер кеше булган булса, болай күңел биреп эшләп йөри алыр идемме? Минем ярты төнгә кадәр эштә югалуыма да, клуб өчен дип районга әйдәкләвемә дә бер авыр сүз әйткәне юк аның. Клуб кирәкярагына айлык хезмәт хакым кереп китүенә дә күз йома. Бригадир булгач, халык алдында сүзе дә үтә. Ни ялынып та тыңлата алмаганда аны җибәрәм.

Шушы урында язмамны тәмамласам да буладыр дисәм, әле тагын мөһим эшләре керми каласы икән. «Зөбәрҗәт»ләр турында ишеткәнем бар иде инде. Авылыбызның җырга-биюгә оста апа-абыйларыннан тупланган фольклор иҗат коллективы ул.

– Мөршидә апа Сафина, Һиндия апа Фазылҗанова, Фоадия апа Чубаева, Әнисә апа Зарипова, Фарук абый Хәйретдиновлар (унбишләп алар, барысын да санау мөмкин түгел) – гомерләре буе сәхнәдә. Элеккеге җырларны, кичке уеннарны, гореф-гадәтләрне алардан да яхшы белүче юк, шуларны сәхнәләштереп, халыкка күрсәтсәк... Берзаман бу йолаларны белүче дә калмас бит. «Сөннәт туе», «Угыз коймагы» күренешләре әнә шулай туды. Клуб мөдиренә фольклор җыючы да булырга туры килә. Авылның өлкән кешеләреннән әллә никадәр халык авыз иҗаты тупланды. «Сөннәт туе»на имләүләр дә: «66 ала күз, 47 кара күз, сокланып караганның сыны катсын...» борынгыларның балаларга өйрәткән уеннары да: «хәзер чәчү чәчәбез, чәчкән җирләр үсә бара, хәзер ашлык урабыз...», тизәйткечләр дә: «бер дидем бермәк, ике дидем икмәк...», сөннәтләнгән балага күчтәнәч-бүләкләр алып, хәл белергә килүләр – барысын-барысын да кертергә тырыштык.

Ләйсән апаның тагын бер зур хыялы бар. Яңа йорт та, яхшы машина да, затлы кием-салым да түгел, ә ... авылның музеен төзү турында хыяллана ул.

– Клубта шактый күп истәлек тупланды. Кайсыдыр спектакльгә кемдер биргән бишек тә, чигүле эскәтер, чулпылар да бар. Үзем пенсиягә киткәч, югалыр инде болар дип, кечкенә генә бер музей ачарга хыялланам. Әле әти (кайнатасы – *авт.*) исән вакытында бу ниятемне бик хуплый, кайда нинди борынгы әйбер таба, Ләйсәннең музеена дип күтәреп кайта, хәтта җир казыганда борынгы кадак чыкса, аны да җыеп куя иде. Үзем дә авылдашларда сакланган иң борынгы фотокарточка, иң борынгы беләзек, борынгы эш коралларын барлап, туплап килдем. Клубта сакланган элеккеге күлмәкләр, борынгы чигү үрнәкләре, камзуллар, картуз кепкаларны бер музейга җыйсак...

Юк, никадәр тырышсам да, Ләйсән апаның бар эшен колачлый алмадым. «Газиз чишмәсе»н ачулары, авылыбызның һәр егетен армиягә озату кичәләре – һәрберсе күңел көндәлекләренең берәр сәхифәсе. Ничек кенә тасвирласам да, ул бәйрәмнәрнең рухын сурәтли алмам мин. Сез үзегез кунакка килегез безгә. Җәй көне килегез – Авыл бәйрәменә. Утызынчы Авыл бәйрәменә!

ҖӘННӘТ... ИРЕҢНЕҢ АЯК АСТЫНДА

Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы



Иләһи нherият кылдым

Ирләрнең хатыннары алдында нинди бурычлары бар?

– Гомумән алганда, гаилә корганда, ир кеше дә, хатын-кыз да беренче чиратта: «Минем бурычым нидә?» – дип, үз бурычлары турында уйларга тиешләр. «Үземә йөкләнгән вазыйфаны тулысынча үти алырмынмы?» – дип борчылырга. Гаиләдәге проблемалар белән миңа да күп киләләр. «Ирем моны эшләми, моны үтәми», – диләр. Мин аларны туктатам: «Башта үзеңнән башларга кирәк, – дим. – Бәлки син нәрсәнедер җиренә җиткереп үтәмисеңдер һәм, шуңа җавап итеп, ирең дә нәрсәнедер эшләмидер?» «Ирем йөри, икенче хатын алырга тели», – дип, күз яше түгүчеләргә дә: «Ашыкмагыз әле, – дим. – Ә ул икенче хатында тапканны нигә сездә тапмаган? Бәлки ул сезгә үзенең теләкләрен, нинидир шикаятьләрен белдергәндер. Ә сез аны ишетмәгәнсездер?» Гадәттә, шулай булып чыга да. Дин буенча карасак, хатын-кыз өчен бик мөһим бер әйбер бар. Җәннәт – әниләрнең аяк астында, дибез. Ә хатын-кызның җәннәте – ире аяк астында. Кияүгә чыккач, хатын-кызның бу дөньяда төп максаты – иренең ризалыгын алу өчен тырышу. Пәйгамбәребез: «Әгәр бер кешенең кешегә сәҗдә кылуы рөхсәт ителсә, хатыннарның ирләренә сәҗдә кылуы фарыз ителер иде», – дигән. Менә шуннан күрәбез инде хатын-кызның ире алдында үзен ничек тотарга тиешлеген.

Хатын-кызлар моны үзләрен кимсетү дип кабул итмәсләрме?

– Әйе, хатын-кызның баш иясе килми. Әмма кирелегеннән ул үзе генә зыян күрәчәк... Пәйгамбәребез: «Ирләр буйсынганны ярата», – дигән. Ирең әйткән һәр сүзне йөгерә-йөгерә үтәү түгел ул буйсыну. Каршы дәшмәү, ирең кушканга, «ярар, яхшы, эшләрмен», дип тору. (Аны бәлки бүген эшләмәссең дә, бәлки иртәгә дә тотынмассың, ләкин иң мөһиме: син каршы төшмә, булмый, димә!) Төп кагыйдә буларак, өч нәрсәгә: ирлегенә, ирегенә һәм горурлыгына кагылмасаң, ир кеше хатын-кыз өчен бөтен нәрсәне эшләргә әзер. Әгәр инде боларга кагыласың икән, бу ир сине ихтирам итүдән, гомумән, сине хатын-кыз итеп санаудан туктый. Ул синдә көндәш күрә башлый: мәсьәләне икенче бер ир-ат белән ничек хәл итсә, монда да шулай – кул күтәрүдән дә тайчынмый.

Ир кеше гаиләдә тавыш чыгуын яратмый. Яхшы хатын – өйдә тынычлык булдыручы хатын ул. Ир-ат мондый гаиләнең кадерен белә! Ә инде хатын-кыз гаиләдә баш булып алып, үз сүзен сүз итәргә керешсә, ир кеше, гадәттә, аңа юл куя. Ярар, ярар, теләсәң нишлә – тавыш кына чыгарма, ди. Акчасын да кайтарып бирә, хатыны ни әйтсә дә ризалаша. Ләкин ул инде ир кеше булудан туктый – чүпрәккә әйләнә. Бервакыт хатыны да аңлый моны, әмма инде соң була.

Ир-ат хатын-кызны үзенеке итәр өчен өйләнә. Һәм ир кешенең шундый сыйфаты бар – үзенекен ул беркайчан ятларга бирмәячәк. Моны башка вакыт сиздермәсә дә, берәр афәт янаса, ирлеге уянып, хатынын саклаячак. Әмма саклыйсы, кадерлисе килсә генә – ул аңа якын булса гына!

Яхшы, ипле хатынга акчаны ул үзе алып кайтып бирә. Ни өченме? Чөнки ир кеше мактанчык – күпме эшләгәнен күрсәтергә ярата. Тавыш күтәреп, хәйлә корып торасы да юк. Дөрес, үз вазыйфаларын үтәмәүче ирләр дә бар. «Ирем акча алып кайтмый», – дип зарлана кайбер хатыннар. Әгәр торырга урының, ашарга-эчәргә ризыгың, кияргә киемең бар икән, димәк, ир кеше сине тәэмин иткән дигән сүз. Артыгын бирә алса – бирә, бирә алмаса, син аны сорап та, тавыш чыгарып, кимсетеп тә ала алмыйсың. Без малны, акчаны Аллаһы Тәгаләдән дибез.

Тагын бер мөһим әйбер бар – ир-ат матурлык ярата. Шуңа күрә аңа матур булып күренергә тырышырга кирәк. Өйдә теләсә ничек киенә алам, үземне теләсә ничек тота алам, дияргә ярамый.

Ирләрне берәр ничек үзгәртеп буламы-юкмы?

– Гомумән, берәүне дә: ирне дә, хатынны да үзгәртеп булмый. Халык мәкале: «Әнисенә карап – кызын, әтисенә карап – улын коч», ди. Әтисенә карыйсың да хәл итәсең: ул сиңа ошаса, аңардан канәгать булсаң, улына кияүгә чыгасың. Юк икән – кире уйлыйсың. Оекбашларын бер урынга куярга, уң кул белән ашарга өйрәтергә була, ә холыкны берничек үзгәртү мөмкин түгел! Әмма хатын-кыз ирне хәйләкәрлеге белән җиңә ала. Хәзрәткә бер хатын килгән дә иреннән зарлана, дога кылып, өшкермәссезме, дип сорый икән. «Ярар, – ди хәзрәт, – тик моның өчен миңа арысланның йоны кирәк булачак». Ирен бик тә үзгәртәсе килә бит инде хатынның, арысланнар булган җирдә ешрак йөри башлый ул. Ерактан-ерактан әйләнә – арысланнар моңа ияләшә. Бераздан аларга якынрак килә. Аннан инде арысланнарны ашата ук башлый. Җанварлар аңа шулкадәр ияләшәләр, якын итәләр, хәтта үзләрен сыйпарга да рөхсәт итәләр. Менә шул вакыт хатын бер арысланның йонын кисеп ала да инде. Кабат хәзрәткә килә: «Булды бу, инде өшкерәсезме?» – ди. Хәзрәт аңа елмаеп карый да: «Арыслан булып, арысланны кулга төшердең, ә ireңне буйсындыра алмыйсыңмы?» – ди... Чынлыкта, ир кеше зур бала кебек бит ул. Бала нәрсә ярата? Йомшаклыкны, матур сөйләгәнне, тәмле ашатканны, мактаганны... Үзенең йомшаклыгы, күндәмлеге белән хатын-кыз бик күп нәрсәгә ирешә ала. Аның төп көче – көчсезлектә. Ә бүгенге хатын-кызлар ирне аның үз коралы белән – таләп итеп, законга таянып, куркытып, тавыш күтәреп җиңәргә тырыша.

PRESSA.RU

ЛИЛИЯ – ГӨЛНЕҢ ЧӘЧӘГЕ

Эльмира ЗАКИРОВА

Мин аны ни өчендер Мария Шукшинага охшатам. Буйчанлыгы, чаялыгы өченме? Атаклы артистлар кызы булгангамы? Төрле амплуадагы рольләре, уңай энергетикасы өчендер, бәлки. Икесе дә бер үк яшьтә дә әле – 1967 нче елгылар… Тагын, тагын… Аларда авылча табигыйлек, ихласлык, гадилек бар! Без Татарстанның атказанган артисты Лилия Мәхмүтова белән Тинчурин театрында, грим бүлмәсендә утырабыз. Түрдә – тәрәзә, анда – кышкы сурәт. Як-якта көзгеле диварлар. Өстәл янында, көзгеләр каршында сөйләшеп утыру әңгәмәдәшемнең күңел дөньясын тулырак, түгәлрәк ача шикелле. Көзгеләрдә Лилия әллә ничә төрлегә төрләнә. Әле уйчан, әле шат, әле хыялый, әле җитди… Гаҗәпләнгән итеп тә күрәм үзен, сагынган итеп тә… Юк, ул роль уйнамый. Ул гадәти бер халәттә. Ул тудырган дистәләгән образлар минем күңел көзгесендә шулай чагыла.

Театрда, грим бүлмәсендә...

Син безнең өчен Гөлшаян да, Зәмзәмия дә, Әсма да, Зәлифә дә, Резидә дә... Дистәләгән хатын-кыз образлары! Ә шуларга Лилия чалымнары, Лилия холкы да күчә микән?

– Бәлки... *(Уйланып кала.)* Төрле образларга керергә тиеш артист кеше. «Эх, алмагачлары»нда мәктәп директоры Фәридә Рәисовнаны уйнап йөрим шулай. Шәле мәктәбе укытучылары спектакль карарга килде. Спектакльдән соң: «Нәкъ безнең мәктәп директоры кебек идең. Сөйләшүләр, бөтенесен кайгыртып чабып йөрүләр, чаялыклар... гел Миңзифа ападан алган сыман», – диләр. Танышларны, дус-ишләрне үземә күчерәм бугай шулай.

Мәктәп сочинениеләрендә киләчәктә кем булам дип яза идең?

– Кыз баланың өч төрле хыялы буладыр инде ул. Башта, кечкенәрәк чагында, башлангыч сыйныф укытучысына охшарга тырыша ул. Минем белән дә шулай килеп чыкты. Үсә төшкәч, берзаман бухгалтер булам дип йөри башладым. Авылда әниемнең энесе Әсхәтнең хатыны хисапчы иде. Чут төймәләрен шалтшолт китереп утыра... И күңелле тоела иде инде эше! Ә унынчы класска җиткәндә инде артист булам дип яза башладым...

...һәм университетның физфагына барып кердеңме?

– Минем физикага да әвәслек бар иде анысы. *(Елмая.)* Кайчакта Ренат, син бит физик безнең, дип шаярта. Әни бит... «Тәгәрмәч өстендә үтәр гомерең. Кияүгә дә чыга алмассың, балаң да булмас... Ярый ла миңа әтиең очрады!..» – дип, мине гел үгетләде.

Физфакны ташлап, театр училищесына керергә этәргән сәбәп булгандыр бит инде барыбер?

– Иптәш кызым Люция белән икебез дә театр дип хыялланабыз. Үзе дә пьесалар язучы Халисә апа Нигъмәтуллина безне Заһит Мәхмүди, Наил Касыймов, Фирдәвес Зарифлар белән таныштырды. Бергәләп театр түгәрәге оештырырга булдык. Ләкин егетләр репетициягә еш килә алмый – вакытлары юк. Үзебез белән уйнар өчен артистлар эзләп, театр училищесына киттек. 4 нче курста Илдус Фәиз, Рөстәм Юнысов, Ренат Әкбәров, Инсаф Абдуллалар укый икән. Җыенысы озын буйлы егетләр. Люция, Фәридә, мин – шулай ук озын буйлылар без. Шундый шәп труппа оешырга торганда гына, «Юк, кызлар, без инде укуны тәмамлыйбыз, 2 нче курсларга төшеп карагыз», – димәсеннәрме! Җәвит Шакиров килеп чыкты. «Мин өйләнгән кеше, вакытым юк, кичләрен эшлим, әйдәгез, яшьрәк егетләр белән таныштырам!» – ди. Барып керсә-ә-әк... Безнең җилкәбездән генә торган егетләрне күреп, тәгәри-тәгәри көлдек соңыннан! Артистлар минем әти кебек гәүдәле булырга тиеш кебек иде. Типаж дигән нәрсә дә бар бит әле... Нәкъ бер айдан инде шушы малайлар янына укырга килдем. Миңнегали Мөхәммәтшин, Мәхмүт Фатыйховлар группасына. 50 яшемне билгеләп үткәндә, егетләрнең үзләренә сөйләп көлдердем. Училищедагы укытучым Илдар абый Хәйруллин мине 2 нче курска алды. Язмыштыр инде. Шулай кирәк булгандыр. Мөгаен, Ренатны көткәнмендер. Алданрак театр училищесына кергән булсаң, без очрашмаган да булыр идек, ди әнә Ренат.

Синең өчен кыен роль булганы бармы?

– «Син бит минем бер генәм» спектаклендәге Алинә образы, ай, кыен булды! Авторы әни – Исламия Мәхмүтова аның. Хәтерлисездер, бер-берсен яратучы егет белән кыз. Без Ренат белән уйнадык. Алинә егетен армиягә озатып кала. Айнурны Чечнядан цинк табутта кайтаралар. ...Һәм көтелмәгән хәбәр: Айнур исән икән бит! Авылына кайткан!.. Әмма ул сукыр!.. Үземне ничек тотарга, көтелмәгән хәлдән ничек чыгарга, ничек уйнарга



белмәдем. Минем өчен бөтенләй ят кичерешләр иде бу! «Әни, мин уйнамыйм, – дим репетиция вакытында. – Алинәнең киеренкелек халәтен таба алмыйм...» Әнинең тавышы кырыс: «Эзлән! Тап! Син артист кеше бит!» Шуннан мин Камал театрында «Сөяркә» спектаклен карадым. Бер генә тапкыр түгел, кабат-кабат... Һәм эзләгәнемне таптым! Алсу апа белән Илдар абыйның уены миңа юл ачкандай булды. Алсу апа яраткан кешесен әнә ничек кире кага! Ул хисләрен әнә ничек оста итеп бирә!

Ә халык ничек кабул итте?

– Бер мәлне залда ыгы-зыгы башланды – кешеләр йөгерешә. «Ашыгыч ярдәм» чакырганнар, врачлар килгән... Бер ханымның улы Әфганстанда һәлак булган икән. Үз баламны күргәндәй булдым, дип, сәхнәгә чәчәкләр менгерде ул соңыннан... Ә Әтнә районында исә бер егет, сәхнәгә менеп, безне кочаклап елады. «Сез минем тормышымны уйнадыгыз», – ди. Ул да Чечняга китеп, аның да «табутын кайтарганнар», сөйгән кызы башкага кияүгә чыккан...

«Танылган кеше» булу кыенмы, рәхәтме?

Минем турыда: «Олы кызыгыз бигрәк акыллы, тирәннән уйлый», – диләр икән. Һәр әнигә үз баласын мактауларын ишетү рәхәттер инде

PRESSA.RU



ул. Ләкин без тыйнак булып үстек. Дәү эти белән дәү әни дә гел әйтә килде: «Әти-әниегезне бөтен Татарстан белә, берүк кызыллык китерә күрмәгез аларга», – диләр иде. Беркайчан да мин эти-әни артист дип кычкырып йөрмәдем. Театр училищесына укырга кергәч тә шактый вакыт Мәхмүтовлар кызы булуымны белмәделәр. Әти белән әни, Күчмә театр артислары булгач, гастрольләрдән кайтып та кермиләр иде. Ә җәйләрен инде без гел бергә булабыз! Отпускларын гел минем белән үткәрәләр! Рәхәт, күңелле чаклар!.. Балачагым Әлки районында, әнинең әнисе Мәрвия дәү әнием янында үтте. 8 айдан 4 яшькә кадәр авылда яшәдем. Дәү әни белән дәү әтигә «әни», «әти» дип эндәшәм икән. «Баланы алып кайтыйк безне оныта башлаганчы», – дигән әти. Мине Казанга алып килгәннәр. Мамадыштан әтинең әнисе Сабира әбием мине карарга килгән. 1988 елда гына Күчмә театр, Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры статусын алып, элеккеге Камал театры бинасында эшли башлады. Ә миңа ул чакта 21 яшь иде инде.

Лилия, сәхнәдә тудырган образыңда озак яшисеңме? Өйдә дә дәвам итәме ул тормыш?

– Юк, спектакль бетүгә үк ул образдан чыгарга тырышам, Лилия булып калам.

Миләүшә чәчәк күзләре булып...

Миләүшә чәчәк күзләре булып, тәрәзәләре урамга карый Лилияләрнең. Тәрәз саен гөлләр. Ниндиләре генә юк! Шәмәхә, алсу, сирин төсендәгеләр, ачык зәңгәрләр... Тамашачысы бүләк иткән чәчәкләр үзенә бер ямь биреп утыра... «Чын күңелдән бирелгәннәре шиңми, озак саклана», – ди ул. Мәктәптә укучы бер кыз бала бүләк иткән роза чәчәге ай буе утырган, бөредән яфраклар чыга башлаган хәтта! Кайберәүләр сокланып карый, кайберәүләрнең күзе каты... «Күз тиюгә ышанам мин, – ди Лилия, – шуңа сәхнәгә чыкканда күлмәгемә булавка тагам. Алка-йөзекләр дә саклый яман күздән. Мари Республикасының Бәрәңге районында сәхнәдә уйнаганда тиктомалдан күзем шеште. Күз тигән дип, укол ясадылар хәтта. Ышанмас җирдән ышанырсың...

Син нәрсәдән куркасың, Лилия?

– Минме? (*Кинәт кистереп.*) Ялгызлыктан! Аллаһы Тәгалә мине туганнарымнан, иремнән, баламнан, якын дусларымнан аермасын иде дип телим. Әнине күз алдыма китерәм дә, аңа берничек тә ярдәм итә алмавыма җаным телгәләнә. Гомер буена гел кешеләр белән аралашып яшәделәр. Театрда да, өйдә дә... Гел кунаклар килә иде... Өебез шау-гөр килеп тора иде... Әти үлгәч, нәрсәдер өзелде. Аңлыйм: әнигә бик авыр! Әмма аның дөньясына да кереп китә алмыйм. Үз дөньям бар.

Сөйлә әле, Ренат белән ничек таныштың? Әтиеңә охшаш яклары бармы? Кызлар, гадәттә, әтиләренә охшаган егетләргә тартыла бугай...

– Ренат Шәмсетдинов исемле егет белән театр училищесында бер төркемдә укыдык. Үзебез дә күп түгел инде, җыенып 11 бөртек. Ренат – курайда, Мөршидә гармунда уйный, мин – фортепианода. Бер төркемгә берләшеп, чыгышлар да ясап йөрибез. Башта гади дуслар гына идек әле. Тора-бара якынаеп киттек. 1991 елда өйләнештек. Ренатны әтигә охшаган дип әйтмәс идем... Хәер, икесе дә балта эшенә оста... Икесе дә җор телле... Үҗәтләр, булсын дип тырышалар... Партнер буларак та җайлы Ренат. «Күрәсем килгән иде» спектаклендә парлап уйныйбыз. Аның белән уйнавы рәхәт!

Син әниеңә – Исламия апага охшагансың, әйеме?

– Минме? *(Көлеп үк җибәрә.)* Белмим, белмим... Тышкы кыяфәттә бардыр, әлбәттә. «Сынган беләзек»не уйнаган вакыт. Тамаша залында рәтләр арасыннан пышылдау уза: «Исламия!» Кайберәүләр: «Абау, яшәргән бу Исламия!» – дип сокланып утыра икән...

Безнең гаиләне белүчеләр, холкың да, төс-кыяфәтең дә гел әтиеңнеке инде, диләр. Тыныч, тәвәккәл... Гомер буе әти кебек гаделлек, дөреслек яратам. Киңәшләре, җайлап сөйләшүләре гел искә төшә менә хәзер... Соң булса да әтигә якыная алдым. Аны үзем өчен өр-яңадан ачтым. Әтиемне бик сагынам.

Син атаклы артистлар династиясеннән бит! Татарстанның халык артистлары Исламия апа белән Хәлил абый, әниеңнең сеңлесе, Камал театры актрисасы Рузия Мотыйгуллина, Ренат Закиров белән Рузия апаңның кызы биюче Чулпан, сеңлең Ләйсән Мәхмүтова... Әнә сез никадәр!

– Әйе шул, без күбәү... Ә менә Рузия апаның иң яраткан сеңлесе мин! Театр училищесында укыганда Рузия апа бездә торды бит. Һәм кияүгә чыкканчы бездә яшәде. Рузия апа холкы белән кырыс, таләпчән иде. Чисталык, матурлык, зәвык ярата. Нәрсә яхшы, нәрсә яман икәнен бәләкәйдән сеңдерде миңа. Иртүк мине бакчага алып китә, үзе дәрескә йөгерә. Кайчак Рузия апа мине училищега да ияртеп бара иде. «Күренми генә утыр!» – дип кисәтеп тә куя. Дәрескә кергән Марсель абый Сәлимҗанов калын тавыш белән: «Кем бар анда? Кая, күрен әле! Нинди кыз алып килгәннәр анда?» – дип, шаяртып төпченергә

тотына. Рузия апа үзе белән укыган дус кызлары Алсу апа Гайнуллина, Зөлфирә апа Зарипова, Фирая апа Әкбәрованы өйгә кунакка алып кайта, бергәләп тәмле әйберләр пешерәләр иде... Хәзер дә бик игътибарлы ул. «Ролең әйбәт, сеңлем. Үзеңә туры килә», – дип күңелне күтәреп җибәрә белә.

Сеңлең Ләйсәнгә син дә шундый ук апа булгансыңдыр инде...

– Безнең яшь аермасы да җиде ел бит! Ләйсән үсмер чакта мин җиткән кыз идем инде. Шундый кызык вакыйга искә төшә. Шимбә безнең өчен өй җыештыру көне иде. Карыйм, берсендә Ләйсәнем бик нык бизәнеп, буянып, муенына чылбырлар асып, каядыр җыена. Безнең эш бар бит, оныттыңмыни, дим. «Син кем әле минем өчен?!» – дип телләшеп маташа, җитмәсә. Апа кеше икәнемне сиздертәсем килде, миңа инде 21 яшь иде! Җилтерәтеп ваннага алып кердем дә битендәге, күзендәге буяуларын юдырттым! «Мин сиңа әти дә, әни дә урынына калдым, беркая бармыйсың, өй җыештырабыз хәзер!» – дим. Соңыннан Ләйсән шушы «тәрбия дәресләрем» өчен рәхмәт әйтте. Ул бик тырыш, эзләнүчән безнең, бер урында гына утыра торган түгел. Театрда да, эстрадада да, кинода да ул, сценарийлар да яза, «Зә-ләй-лә» төркемендә дә җырлап йөри. Булдыра, кыскасы! «Уеннан уймак» музыкаль фильмын караучылар белә инде, Ләйсән язды аны. Рольләр бүлеп, Мәхмүтовларны да катнаштырды фильмында.

Улыгыз да, бәлки, театрны сайлар берзаман?

– Декабрьдә армиягә озаттык Ришатны. Дисциплинага, тәртипкә, мөстәкыйльлеккә өйрәнер. Хәзергә – Ульяновскида. Военкоматтан кайткач, бик еладым. *(Моңсу.)* Янына да барып кайттык. Шалтыратып тора. Казанны бик сагына. Ришат КНИТУ (КХТИ)ны тәмамлап, программист дипломы алды. Ул безнең яшь тә 8 айдан гастрольләрдә йөреп үскән бала инде. 3 яшеннән укырга өйрәнде. Кечкенәдән үк бик кызыксынучан булды. Музыка мәктәбен «биш»кә генә тәмамлады, флейта буенча конкурс лауреаты исемнәрен яулады. Япон мультфильмнарын русчага яңгыратты, пародияләрне оста башкара. Берара театрга да барасы килгән иде. «Улым, ир-атка беркайчан соң түгел. Башта һөнәр сайларга кирәк, – дим. – Артистның уңышы режиссерга бәйле. Сөйкемле сөяге булса, рольләр эләгә, булмаса, рольсез йөрисең...»

Син нинди әни? Нииндирәк ир хатыны?

– Мин – Кыз йолдызлыгыннан дисәм, аңлашыла инде... Холкым буенча да тыныч. Соң чиккәчә түзә алам. Чыгырымнан чыгарсалар гына вулкан кебек шартлыйм! Бөтенесе белән килешеп, тату яшәргә тырышам. Хәзер үземне яклый алам инде! Беркемнән сүз әйттермим. Әдәп саклап, сүз әйтергә оялып йөрмим элеккечә. Шәлегә, Ренатлар авылына кайткач та, шәһәр кызы булып йөрмим, гап-гади Лилия булып калам. Өстемне алыштырып алам да эшкә тотынам. Ашарга да пешерәм, идән дә юам, бакчада да эшлим, ял да итәм... Мин анда кайчан да үз кеше.

Синең өчен авылга кайту ял алайса?

– Еш кайтып булмый. Әле бакчабыз да бар бит! *(Елмая.)* Үзебезнеке – Түбән Осланда, Иделгә 20 минут кына төшәсе... Пионнарымны сагынып киләм анда. Салмачида әнинең дә бакчасы бар әле... Бер елны Ләйсән белән Мисырда ял итеп кайту да ошады. Адәм баласына ял кирәк ул. Бәйләм бәйләп, фильмнар карап, китап укып та ял итә алам.

Ә нинди кинофильмны кат-кат карый аласың?

– «Девчата»ны! *(Күзләре очкынланып китә.)* Надежда Румянцева, Николай Рыбниковлар уйный анда Мин һаман совет кешесе булып калдым бугай. (*Көлә.)* СССРда туган бала бит! «Иван Васильевич меняет профессию», «Бриллиантовая рука»лар ошый...

Димәк, син хатирәләр, ностальгия белән яшәргә яратасың. Ә фотоальбомыңда иң кадерле фото кайсысы?

– Әти белән әни уртасында курчак тотып төшкән фотом. Ләйсән кечкенә чагында ул курчакның битләренә язып, сызгалап бетергән иде. Еллар узгач, ул 40 яшемә курчак бүләк итте. «Апа, теге вакытта яраткан курчагыңны бозган идем, монысы озын гомерле булсын», – дип, сюрприз ясады, мине балачагыбызга кайтаргандай булды...

...Лилия белән әле рольләр турында сөйләшәбез, әле өй, гаиләгә күчәбез. Ә блокнотта әллә никадәр мәгълүмат һаман!

«Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ендә Гөлбануны башта әни уйнады. Камал театрында – Рузия апа. Соңгы куелышта – мин».

«Гротеск образларда да эзләндем. Бомаршеның «Фигароның өйләнүе»ендә Розина шундыйлардан».

«Әнием Исламия Мәхмүтованың «Син бит минем бергенәм», «Мәхәббәт чишмәсе», «Күрәсем килгән иде» пьесаларындагы геройлар миңа атап язылган».

...Театр, рольләр, гаилә, туганнар, дуслар, тамашачылар... Барысын да ярата бит ул! Аларның барысына да ул, Лилия кирәк!



PRESSA.RU



Ул әдәбият сөючеләргә шагыйрь, публицист, документаль проза өлкәсендә эшләүче буларак таныш. Татарстан, Россия күләмендәге һәм Халыкара премияләр лауреаты. «Шаһинур Мостафин дип әйтү белән, милләтебезнең асыл сыйфатларын үзенә туплаган олы җанлы, кече күңелле, итагатьле, ярдәмчел, кешеләр өчен җанын да бүлеп бирергә әзер ир-ат күз алдына килеп баса», – дип яза аның турында Илдар Юзеев. Һәм чынлап та шигъри күңелле, тормышны, кешеләрне яратучы эзтабар язучыны без нәкъ шундый итеп беләбез. Бөек Ватан сугышының моңарчы билгесез булган каһарманнарын эзләп табудагы изге, игелекле эшләренә сокланабыз. Матур юбилее белән котлап, аңа нык сәламәтлек, иҗатында зур уңышлар телибез!

Шаһинур
МОСТАФИН

ЯРАТУ УЛ – ТЫҢЛАП ТУЙМАС ҖЫРДАЙ!..

2007 елның декабрь аенда –
59 яше тулыр алдыннан –
автоһәлакәт корбаны булган
сөекле хәләл җефетем –
Җанҗиләгем Дамирә Рафаил
кызы кабере янында уйланулар

Әйткән идең: «Чын дусларың булу,
Шаһинурым минем, бик кирәк!»
...Ул асыл зат гомерең саклап калды
Байтак еллар элек, Җанҗиләк!
Хәләл канын бирде! һәм җанын да
Бирергә ул әзер иде бит! –
Сине тизрәк терелтергә теләп,
Яннарыңа кат-кат килде бит...
Аның ире – сабакташым-дустым –
Искитмәле Шагыйрь иде лә!
(Халкыбызның олуг мәхәббәтен
Казанган шәп Шаһ-ир әле дә!)
Ул да бакыйлыкка китеп барды –
Синдәй, бер үк елда! – бик иртә...
Мин юксынган кебек, Ханбикә дә
Ирен һәрчак исендә йөртә!
Сөенәмен: онытмаган өчен
Һәм Рухын зурлаган өчен!
(Шул дустымны кабат терелтергә
Җитсә иде, димен, дәрт-көчем!)
Мин дә шулай тиң ярымны сөйдем,
Өзелеп сөйдем! – Ул да аңлады...
Бергә кичердек без Сөю тулы
Күп кичләрне, алсу таңнарны!
Язмыш җиле алып китте аны,
Каерып алып миннән, гомергә...
Төшләремә керде Җанҗиләгем:
«Миндәйне тап, зинһар, тилмермә!..»
Синдәйне мин таба алмам инде:
Син – үзеңчә, ә ул – үзенчә...
Йөрәгемдә, мәңге янар уттай,
Калчы, бәгырем, нәкъ шул көенчә!
Синдәйне мин һич тә таба алмам,
Син – Җанҗиләк, ә ул – Ханбикә!
(Кушаматы шундый инде аның –
Балкып торгангадыр кич-иртә!)
«Татар Терезасы!» – дип тә аны
Йөретәләр, зурлап, һәр җирдә!
Ярдәмгә ул шундук килеп җитә –
Коштай җитез үзе, өлгер дә!
Син үзең дә тойдың, Җанҗиләгем,
Җан җылысын аның һәрчакта...
Сезне бик сагынып, хәтерләрдә
Терелтәбез! Хисләр – учактай!..


* * *

Без – тиңдәшләр,
Рухи тиңдәшләр!! –
Аның да юк пары, минем дә...
Сөйгәннәргә һәрчак тугры калыйк,
Яра калмасынга күңелдә! –
Тансык ярлар була бер генә!!!
«Һаман яратам!!» –
дип әйткән бит ул,
«Сөю – мәңгелек!!!» – дип язган ул...
Шуны раслап, шомырт чәчәк ата –
Йөрәккә дәрт өстәп язларын!..
Ошаганнар, охшатканнар була,
Тик хәтердә бары бер сурәт:
Ул, елмаеп, сиңа карап тора:
«Тормыш күмерләрен көйрәт!»
Күмерләргә җылы сулыш өрсәң,
Терелә, диләр, Учак: Ут-ялкын!
«Шул Ялкынны һәрчак дөрләтергә
Көч-кодрәт бирче, Илһамчым!» –
Диеп дәшә кебек газиз җаннар –
Рухлары белән көчлеләр!
...Чын Сөюнең Илаһи зурлыгын
Ничек аңлатыйк соң, кешеләр?!.

* * *

Сезнең җаннар, Кояш нурларыдай,
Безнең күңелләргә багалар!
Сез – оҗмахта,
Ә без – фанилыкта...
Ничек табыйк икән дәвалар?!
Сезгә булган ихлас ихтирамны
Һәм Доганы саклап күңелдә,
Әйтәбез гел: «Сезне яратабыз!!.
Кайда булсак та без – гел бергә!!»
Күчкәч тә без бакый-мәңгелеккә,
Шул ук сүзне сезгә әйтербез:
Ярату ул – тыңлап туймас
Җырдай! –
Яратудан башка – ятим без...
Өзелеп сөйгән ирең – якын дустым,
Җанҗиләгем – минем хатыным, –
Җәннәт түрләрендә нур сипсеннәр,
Күрсен алар хисләр балкуын!!
Ихлас сөенсеннәр, риза булып:
«Тормыш дәвам итә тагын!!» – дип...
...Яныгызга бергә киләбез гел –
Бик сагындык Сезне, сагындык!!.

«...Җилкәнеңне җилләр екса – йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. Көчле рухлылар гына максатларына ирешә ала. Түземлеләр генә бәхеткә лаек». Фәнис Яруллинның шул сүзләре һәркем өчен тормыш кагыйдәсе сыман. Беренче шигырьләр җыентыгы да шул сүзләрнең лейтмотивы кебек – «Мин тормышны яратам!» Иҗаты кемне генә битараф калдырыр икән?! Шагыйрь, прозаик, драматург, әкиятләр остасы, ялкынлы публицист. Лирик шигырьләре хатын-кызларның күңел кичерешләренә аваздаш. Кабат укыйк әле шуларны. Үзе дә, шигырьләре дә сагындырган...



Фәнис ЯРУЛЛИН

СИНЕҢ БЕЛӘН БЕР КҮРЕШҮ ӨЧЕН...

* * *

Матур кызлар җирдә бик күп алар,
Синдәйләре ләкин сирәктер.
Син җәйләрнең бөтен матурлыгын,
Назын җыеп үскән җиләктер.

Күзләреңдә синең серле балкыш –
Йолдызлардан килгән бүләктер.
Кемдер өчен синең бер карашың
Бар нәрсәдән җирдә кыйммәттер.

Зөһрә кызның сурәте бар Айда,
Ә бәлки, ул синең сурәттер.
Синең белән бер күрешү өчен,
Айга күтәрелү кирәктер?!

Кара төндә йолдыз атылып төшә,
Ансы инде минем йөрәктер.
Сиңа таба еллар буе барам,
Барып җитә алмыйм нишләптер.

* * *

Бер-беребезне күпме йөрдек
озатышып
Салкын кышта, эссе җәйдә,
елак көздә.
Ике җанны мәңгелеккә кушар өчен,
Бер сүз җитәр кебек иде икебезгә.

Ләкин ул сүз әйтелмичә
калды шулай,
Очты-китте бик биеккә, гүя тургай.
Ә без калдык бик түбәндә, кечерәеп,
Ул арада йолдыз сүнде, югалды Ай.

Бер-беребезне озатышып
йөри-йөри
Без сөюнең үзен озатып
куйганбыз бит.
Яшьлек биргән иң кадерле
хәзинәне
Төнге кара сукмакларда
җуйганбыз бит.

Шушы хакыйкатьне аңлар өчен
Кирәк булган безгә ничә еллар?
Кайсы диңгезләргә акты икән
Чума-чума без коенган сулар?!

* * *

Тышта төн. Шәһәр йоклаган.
Талгын кар ява иде.
Тәрәзәмне әкрен генә
Кемнәрдер кага иде.

Килдем тәрәзә янына,
Күренми анда беркем.
Машиналар туктап калган,
Урам тын, урам иркен.

Җил кызы шаяра дисәң,
Җил дә исми урамда.
Шәһәр йоклый тып-тын гына,
Төренеп ак юрганга.

Ә шулай да тәрәзәгә
Чиртеп алгалый кемдер.
Бәлки, ул яшьлектә калган
Тәүге мәхәббәтемдер.

Тәрәзәмне ачып куйдым,
Кемдер өемә узды.
Пышылдады серле тавыш:
– Мин синең хыял кызы.

Тик шуны бел: хыяллар да
Картая һәм үзгәрә.
Син эзләгән ялкын сүнде
Күптән минем йөзләрдә.

Син мине күрми яшәдең,
Әле дә күренә алмыйм.
Синең хыялда булса да,
Матур кыз булып калыйм.

* * *

Агымсулар ярга сыймый
Агар да агар инде.
Хисләрем күңелең ишеген
Кагар да кагар инде.

Вакыт аты кешни-кешни
Чабар да чабар инде.
Йөгәнгә уралган куллар
Канар да канар инде.

Ялгыз Ай миңа моңаеп
Карар да карар инде.
Җавапсыз сөю йөрәктә
Янар да янар инде.

PRESSA.RU



Фирүзә
ҖАМАЛЕТДИНОВА

ЯРАТУДАН АЛДАШУ

(Хикәя)

Җир өстендәге һәммә кеше, тормыш чынбарлыгыннан качып, бәхет бары тик акчада гына дип яшәгән бер мәлдә, ул да ялганга табан бер адым ясады. Ничекләр башына килгәндер?.. Никләргә генәдер?.. Үзен үзе алдавына үкенеп, мендәренә капланып, ничәмә-ничә кат яшь түкте инде менә... Тик соң шул хәзер. Бәлки әле соң да түгелдер...

Кызның һаман матур ялганга ышанасы һәм аны да ышандырасы килә иде. Байлыкның кешегә күпмедер дәрәҗәдә бәйсезлек рәхәтлеге бирә алуын да шунда чамалады сыман ул... «Менә ни өчен малга табыналар икән, – дип уйлап куйды. – Әгәр дә дөресен әйтсәм, ул минем янга килеп тә карамас, хәерче бер кызны затлы машинасына утыртып йөрүенә дә гарьләнер әле».

Һәм бөтенесе дә үзгәрер, Җир шары да кирегә табан әйләнә башлар кебек тоелды. Гөлләрнең кинәт кенә хуш исләре бетеп китәр, кояш нурсыз калыр, салават күпере дә черек басмадай күк катыннан ишелеп үк төшәр сыман иде... Аннан яшәве дә үзгәрәчәк бит. Иң кирәге – тормышта тотынып торырдай бердәнбер өмете югалып китәргә дә мөмкин әле... Аңардан башка яшәү яшәүме инде ул?! Тере көенчә мәет булып йөрү генә булмасмы?

Әйе, сөйгәнен югалту кыз өчен үлемгә тиң иде. Ярата шул ул аны. Ничек кенә ярата әле. Ап-ак болытлар күктә көн-төн туктамыйча ничек йөзеп йөрсәләр, Лилия дә мәхәббәте хакына шул болытларга кушылып китә ала. Җилләр ни рәвешле иссәләр, кыз да сөюе хакына нәкъ шушылай ук туктаусыз бөтерелеп яки йомшак кына һаман алга алгысып тора алыр иде. Тик мондый теләк-гамәлләрне мәңгелек җиһан гына тоемлый аладыр шул... чөнки ул мәхәббәтне күп тапкырлар күргән. Барысын да зур йөрәгенә яшергән...

...Алар биш катлы кызыл кирпеч йортның урта подъезды каршысына кайтып туктадылар. Егет, чем-кара иномаркасыннан төшеп, сул яктагы ишекне ачты да кызга дәү кулын сузды.

– Битләрең алсуланып киткән, салонда эссе булдымы әллә, матурым? Әйтсәң, кондиционерны кабызыр идек бит...

Егет, елмая-елмая, машинадан чыгып җиргә баскан кызның алсу бит алмаларын бармак очларын гына тидереп, сыйпап алды.

– Юк, болай гына...

– Әниең күрер дип куркасыңмы әллә?

Кыз дәшмәде.

Егет, горур башын күтәреп, өске каттагы тәрәзәләргә төбәлде. Дөньяның бар караңгылыгын йоткан, һәммәсе бертөсле чем-кара тәрәзә пыялаларында яшендәй сызылып, ялт-йолт серле нурлар уйнаганын, кояшның да сәер чагылышын күрергә була иде. Кыз нигәдер аскы каттагы тәрәзәләргә карап торды. Заманча пыялалар буйлап рәт-рәт кара машиналар шуышканы, карт топольләрнең караңгы шәүләләре чайкалганы күңеленә шом өстәгәндәй тоелды. «Подъезд ишеге ачык микән соң?» – дип куркып уйлап куйды ул.

Гадәттә, беркайчан да бикләмиләр аны, чөнки шунда, беренче катта гына тәүлек буена эшли торган кибет ачып куйдылар. Ишеген икенче яктан ясарга җыеналар икән, дигән хәбәрләр ишетелсә дә, башка яктан керү урынын тишеп, бикләп алсалар да, нигәдер бу эшне тулысынча башкарып чыкканнары юк әлегә.

– Йә, бу юлысы әйт инде, кайсысы сезнең тәрәзәләр?

– Син кайсылары дип уйлыйсың?

Кызның тавышы ишетелер-ишетелмәс кенә чыкты, үзе дә сизмәстән иңбашлары җыерылып куйды, ирексездән озын керфекләрен җиргә төбәде. Кинәт кенә аяк буыннары йомшап киткәндәй булды.

Егет һаман әкрен генә гоманлавын белде:

– Әлбәттә, иң өстәгеләре... Бишенче катта... тәк... сул яктагылары...

Кыз дәшмәде, тыйнак кына янәшәсендә басып торган егетнең бит очыннан үбеп алды да йөгерә-йөгерә затлы ишек артына кереп югалды. Сөйгәненең тоныкн тавышын ул гүя офыкларның аргы ягыннан ишетте:

– Иртәгә сөйләшкән урында сәгать алтыда көтәрмен...

Егет, кызның шәүләсен күрергә теләп, караңгы тәрәзәләргә текәлеп, бик озак басып торды. Тик тыштан берни дә күреп булмый иде шул. Ул әллә нинди яңа төрле корылмалар, кара пыялалар уйлап тапкан төзелеш кешеләрен эчтән генә сүгеп тә алды кебек...

– Төрмә дип белгәннәрме әллә кеше яши торган йортларны? Кемгә кирәк мондый караңгылык?

Лилия шушы сүзләрне ишеткәндәй булды. Ишекне киереп ачып, эчкә кереп басты. Бер кыргарак авышып, таш диварга сөялде. Йөрәк тибеше урамгача ишетеләдер кебек тоелды.

– Йа Ходаем, никләр миңа бу җәза? – диде ул, кемне гаепләргә дә белмичә.

Ишек тоткасына кемнеңдер тотынганын ишетеп, ул баскычларга табан атлап китте һәм бар сынын җыеп тиз генә икенче катка юнәлде. «Кибеткә керүче булды бугай», – дип уйлап куйды. Һәм икенче каттагы караңгы тәрәзә янына килеп басты. Эчтән урам ап-ачык күренә; егет, тәрәзәләрнең кайсына да карарга белмичә, башын әле уңга, әле сулга боргалап, аны эзли иде.

– Йә, кайтып кит инде, матурым, – диде кыз, үзе генә ишетерлек итеп. Ул кесә телефонын тартып чыгарды. Егеткә нәкъ шулай дип әйтәсе килде. Янә бөтен тәне кызышканны тоеп, аны кире үз урынына, сумкасына салып куйды. Егет кузгалырга уйламады да кебек...

Лилия, тимер челтәрле баскычларга тотына-тотына, өченче катка ук менеп җитте. «Нигә бәхетсез соң мин?» – дип, үз-үзенә сорау бирде. Әлбәттә, бәхетсезлегендә кыз һаман берәүне генә гаепли – әнисен. «Бөтен кеше фатирларда яши. Гомере буена эшләп тә, аңа гына бер бүлмәлене булса да ничек бирмәгәннәрдер инде? Димәк, сорамаган. Димәк, минем язмышым аны артык борчымаган...» Шулай уйлый башлауга, иң якын кешесе – әнисе белән ике арага салынган бозлы күпер кырында басып калгандай була. Бөтен җанына салкын үтеп керә. Яшисе дә килми башлый...

Кыз, караңгылыкны сөртеп алырга теләгәндәй, салкын пыяланы сыпырып-сыпырып куйды. Ул гүя «сөрем» аша да егетнең ахактай янып торган күзләрен күрде... «Кем белә, бәлки әле аның да нәкъ шушындый йортта яшисе киләдер. Яхшы машинаны бит хәзер бөтен кеше дә бурычка ала. Банклар акчаны капчыклап бирә ич... Әти-әниләр түләп кенә бетерсен... Тик үзе әйтмәгәч, кайлардан беләсең соң аны? Бер дә тулай торакта үскән егеткә охшамаган шул ул».

Кыз яхшы машиналарда җилдерүче күршеләрен, төркемдәшләрен күз алдыннан үткәрде. Кешеләр бай булып күренергә ярата торган заман шул бу... Күптән түгел генә байлар күченеп яши башлаган шушы йортның кызыл кирпечләренә ул ачу түгеп карады. Салкын кирпечләрнең һәммәсе дә хәлен сизеп тора, хәтта исәрлегеннән көләләрдер кебек тоелды. Адәм балалары нигә бер дә тигез яратылмаган икән соң?

– Бар, кайт инде, матурым, әниең көтәдер... – Җөмләсен пышылдап кына әйтте дә, кыз дүртенче катка менә башлады.

Инде менеп җитеп бара иде, кинәт кемнеңдер тимер ачкычларын шалтыратып ишек ачканы ишетелде. Лилия адымнарын кызулатты. Гүя шушы тозак-тавыш, куяндай калтырап, үзеге аша үтеп чыкты... һәм өске катка элдерде. Тукталып, колакларын шомрайтып тыңлады. Тавышның тек-тек итеп аска табан тәгәрәп китүен тоеп торудан рәхәтлек сизеп, ниһаять, җиңел сулап куйды.

«Шөкер, әлегә күрмәделәр... Күрсәләр, ни диярсең? Кемгә килдегез, дип сорасалар... Очрый гына күрмәсеннәр, Ходаем. Монда гади кешеләр яшәмидер әле... Кайсы директордыр, министрлары да бардыр... Җаваплы кешеләр алдында җавап тотып, кемнең ни исбат итә алганы бар соң? Гаепсездән гаепле булып куялар бит һәммәсе дә...»

– Киттеңме инде, матурым? Кайт инде өеңә!

Кыз, шулай сөйләнә-сөйләнә, тәрәзә янына килеп сөялде. Ул инде үзенең алдашканына үкенә дә башлаган иде: «Матди байлыкның мәхәббәткә ни катнашы булсын соң? Яраткан ярларын чатырда яшәсә дә ташламаучылар турында күпме әсәрләр язылган бит әнә...» – дип уйлап куйды. Шуларны белә торып, ни дип мондый адымга барды соң әле ул? Нинди шайтан котыртты аны?

– Нишләп торасың инде, матурым?

PRESSA.RU

Лилия җөмләсен кычкырып ук әйтте. Чөнки егет, караңгы тәрәзәләргә төбәлеп, һаман нидер көтә иде. Әлбәттә, аларның ачылып китүен, аннан кызның, башын тыгып: «Мин сине яратам!» – дип кычкыруын көткәндер ул... Тик бу хәл мөмкин түгел иде шул. Дөресен әйткәндә, Лилия аларның ничек ачыласын белми генә түгел, хәтта күз алдына да китерә алмый, мондый куркыныч затлы билгесезлеккә кулы белән кагылудан уттан курыккандай курка да иде.

Егет чалбар кесәләрен капшап карады, сул кесәсенә тыгылып, ниндидер кечкенә генә төргәк тартып чыгарды һәм аны иплəп кенә сүтә башлады. «Акбур!» – дип уйлады кыз. Егет кулында чынлап та акбур иде. Менә ул асфальтка иелде... Менә ул үзе кадәрле дәү хәрефләр белән юлны тутырып яза башлады: «Лилия!»

Кыз елмайды. Аңа бик тә рәхәт, шул ук вакытта бик тә кыен иде. «Нишләп кенә алдаштым икән соң мин?» – дип сорау бирде ул үз-үзенә.

Шушы мәлдә, бай һәм затлы диварларга сөялеп, бәхетле мизгелне күзәтү, караңгы тәрәзәләргә төбәлү вакытлыча гына булса да, матди байлыкка кызыккан заманга яраклаштырса, чибәр егетнең ишек төбендә аны уйлап таптанып торуы җанына рухи дәрт өсти кебек тоелып китте.

Егет соры асфальт өстеннән вак таш кисәген читкә тибеп очырды. Бөгелеп тагын язарга иелде. Кыз игътибар белән аны күзәтте. Шул мәлдә астан өскә таба менеп килүче аяк тавышлары ишетелде. Тавыш иясенең бишенче катка ук менеп җитмәвен тели иде. Ул Ходайга ялварды: «Күрмәсеннәр иде мине, Ходаем!»

Кыз бу йорт тирәсендә гел кырыс, тормыштан бигүк канәгать булмаган кебек салкын йөзле кешеләрне күзәтештереп йөри, алардан җанына бер генә тамчы да мәрхәмәт очкыны төшмәячәген электән үк сиземли иде. Тавыш һаман якынайды. Ул һаман күтәрелә, күтәрелгән саен, тимер үкчәнең таш идәнгә шак-шок бәрелгәне куркынычрак, хәтта шомлырак булып ишетелде.

Сагаеп, тыңлана-тыңлана, Лилия баскыч култыксасына тотынды. Аның тез буыннары тәмам йомшап бетте, ул инде аска төшеп китәргә әзерләнде.

– Мадам, сез кемгә килдегез?

Кыз, каушаганын сиздермәскә теләп, хатынга арты белән борылды.

– Мадам?..

– Сезгә килмәдем, – диде кыз йомшак кына.

– Алайса, Нуриевларгадыр?

– Гафу итегез, мин китеп барам инде...

Ул култыксаларга тотына-тотына аска төшеп китте. «Мадам, имеш... бәлки, мадемуазельдер», – дип кабатлады эчтән генә, ачуы килеп.

Хуҗа хатын, киң кырлы кара эшләпәсендәге вуаль астыннан сөзеп кенә карап, мәрмәр сындай катып, аны очлы күзләре белән чәнчи-чәнчи озатып калды.

Аңлады Лилия, әлбәттә, аңлады. Чит биләмәгә керергә ярамаганын ул болай да белә иде. Аны сөйгәненә лаек җан иясе буласы килү теләге шушы хәлгә төшерде. Бәлки, аны югалтасы килмәү теләге көчлерәктер дә әле...

Югарыдан карап тору ничек рәхәт иде шулай да!..

Лилия әлеге бай ханымны гына түгел, кызыл чирәпле затлы йортны да сөйми башлады кебек. Байлар тар күңелле була икән шул... Ә менә аларның тулай торагына кемнәр генә керми дә, кемнәр генә куна калмый!

Кыз подъезд ишегенә якынайды, сызык кына ярыктан тышка карады. Урамда кеше заты күренмәде. Машина урыны да буш иде. Күңеленә җылы йөгерде. Тоташ затлылыктан торган салкын диварлардан котылуына сөенеп, бик теләп урамга чыкты. Әллә нинди куркыныч тоткынлыктан азат иткәннәр диярсең...

Әле өсләренә яшеллек иңеп кенә килгән яшь яфракларга ул яратып төбәлеп торды. Алар һаман кояшка табан үрелеп, шул арада тагын да яктырып киткәннәр күк тоелды. «Караңгы тәрәзәләр бар булды ни аларга, юк булды ни – ник берсен бер кызыктырсын соң! Яфрак булып ачылалар да ямьле җәйләрдә рәхәт чигеп яшәп калалар, ичмасам. Баксаң, әле аларның пышылдашып кына бер-беребезгә «яратам!» дип әйткәнне дә тыңлыйсылары киләдер», – дип уйлады кыз.

Әкрен генә, үзләре яшәгән тулай торакның искереп карала башлаган шифер түбәләренә карый-карый, ул өйләренә кайтып җитте. Ике як тупсасыннан да кубып, асылынып төшкән, кеше башы чаклы тишекләренә фанер кагып бөтәйтелгән ишекләренә текәлеп, туктап калды. «Бу ишекләрне беренче кат күргән кеше нинди хисләр кичерергә мөмкин икән?» – дип уйлап куйды. Хәер, ул үзе ияләшкән инде. Моңарчы җир йөзендә башка төрле ишекләр дә буладыр дип башына да китергәне юк иде. Димәк, кешеләрнең байлык һәммә нәрсәдән өстен дип сөйләшүләре хак булып чыга түгелме?

Кыз сорауларына җавап таба алмады. Ни өчен берәүләр, бер көн эшләмәсәләр дә, затлы фатирларда яшиләр? Икенче берәүләр, гомере буена бил бөгеп тә, тулай торакның кысан бүлмәсендә интегә? Нигәдер, башына килгән бу сораулары да җавапсыз иде.

Аны тулай торак вахтёры каршы алды:


– Әниең кайтып җитмәде әле, – диде ул, гадәттәгечә. – Ачкычың бармы соң?

– Бар.

Гүя ул үзе түгел, аның белән башка кеше сөйләште. Гадәтләнгән сораулар, күзләр күнгән кыршылган соры стеналар – монда кыл кадәр дә үзгәреш сизелми иде...

Кыз, нигәдер песи учы кадәрле генә күренгән суык бүлмәгә кереп, караватына ауды. Аның өчен мәхәббәт газабы, алдашу үкенече һәм сөюен югалтасы килмәү теләге һәммәсе бергә кушылган, алар аңа сөенеч китерәсе урынга әрнетеп җанын талкыйлар иде. «Әнием гаепле һәммәсенә...» – дигән нәтиҗә чыгарды.

...Алар әнисе белән авылдан бик сәер итеп чыгып киттеләр. Әнисе ул көнне иртүк торып өй җыештырды. Идәннәрне юды, көзгеләрне сөртте. Кәстрүл-тәлинкәләргә кадәр ялт иттереп өстәлгә тезде дә өсләренә чиста сөлге япты. Ишек бавына эленеп торган тастымалның да чәчкәле ягын өскә каратып, тигезләп куйды. Өй гөлт итте. Аннан әнисе Лилиягә яңа күлмәген кигезде. Каядыр барасыларын кыз шунда гына сизенде.



Рәсем: Наталья Васильева

– Без кибеткә барабызмы әллә, әнием? – дип сорады.

– Китәбез!

– Кая китәбез?

– Еракка...

Әтисе дә, әбисе дә эштә иде шул. Белсәләр, бәлки, яннарыннан бер карыш та җибәрмәсләр иде.

Ул көн чалт аяз, зәңгәр күктә бөтерелеп кошлар оча, алар да кайларгадыр ерак-еракларга сәфәр чыкканнардыр шикелле. Үләннәрнең канат очларына кунып энҗе нурлар җемелдәшә, аларны коймаска тырышып, талгын гына җил исә иде. Шуңадырмы, кызга үзләре чыккан юлның теге очында әкияттә тиң гүзәл тормыш көтәдер күк тоелган иде.

Ә бер тапкыр, ник шулай бөтенесен ташлап китүләре турында кызыксына башлагач, әнисе: «Бәлки, әтиең үзе безнең янга күчеп килер әле, кызым. Ул сине бик ярата бит», – дип куйган иде. Кыз озак көтте әтисен. «Кызым минем» дия-дия, итәгенә утыртып чәчләреннән сыйпаганын кич саен, йоклап киткәнче, башка уйларга ияртеп күз алдыннан җибәрмәде. Тик килмәде шул әтисе... Димәк, үз әнисен күбрәк яраткандыр инде ул...

Бераз үсә төшкәч, әнисенең сүзләрен хәтерләп:

– Әти нигә безнең янга күченмәде икән? – дип сорады.

– Әтиең бик намуслы кеше, ул ялганларга яратмый, – дип җаваплады әнисе. – Дәү әниең бер дә хупламас иде шул...

Хәзер аңа бик күп еллар үткән инде. Тик нигә һаман бәхетле түгел соң аның әнисе? Нигә һаман тулай торакның тынчу бүлмәсеннән башка дөньяны күрергә бер дә омтылмый икән? «Тауга менсәң – тау биек, түбән төшсәң – тамырлык», – ди дә тик яши бирә шулай. Лилия үз сорауларына үзе җавап таба алмады. Ачык: аның бик тә, бик тә бәхетле буласы килә иде. Хәер, әнисе дә кызының үзеннән бәхетлерәк булуын тели бит. Аллаһка ялварып сораган чакларын да күргәне бар хәтта... Шул чакларда аңа аеруча моңсу булып китә...

Кызның җанын янә ялганның очлы уклары көйдереп үтте... Әйтергәме әнисенә монысын, юкмы? Хәтере калачак инде, әлбәттә. Үстердем, диячәк. Укыттым, диячәк... Балалар үзләрен генә яраталар, диячәк... Аның бу сүзләрне күп тапкырлар ишеткәне бар инде...

Үзен һәм әнисен җәлләп, Лилия кинәт кенә мендәренә капланып сулкылдый башлады. Шул чакта ишек ачылды, һәм бүлмәгә әнисе килеп керде. Ул кызының комачтай кызарган күзләрен күреп өлгергән иде инде.

– Тагын ни булды, балам? – дип сорады.

Кыз дәшмәде. Ул, кул аркасы белән битен сөртәсөртә, коридорга чыгып китте. Озын коридорның аргы башындагы кухняга керде, тулай торакка яны белән торган затлы кирпеч йортның караңгы тәрәзәләренә текәлде. Егетнең асфальтка «Лилия!» дип язганын исенә төшерде. Күзләрен йөгертеп, шул язуны эзләп тапты.

Хәрефләр аңа тараеп, кысылышып беткәндәй, хәтта берсе өстенә икенчесе менеп киткәндәй тоелды. Хәрефләрнең берсе дә, якын итеп, аңа таба карамый иде... Лилия исеме янәшәсендәге язуны көчкә-көчкә укый алды. Кызның нәкъ шушы заманча караңгы тәрәзәләргә төбәлгән исеме янәшәсенә «Мин сине яратам!» дип язылган иде...

PRESSA.RU



Аерылмагыз!

Су буенда ялгыз аккош,
Каерылган канатлары.
Канатларны каера ул
Аерылу газаплары.

Кушымта:
Аерылмагыз, аерылмагыз,
Булса да сәбәпләре.
Канатларны каера ул
Аерылу сәгатьләре.

Ят кошны пар итмәс аккош,
Ялгыз канат какса да.
Без дә бергә булалмабыз,
Сулар үргә акса да.

Кушымта:
Ялгыз аккош күргән саен
Өзелә бәгырьләрем.
Нигә без бергә чакларның
Белмәдек кадерләрен?!

Су буенда ялгыз аккош,
Каерылган канатлары.
Канатларны каера ул
Аерылу газаплары.

Кушымта:
Аерылмагыз, аерылмагыз,
Булса да сәбәпләре.
Гомерләрне кыскарта ул
Аерылу сәгатьләре.

Зөлфия
АФЗАЛОВА-
НИГЪМӘТҖАНОВА

«АЕРЫЛМАГЫЗ!» — БЕЗНЕҢ ҖЫР

«Әлфия Афзалова кызы» дигән исемем мине үзе үк сәхнә тормышына әзерләгәндер. Әни җәйләрен мине үзе белән гастрольгә алып чыгып китә иде. Бәләкәйдән үк аңа ияреп йөрдем. Бер дә еламыйм, көйсезләнмим, тик сәхнә артында уйнап йөрим. Нинди генә уңайсыз шартларга да түзәм, юл йөрүне ярата идем. Кайчак концерт бик озакка киткән төннәрдә, Зиннур Гыйбадуллинның баян чехолына башым куеп, йоклап киткән икән. Кышларын өйдә Җыракай (әнинең бертуганы Закирә апа) белән калгач: «Гастрольгә китәм!» – дип елый идем. Әнинең концерт бригадасында популяр булган «Юллар, юллар»ны «Юллал, юллал, авыл булса булсын...» – дип җырлап йөргәнмен әле. Кайчакта әни сәхнәдә бөтен йөрәген салып җырлап торганда, аның янына чыгып басам да, музыка ритмына биеп, боргаланып торам. Халык кул чаба.

Үсә төшкәч инде, әни миңа да эш тапты: концерт алдыннан, контролер булып, билетлар ертып торам! Авыл саен, клуб саен кабатлана шул эшем. Кайчак әбиләр, еламсырап, ишек төбенә килә:

– И кызым! Акчам җитми бит билеткa, ә Әлфияне бик карыйсы килә! – диләр. Жәлләп, бушлай гына кертеп җибәрәм. Әни аптырый... Зал шыгрым тулы, утырырга түгел, басып торырга да урыннар юк, ә билетлар никтер сатылып бетмәгән!

Сәхнә артында әнинең җырлавын исем китеп тыңлап торам, үзенә сокланып карыйм. Ул көлмәкләре, чәчләре, дугаланып киткән кыйгач кашлары, битләрен чокырайтып, серле елмаюлары!.. Ул ансамбле тагын!.. Эдита Пьеханы бик ярата иде ул. Үзенең дә прическалары, күлмәкләре, заманча җырлаулары Пьеханыкыннан бер дә ким түгел! Ә тавышы!.. Йомшак, шул ук вакытта көчле, яңгыравыклы, төрле төсмерләргә бай тавыш... Һәр җырын яттан беләм. Әни, Баянга кушылып, «Күл буена килсәң иде», «Кайтам инде», «Күңелле ял итегез», «Гармунчыга»ларны өздерә. «Казан утлары» инструменталь ансамбле белән «Актаныш таңнары», «Сәяхәтче җыры», «Тамчылар», «Ник соңладың?», «Назлы гөлкәем», «Чыгарсыңмы каршы алырга?»лар тагын да дәртлерәк яңгырый. Бөтенесен шаккаттырып, чит телләрдә дә җырлый әни. Их, ничек матур ул! Юк, мин тыңламыйм, очам!.. Мин генә түгел, бөтен зал сихерләнгән!

Күп җырларның ничек дөньяга килүе, ничек тууы минем күз алдында булды. Күбесенең авторлары Гөлшат апа Зәйнашева белән Зиннур абый Гыйбадуллин иде! Әнинең дусты, шагыйрә Гөлшат апа җыр текстын яза; аның ире, Әлфия Афзалова концертларының баянчысы Зиннур абый шул шигырьгә көй иҗат итә. Башта әнигә күрсәтеп, җырлатып карыйлар, ул әйткәнчә үзгәртәләр, төзәтәләр дә әле. Әнинең бормалары гына да бит ни тора! Өчәүләп яңа җыр тудыралар шулай.

Бервакыт әни гастрольләргә китте, апам Гүзәл белән мине Гөлшат апаларда калдырды. (Җыракай Актанышка кайтып киткән иде.) Без Гөлшат апа кызы Асия белән дуслаштык. Гөлшат апа өчебезгә дә сарафаннар тегеп кидерде, пончик дигән кабартма пешереп сыйлады. Мин «пончик» дип әйтә алмыйм, «путик» дим һаман. Гөлшат апа минем өчен «Путик» булып калды.

Бераз соңрак, Казан театр училищесын тәмамладым, эстрада артисткасы булып киттем. Әнинең концерт бригадасында да конферансье булып йөрдем әле берара.

Әнием җырларына бәйле матур истәлекләрем бар. Гөлшат апа белән Зиннур абыйның бергә яшәгән чаклары. Әни белән аларга киттек. Шатланып каршы алдылар. «Синең өчен өр-яңа җырыбыз бар!» – диләр. Гөлшат апа да матур җырлый иде. «Әлфия, тыңла әле!» – ди Зиннур абый. Ул матур музыкадан, искиткеч тирән мәгънәле сүзләрдән һушымны җыя алмый тордым. И әнигә ошады инде!

Узма, төн, үтми тор, бар әле сүзләрем / Иркәмә сөйләргә, сөйләргә. / Яшьлектә төн кыска, сызыла таң тышта, / Вакыттыр керергә өйләргә.

Шигырьнең авторы Роберт Әхмәтҗанов икән. Ә көен Зиннур абый язган! Күңел каядыр ашкына, оча. Вальска бөтереләсе килә.

Хуш, дускай, таң ата, / Офыклар алсу. / Бу – саубуллашу вальсы! / Бу – саубуллашу...

Зиннур абый кычкырып җырлый гына башлаган иде, шунда кинәт ут сүнде. Әни белән Гөлшат апа шәм яктысында тәмле мәмиләр дә пешерделәр. Ул арада эңгер-меңгер дә төште. Кыш көне бит тиз караңгылана. Кат-кат җырлый торгач, җырны да тәмам өйрәндек. Ут кабынуга инде Зиннур абый, ноталарын алдына куеп, пианино каршына килеп утырды да җырлап җибәрде. Без аңа кушылдык. Бу – «Саубуллашу вальсы» иде!

Тагын бер истәлек. 1982 нче еллар. Мин Равилгә кияүгә чыктым. Яңа өйләнешкәч, әле бер-береңә ияләшергә, бер-береңне өйрәнергә кирәк була икән. Саксыз сүз дә ычкынып китә, юкка-барга үпкәләшәсең дә... Равил белән без дә үпкәләштек. Шундый көннәрнең берсендә әни белән Гөлшат Зәйнашевага киттек. Мине күрү белән, шундук нәрсәдер булганын аңлап алды Гөлшат апа.

– Зулик, нишләп кәефең юк? Нәрсә булды? – ди.

– И Путик!.. – дим, чак еламыйча. – Равил белән аерылышырбыз, мөгаен. Сөйләшмибез...

Гөлшат апа мине тынычландырмакчы була. «Сабыр, акыллым, алай ук бетеренмә әле. Әйдә, чәй эчәбез», – дип, мине юатмакчы була.

Икенче көнне безгә үзе килеп керде. «Тыңла әле, сезгә багышлап шигырь яздым!» – ди. Һәм «Аерылмагыз, булса да сәбәпләре...» – дип укый башлады. Безне әнә шулай дуслаштырды ул. Бераздан ул шигырьгә Чулпан Зиннәтуллина көй язды. «Аерылмагыз!» дигән популяр җыр – безнең җыр. Равил белән бергә яши башлаганга да 37 ел тулды. Ике кызыбыз, дүрт оныгыбыз бар. Ә җыр безнең гаиләнең кадерле бер ядкаре булып калды.

Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.

PRESSA.RU



Фото: www.pixabay

ҮГИ АНА ОЯСЫ



Люция ФАРШАТОВА

НӘРСӘ, ӘТИСЕН САГЫНДЫМЫ? НИЧӘ ЕЛЛАР КҮРЕШМӘГӘН ӘТИНЕ НИЧЕК САГЫНАСЫҢ, ДИ? АНЫҢ ӨЗЕЛЕП ЧАКЫРУЛАРЫ ТӘЭСИР ИТТЕМЕ? ҺЕ, ЧАКЫРЫР ДА, ҮСЕП ҖИТТЕ БИТ ИНДЕ ТАШЛАП ЧЫГЫП КИТКӘН КЫЗЫ.

Нигә, нигә күзгә йокы керми соң? Күршеләре инде өченче төшләрен күрәләр бугай. Әнә сул як киштәдәгесе, саташып, нидер сөйләнеп тә алды. Поезд тәгәрмәчләре дә, «юк-юк» дип тукылдап, болай да тынгысыз күңелдәге вәсвәсәне арттыра.

Нишләп болай капыл гына юлга чыгасы итте соң әле ул? Каникулын башкача файдаланырга да була иде ләбаса. Иптәш кызларының берничәсе әнә көньякка йөрүче поездларга урнаштылар. Бер ишләре туган якларына – әти-әниләре янына кайтып китте. Ә ул әтисе янына кунакка бара, имеш. Бәлки файдасы тиеп куяр, дип уйлыйдыр әле, шуңа чакырадыр. Тияр, тими ни?

Аида ятагында әнә шундый кирле-мырлы уйларына уралып боргалана да тулгана. Юк, боларның берсе дә сәбәп түгел, өйләрендәге эчпошыргыч тынлыктан качуы иде бугай аның.

* * *

Әтисе кышкы күз ачкысыз буранлы кичтә ташлап китте аларны. Эшенә йөри торган букчасын гына алды. Әнисе һәрвакыттагыча ха-ха-халап көлеп калды. «Барыбер әйләнеп кайтасың ич син, нәрсә куркыткан буласың?» – дип тә кычкырды әле артыннан. Аида да шулай уйлаган иде. Беренче мәртәбә генә чыгып китүе түгел этисенең. Әнисе дөрес әйтә. Барыбер берничә көннән әйләнеп кайта ул. Ә бу юлы әтисе, ишекне каты итеп ябып чыгып киткәч, кире әйләнеп керде. 4 яшьлек улына кулындагы сәгатен салып тоттырды. «Истәлегем итеп тагарсың, улым», – диде. Аида янына килеп, башын күкрәгенә кысып, гадәттәгечә күзләреннән үпте дә: «Сиңа ни калдырыйм икән соң, кызым? – дип аптырап калды. Аннары сумкасыннан бик кадерләп кенә саклый торган алтын каләмле авторучкасын алып, кызына сузды. – Миңа рәнҗемә, кызым. Вакытлар узгач, син... сез аңларсыз мине». Стенага сөялеп, матур сынын кочаклап баскан хатынына борылып та карамады әтисе. Кыз аны әнисенә дә нәрсәдер бүләк итәр дип көткән иде.

Аида кечкенәдән үк гаиләдәге ниндидер бер салкынлыкны тоеп үсте. Әмма фаҗигане бөтен тулылыгы белән әнисе авырга узгач кына аңлады. Баштарак ул бик гаҗәпләнде. Нигә? Юк, ул үзенең энесе яки сеңлесе булуга каршы түгел. Ләкин әнисенә 36 яшь бит инде, олыгаеп бара. Их, бала белән генә суынган араларны җылытып, өзелгән бәхетне ялгап булса икән ул? Монысын инде 14 яшьлек кыз бала да аңлый. Җитмәсә, сәламәтлеге дә юк үзенең. Әтисе эштән кайтуга, авырыйм, дип башын бәйләп куя, йә урынга ук барып ята. Бәбигә узгач, аеруча көйсезләнде, даими игътибар таләп итә. Исен яратмыйм дип, ашарга да әзерләми башлады. Соңгы арада гел корысары белән тукланалар. Ул катык, кефир, эремчек кебек нәрсәләрнең әчегән исе бөтен әйберләргә сеңде бугай инде. Әтиләре командировкага китә башласа, өйдә кара тавыш, кайткач – тагын.

Бала гаиләгә шатлык та, тынычлык та алып килмәде. Әниләре тагын да көйсезләнә төште, әтиләре үз эченә ныграк йомылды. Малайга Вольдемар дигән исем куштылар.

– Ни өчен Вольдемар? – дип үртәлде әтиләре. – Ичмасам, Руслан, Ринат дип кушыйк. Ул бит синең белән миннән туган татар баласы.

– Нәрсә, син – Илгизәр, мин – Дамирә булгач, ул Галимулла булырга тиешмени?

Бәхәсләшү мәгънәсез иде. Аидага да исемне әниләре кушкан. Әтисе ул чакта да риза булмаган. Шуңамы, ул аңа бер мәртәбә дә исеме белән дәшмәде, «кызым» дип йөртте.

12 яшендә Аида, миңа нигә шундый исем куштыгыз, дип сорады.

Әнисе аны «Аида» дип аталучы операга алып барды. Кайтканда, аңладыңмы инде, дип сорады, опера-балет, гомумән, сәнгать турында бик озак фәлсәфә сатты.

– Шуннан, – диде кыз, – минем бу операга ни катнашым бар?

– Бәрәңге, – дип ачуланды аны шул чакта әнисе. – Ичмасам, син дә матурлыкны, сәнгать дөньясын аңлый белмисең. Музыка мәктәбенә юкка гына йөртәммени мин сине? Әтиең кебек үк бәрәңге син. – «Бәрәңге» аның иң яратып куллана торган хурлау, кимсетү сүзе.

Шушы вакыйгадан соң, әнисе еш кына: «Их, узды гомеркәйләрем заяга, – дип зарлана башлады. – Теге Бәрәңгегә эстетиканың, моданың ни икәнен аңлата алмый бимазаландым, инде кызы да...»

...Кияүгә чыгып, балага узу сәбәпле, консерваториянең беренче курсын да тәмамлый алмады, тормышын дәрәҗәле урында эшләүче иренә һәм кызына багышларга булды Дамирә. Нишлисең, кайбер хатынкызларның язмышы шундый инде, дип юатты үзен. Баштарак ирен опера тыңларга, балет карарга ияләштерергә тырышып карады. Барып чыкмагач, театр-концертлар белән генә канәгатьләнергә туры килде. Өйләрен, үз зәвыгына туры китереп, картиналар, антиквариат җиһаз, кыйммәтле әллә ниткән фарфор сыннар белән тутырды.

Әйтерсең, үги кызы түгел, бертуган сеңлесе яки берәр якын кешесе килгән.

Вольдемар әтисе белән шаярганда ялгыш кына тиеп китеп кыйммәтле кытай вазасын төшереп ваткач, Дамирә тәмам туарылды, әйтмәгәнен калдырмады, малайны кыйнап ташламакчы булып, берничә мәртәбә суккалап та алды.

Әтиләре куырылып килде: «Безнең өйдә бер таш сын бар бит инде, матур, ләкин салкынлыгы әллә каян ук өшетеп тора, шул да бик җитеп ашкан», – дип малайны үзе белән ышыклады.

Шул көнне үсмер Аида аларның бер-берсенә бөтенләй чит, капма-каршы кешеләр булуын аңлады. Аңлады да коты очты.

* * *

Сәкинә ханым (әллә апамы, ничек дип дәшәргә соң аңа) – әтисенең яңа хатыны яшьтер, чибәрдер, мөгаен. Гадәттә, олыгая башлаган ирләр яшь хатынга өйләнәләр бит.

Аида тынычсыз төннән соң авырайган башын терсәкләренә салып, ирексездән үзалдына Сәкинә апасы белән бәхәсләшергә тотынды. «Алдан ук ачыклап куйыйк, безнең арада чебен аягы кадәр дә туганлык мөнәсәбәтләре булырга мөмкин түгел, – дип уйлады ул. – Мин, каникулда ял итәргә дип, үз әтием янына килдем. Бик ялынып чакыргач кына...»

– Нәрсә, кызый, син төшмисеңмени? Поезд бүтән бармый, бу – соңгы тукталыш.

PRESSA.RU

Проводницаның кырыс тавышы аны уйларыннан аерып, чынбарлыкка кайтарды. Аида ашыга-ашыга җыенды да башкаларга иярде. Перронда... халык. Кайберләре үзләренең танышларын танып кычкыра, кул болгый ук башладылар. Кыз вагоннан сикереп төште дә халык арасында буталып калды. Кешеләр сирәгәйгәч, кемдер аны арттан килеп кочып алды. Әтисен шунда ук таныды ул – сулышыннан, исеннән. Борылып, аның муенына асылынганын сизми дә калды.

Әтисеннән ниндидер бөтенлек, рәхәт тынычлык бөркелә.

– Әтием! Әтием! Әллә ничек, үзгәргәнсең син, яшәреп киткәнсең димме?

Ходаем, ни сөйли ул? Шулай дип күрешергә әзерләнгән идемени? Дөрес, әзерләгән сүзләре аның хатыны Сәкинәгә иде. Ә ул күренми. Килмәгән. Дөрес эшләгән. Әтисенең үзе генә булуы яхшырак та әле.

– Бездә такси йөрми, кызым, – диде әтисе, Аиданың юл сумкасын алып. – Хәер, ерак яшәмибез без.

Юл буе сөйләшеп кайттылар. Аидага үз тормышы: институт, имтиханнар турында сөйләве җиңел булды, калганнары – газап. Бигрәк тә өйләрендәге хәлләргә кагылганнары.

– Менә кайтып та җиттек, – диде әтисе, сарыга буялган капканы ачып. Алар агачларга, чәчәкләргә күмелеп утырган гап-гади авыл йорты янына килеп туктаганнар икән. – Уз, кызым. Юынып ал да чәйләп алырбыз. Тиздән Сәкинә апаң да кайтып җитәр. Иртәрәк кайтырга тырышырмын, дигән иде.

Һе, әтисенең бу хатыны эшли икән. Кызык. Димәк, үзен иренә генә багышламаган.

Әтисе бертуктаусыз сөйләнә. Дулкынлана, күрәсең. Бәлки, килеп дөрес эшләмәгәндер Аида. Яшәсеннәр иде үз көйләренә тыныч кына.

– Менә хуҗабикә дә кайтып җитте...

Әтисе аны каршыларга капкага юнәлде.

Хатын ашыга иде. Шуңамы, аз гына аксабрак атлый. Яшь тә түгел икән: әтисе белән бер чамадарак. Артык чибәр дә түгел. Сөйкемле үзе, мөлаем. Зәвыклы булса да, киенүе дә гади генә. Әнисе моның янында курчак кебек. Һе, әтисе нәрсәсен ошатты икән соң бу апаның, дигән уйлар узды Аиданың башыннан.

– Килеп җиттеңме, Аида? – дип, кызга кулын сузды ханым. – Рәхим ит! – Аннан әтисенә дәште. – Әйттем бит мин сиңа бүген килә дип. Өченче көн дә, кичә дә сине каршыларга барды ул, Аида. Килүең өчен рәхмәт!

Сәкинә ханым үзен гади, табигый тота. Төчеләнми дә, ярарга да тырышмый. Шул табигыйлеге белән киеренкелекне йомшартты да куйды. Юкка гына әтисе аның кайтканын көтмәгән икән шул. Аида да үги ана йортына түгел, якын туганнарына кунакка килгәндәй хис итте.

Юлда килгәндә туган көнләшү хисе дә, киеренкелек тә әллә кая югалды. Әнә Сәкинә ханым тыныч кына өстәл әзерли. Әтисе аңа булыша. «Өйдә ул мондый эшләрдә катнашмый иде», – дип, тагын көнләшепме-гаҗәпләнепме уйлап куйды кыз.

Өйгә тәмле аш, камыр ризыклары исе таралды. Аидага бала чагына кайткан кебек рәхәт булып китте. Әбисе авылдан килгәч, әнә шундый тәмле исле аш, өчпочмаклар пешерә иде. Әнисе андыйга оста түгел. Алар гомер буе кичәге кәбестә ашы, кибеттән алган кәтлит, сосиска, колбаса белән йомырка кыздырып ашыйлар. Ә монда ниләр генә юк! Кайсын гына ашасаң да, авызда эреп китә.

Ашаганнан соң, тиз генә табынны җыеп алып, Сәкинә ханым эшенә китте.

– Маратны кайтышлый бакчадан үзем кереп алырмын. Син бүген барып йөрмә инде, Аида белән бул, – диде әтисенә. – Ә син, Аида, ятып тор. Юлдан соң арыгансыңдыр, – дип, кызны верандадагы карават янына озатып куйды.

– Ошатсаң, синең урының бирелә булыр. Бик рәхәт монда. Кичләрен айны күзләргә, йолдызлар санарга була. Нәкъ синең кебек матур кызлар урыны инде.

«Уллары да бар икән. Марат исемле. Матур исем. Кем кушты икән? Әтиседер, мөгаен», – йокы аралаш Аида шулай уйлады.

* * *

...Әтисенең, урындык алып, әкрен генә Аиданың баш очына килеп утыруыннан, йокымсырап киткән кызының чәчләреннән сак кына сыйпавыннан уянып китте ул.

– Бик-бик сагындым сине, кызым. Вольдемарны да. Ул ничек, зур үскәндер инде? Мине исенә төшерәме?

«Ә әнине сагынмадыңмыни?» – дип сорыйсы килде Аиданың. Дәшмәде. Әтисенең кәефен җибәрүдән курыкты. Әнә бит нинди бәхетле елмая ул.

– Ә син эшкә бармыйсыңмыни, әтием? – Аида әтисенең үтә дә якын кытыршы учларын кулына алып, яңакларына куйды.

– Мин отпуск алдым, кызым. Синең белән буласым килә. Чакыртып алмасалар.

– Сез бер дә ачуланышмыйсыздыр, әйеме, әтием?

– Болай да катлаулы тормышны нигә катлаулandырырга, кызым?

– Ул кем? Кайда эшли?

– Китапханәче. Без аның белән хастаханәдә таныштык. Хәтерлисеңме, син җиденчедә укыганда мин, аварияга эләгеп, өч ай хастаханәдә яткан идем. Ул да шунда дәвалана иде. Егылганнан соң, аякларының нервлары кысылган булган. Теге көнне өйдән чыгып киткәч, мин кая барырга белми таңга чаклы урамда йөрдем дә, иртән туп-туры аның янына киттем. Адресы да юк иде. Бары бер район үзәгендә яшәгәнлеге генә истә калган. Эзләп таптым тагын. Ул кумады. Шулай яшәп киттек.

– Мин синең өчен бик шат, әтием!

«Ни сөйли ул? Шулай дип әйтергә әзерләнгән идемени? Әнисенә ни дияр? Дөрес, ул аңа әтисе янына барачагын әйтмәде. Башка шәһәргә практикага җибәрәләр диде дә бетте. Әнисе дә, кая, озаккамы, дип кызыксынмады».

* * *

Башта дөп-дөп аяк тавышлары ишетелде, аннан ишек шыгырдады. Кечкенә малай йөгереп килде дә әтисенең алдына менеп утырды.

– Син нигә Алма апаң белән исәнләшмисең? – дип битәрләп алды аны әнисе.

– Исәнмесез, – диде Марат, олыларча итеп. Аннан, әкрен генә әтисенең тезеннән төшеп, Аида янына килде дә нәни бармагы белән аның кофтасындагы самолет төшерелгән значокка кагылды.

– Реактив самолетмы?

Аидага кинәт эссе булып китте. Малай аңа Вольдемарның яшькелт күзләре белән карый, аның тавышы белән эндәшә иде. Ул тиз генә, бармагын чәнчи-чәнчи, малайның күлмәк кесәсенә значогын беркетте. Марат шунда ук аны ниндидер Сережага күрсәтеп мактанырга йөгерде. Аннары әйләнеп керде дә:

– Син чынлап та минем апаммы? Нигә алайса озак кайтмадың? Сережаның апасы атна саен кайтып йөри әнә, – дип сорады. Тавышы өлкәннәрнеке кебек таләпчән яңгырый.

– Мин укуда идем. Моннан соң мин дә еш кайтып йөрермен, – диде Аида, малайның әтисенеке кебек бөдрә чәчле башын битләренә кысып. (Ни сөйли ул? Нинди еш кайтып йөрү, ди?)

– Ә син минем белән су коенырга йөрерсеңме? Теге зур башлы Илһам миңа «каз боты ашатканда» якларсыңмы?

– Әйе.

Яклаучысы барын тойган малай Аиданы кысып кочаклады. Аннан, күзләрне әчеттереп, Вольдемар исе килә иде.

...Төп-төгәл өч атна яшәде Аида биредә. Тагын калырга кыстаганнар иде дә, практика үтәсе бар, дип ялганлады. Әтисе, ышанмаса да, аңлады аны.

Шулай да китәсе килми. Шундый тыныч, рәхәт бу йортта.

Беркөнне әтиләре соңлап кайтты. Маратны йоклаткач, Сәкинә апасы Аида белән озак кына сөйләшеп-серләшеп утырды.

– Бигрәкләр дә авыр ияләнде Илгизәр бирегә, – дип башлады ул сүзен. – Зур урыннарда эшләгән кешегә вазыйфасы да кечкенә тоелгандыр инде. Аннан бигрәк сезне сагынды. Беркөнне әйттем үзенә, бар, гаиләңә кайтып кил, теләсәң, калырсың, теләмәсәң, кире килерсең, дидем. «Юк, диде, бер кискән икмәк кире ябышмый. Кешенең дә, кошларныкы кебек, оясы бер генә була. Минем җылы, уңайлы оям биредә, сезнең янда». Ә син гел килеп йөр шулай. Күрәсең бит, әтиең нинди бәхетле!

Бу сөйләшүдән соң, Аиданың тынычлыгы югалды. Бердән, Сәкинә апасының зирәклегенә, киң күңеллелегенә сокланса, икенчедән әтисенең бәхетле булуына шатланды. Һәм... әнисен чын күңеленнән җәлли башлады. Нинди бәхетсез икән бит ул?!

* * *

Теге көннәрдә – әтиләре чыгып киткәч, әниләре балтасы суга төшкән кешедәй, миңгерәеп калды. Баскан урынында тораташтай ката да кала. Вольдемарның илереп елаганын да ишетми хәтта. Йә булмаса, пианино артына утыра да уйный да уйный. Аиданың коты очты. Әллә...

Шөкер, узды тагын. Әниләре эшкә урнашты. Сирәк булса да, ашарга әзерли, өй җыештыра башлады. Әмма йөзеннән моңсулык, күзләреннән сагыш китмәде. Аида аңлый: аны ялгызлык, хәтта үкенү хисләре изә бугай. Әтиләрен һаман да сагына, кайтыр дип көтә, ахрысы. Аида да көтте әтисен. Быелгы җәйгә кадәр көтте...

Беркем театр уйнамый, ялганламый. Барысы да гап-гади, ап-ачык бу йортта.

* * *

Аида иртәгә китә. Соңгы тапкыр су буйларын, комлыкны әйләнде. Өйне җыештырып чыгарды, үзе йоклый торган веранданы тәртипкә китерде. Сәкинә апасының кичтән әйткән сүзләрен искә төшереп, моңсу елмаеп куйды.

– Аида, бел, бу йортта синең үз урының бар, – диде ул кызга. – Ул да, без дә сине сагынып көтәрбез.

Кызык, йорттагы һәрнәрсә гомер буе биредә яшәгәндәй үз булып өлгергән икән инде аңа. Менә түгәрәк аш өстәле. Аның өстендәге төрле тәм-томнар ап-ак чигүле сөлге белән каплап куелган. Һәрвакыт үзенә тартып, ымсындырып тора. Әйтерсең, йорттагы иминлек, тынычлык турында сөйли.

Түрдәге тәрәзә кырыенда – әтисенең эш өстәле. Китаплар, эш кәгазьләре тәртипсез тәртип белән өеп куелган. Аларга беркем кагылмый, тузгытмый, актарынмый. Әти өстәле, әти урыны – изге бу өйдә.

Шунда ук ап-ак рамда өчәүләп төшкән фоторәсем. Әтисе бер кулы белән Сәкинәнең җилкәсеннән кысып кочаклаган. Гүя ычкынып китәр дә югалтырмын дип курка. Ә Сәкинә ханым, иренә авыша төшеп, баласын күкрәгенә кыскан. Маратның исә куллары әнисендә, күзләре әтисендә. Тигез әти-әниле сабыйларга гына хас бәхетле елмаю белән елмая үзе.


Оя, дип, әтисенең сүзләрен искә төшерде Аида. Кешеләрнең дә кошларныкы кебек оясы була. Бер генә була!

PRESSA.RU

МИН БУ ТАРИХНЫ БОХАРАГА БАРГАЧ ИШЕТТЕМ. ИШЕТТЕМ ДӘ, БИК ОЗАК УЙЛАНЫП ЙӨРДЕМ: ӘЛЛӘ ШУШЫ ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШНЫ ИШЕТҮ ӨЧЕН МЕҢӘР ЧАКРЫМ ЮЛ УЗЫП КИЛДЕММЕ СОҢ МИН?



Рәмзия КАШАПОВА



ҖАНЫМ ҖӘЛ ТҮГЕЛ СИҢА...

Барыгыз да беләсездер, Урта Азиядә егет белән кыз үзләре танышып, алдан очрашып йөреп кавышмый. Гомер-гомергә шулай булган: яшьләрне анда бер-берсенә ярәшәләр генә.

Мәликәнең яшьлеге җитмешенче елларга туры килә. Мәктәптә «яхшы» билгеләренә генә укучы кыз, җиңел генә институтка да барып керә. Иҗтимагый эшләрнең үзәгендә кайный, студентлар отрядына языла.

Язгы җылы көннәрнең берсендә алдан әйтмикисәтми генә Мәликәләргә бер хатын килеп керә. «Әти-әниең өйдәме? Миңа алар белән сөйләшергә кирәк иде», – ди ул ишекне ачкан кызга. Чит кеше тавышын ишетеп, түр яктан әнисе чыга. Кунакның нигә алар бусагасын атлап керүен сорап та тормыйча, аны өстәл янына чакыра, чәй куя. Сүздән элек – сый. Шәрыкта һәр йортта язылмаган кагыйдә бу.

Йөрәгенә нидер сизенеп, Мәликә бүлмәдән чыгып китә. Җәйге веранданың ачык тәрәзәсе аша өлкәннәрнең өзек-өзек ишетелгән сүзләрен аңларга тырыша. Аның «башын ашарга» йөрүе түгелдер бит бу хатынның?!

Уйлаганың алга килә, диләр. Мәликәне күрше мәхәлләдәге бер егеткә ярәшеп тә куялар. Кияү буласы кеше инде институт тәмамлаган, археология буенча бер комиссиядә эшли икән. Күп балалы гаиләдә өлкән бала ди.

Әти-әни теләгенә каршы төшү юк Урта Азиядә – балалар кечкенәдән шулай тәрбияләнә. Сыкрануын эчкә яшереп, Мәликә дә ризалаша.

Зур гаиләгә килен булып төшә ул. Өй эчендәге тавык та чүпләп бетермәслек эшләре янына, иренең кечерәк эне-сеңелләрен кайгырту да өстәлә: хәтта дәресләрне дә җиңгәләре белән бергә әзерли алар. Олы абыйларының хатыны буларак, каенсеңелләренең киләчәге турында уйларга, аларга бирнә әзерләшергә дә тиеш була.

Шулай итеп еллар уза. Төп йорттан аерылып башка чыкканда, икенче уллары мәктәп тәмамлый торган була инде. Кияүгә чыккан мәлләрдә төннәр буе күз яшьләре түксә дә, бергә яши башлагач, Мәликә дә иренә күнә, иялəшә, хәтта Әкрамны ярата да башлый.

Алар сатып алган йорт XVIII гасыр архитектурасы һәйкәле булып чыга. Хуҗалары – Бохара яһүдләре – шактый хәлле кешеләр, СССР таркалгач, үзләренең тарихи ватаннарына китәргә кирәк дигән карарга киләләр. Инде берничә буын яшәгән шушы нигезләрен, йорт эчендәге барлык җиһазлары белән ашыгыч рәвештә сатып, тиз генә юлга кузгалалар. (Израильдән әледән-әле шалтыратып, яңа хуҗаларның, алардан да бигрәк йортларының хәлен белешкәләп торалар икән.)

Музей кебек шушы матур йортта яшәп китәләр алар. Мәликә белән Әкрам эшли, балалар укыйлар. Уң ягында барлыкка килгән авыртуга Мәликә башта әллә ни игътибар да итми. «Үтәр әле», – ди. Билен тота-тота гына иренә иртәнге ашны әзерли, улларын укуга озата, аннан үзе эшенә кузгала. Авырту исә көннән-көн көчәя генә. Табибка бармый чарасы калмый. Анализлар тапшырталар, бер кабинеттан икенчесенә йөртәләр. Берничә көннән табиб Мәликәне үзенә чакыртып ала. «Сеңлем, хәлләр шактый җитди. Нык булыгыз. Сездә яман шеш...» – ди.

– Алар ничек яшәр?

Табибка уен кычкырып әйтүен үзе дә сизми кала ул. Әйе, алар ничек яшәр? Уллары, ире... Бигрәк тә ире. Әкрам бит тормышка бигрәк җайлашмаган – эшеннән кала берни белми!

Әкрам ул көнне эштән бик канәгать кайтып керә: саллы контрактка кул куйганнар икән – мәчеткә реставрация ясаячаклар. Аның йөзенә карау белән Мәликә бер карарга килә: «Берсенә дә әйтмим!» Иренең борчылып: «Ә синең хәлең ничек?» – дип соравына: «Әйбәтрәк», – дип кенә җавап бирә. Соңгы вакытта ире аннан башка бер адым атламый шул: нәрсә эшләсә дә, башта аңа хатыны белән киңәшләшү кирәк: «Мәликә, син ни уйлыйсың?», «Мәликә, син нәрсә әйтәсең?» Хәтта командировкаларга киткәч тә бертуктамый шалтырата: аның тавышын гына ишетсен.

Халыкта «кайгы килсә – капкаң ач» дигән сүз бар. Дөрес ул. Әйе, кайгы ялгыз йөрми. Беркөнне Әкрам үзләренең ишегалдында аңын җуеп егыла. «Ашыгыч ярдәм» аны хастаханәгә алып китә. Диагнозны бик тиз куялар: бөерләре эштән чыккан, кемнеңдер бөерен күчереп утыртсалар гына ул исән калачак...

«Хәсрәт менә шундый була икән ул, – дип уйлый Мәликә. – Үземдә яман шеш. Ирем теләсә кайсы мизгелдә үлеп китәргә мөмкин. Ходай бу сынауларны ни өчен җибәрә икән? Нинди гөнаһларыбыз өчен?»

Кайгысыннан сыгылып төшкән хатынны табиблар: «Борчылмагыз әле. Туганнары күп дидегез бит: ярдәм итәрләр – берсенеке булмаса, икенчесенеке туры килер», – дип юаталар. Мәликә башта үзе дә шулай уйлый. Абыйларын ташламаслар. Ул бит аларның һәрберсен укытты, югары белем бирде, хәтта туйларын да үзе үткәрде. Әле дә ярдәм кирәк чакларда гел аңа килеп егылалар...

Дуслар авыр чакта сынала, диләр. Туганнар да шулай. Әкрамның эне-сеңелләре: «Бөеремнең берсен бирәм сиңа», – дип әйтмиләр. Алар бер сүз дәшмиләр! «Иң авыры – шуны аңлаган көн булды...» – ди Мәликә.

«Мин аны барыбер коткарам!» Үз-үзенә шулай дип сүз бирә ул. Компьютер артына утырып, төрле илләрдәге клиникаларга хат яза башлый. Израиль белән Германия табиблары: «Без бары тик трансплантация тәкъдим итә алабыз», – дип җавап бирә. Хәер, алар куйган бәя дә Мәликә өчен коточкыч күп булып тоела: бөтен йорт-җирен сатса да, җитмәячәк. Хезмәттәшләренең берсе: «Мондый операцияләрне Һиндстанда ясыйлар, әллә аларга мөрәҗәгать итеп карыйсыңмы?» – дип киңәш бирә. Җавап озак көттерми – диагностика узарга килергә чакыралар. Әмма барысы да кабат акчага килеп төртелә...

«Ходай күпме гомер бирсә – мин шуның кадәр яшәрмен. Ә ирем үләргә тиеш түгел!»

«Коткарам дигәч – коткарам!» Хатын кискен бер карарга килә дә, җыенып, ирен дәвалаучы табиблар янына китә. «Әгәр туры килә икән – минем бөеремне алыгыз! – ди ул. – Тик бөеремнең берсендә яман шеш...»

Сүзсез калган табиблар аны анализлар бирергә озаталар.

Икенче көнне хастаханәдә Мәликәне аяктан егардай яңалык көтә! «Сездә бернинди дә яман шеш юк! – ди табиблар. – Бөерегез ялкынсынган булган, әмма ул инде узган диярлек». Яңалыкның икенчесе дә сөенечле булып чыга: аның бөере Әкрамга туры килә – күчереп утыртырга мөмкин!

Бу минутларда аның ниләр кичергәнен күз алдына китерү авыр түгел. «Еларга да, куанырга да белмәдем», – ди ул.

Операцияне Һиндстанда ясыйлар. Ул уңышлы уза. Мәликә шактый тиз аякка баса, Әкрамга тернәкләнү өчен әле вакыт кирәк була.

Ул көннәрдән соң ике ел узган инде. Икесе дә пенсиядә булсалар да, әле һаман эшлиләр: операция өчен бурычларын түләп бетерәселәре бар. Йортларының архитектура һәйкәле булып саналуын әйткән идем бит: шәһәр җитәкчелеге белән үзләрендә туристларны кабул итү турында килешү төзегәннәр. Шактый гына турист маршрутлары алар өе аша уза. Моңардан зур табыш алмасалар да, ярап куя.

...Әңгәмәбез ахырына якынлашканда телефон шалтырады. Ире шалтырата. Сиңа яңа күлмәк алдым, ди бугай. «Мин ул күлмәкләрне кайчан киеп бетерермен икән?» – дип көлә Мәликә. Аннан, безгә таба борылып, иренең җавабын кычкырып кабатлый: «Алда гомер озын бит әле безнең – барысын да үзең киеп туздырырсың!»

Фото: автор

PRESSA.RU



ИКЕ ТӨРЛЕ СЕРБИЯ



Альбина ХӘКИМУЛЛИНА

Казан. 2013 ел. Универсиада. Дустыма иптәшкә дип кенә баскетбол матчына барган җирдән, үзем дә сизмәстән, Сербия командасы өчен җан атып утыра башладым. Һәм шул мизгелдә күңелдә бер теләк бөреләнде: мин, һичшиксез, Сербияне күрергә тиеш! Ул уенда Сербия баскетболчылары, АКШ командасын җиңеп, бронза медаль яулады. И шатланганнарым! Әйтерсең, ул медальне миңа бирәләр! Билгеле инде, бу шатлыгымны дусларым, хезмәттәшләрем белән дә уртаклаштым. Һәм берничә елдан: «Мин Сербиягә барам!» – дигән хәбәрне җиткергәч, алар: «Баскетболчыларың артынданмы?» – дип шаярттылар. Шулай көлештек тә, чемоданнарымны тутырып, берүзем Сербиягә чыгып киттем. Баскетболчылар артыннан түгел, яңа хис-кичерешләр һәм илһам артыннан!

Чәйсез кунакчыллык

Россиядән Сербиягә барырга виза кирәкми. Отпускта кайсы илгә барыйм икән, дип сайланып утырганда бу фактор да зур роль уйнады. Икенчедән, Сербия – чагыштырмача арзан ил. Анысын да игътибарга алдым. Алар еврога бәйле түгел, шуңа күрә бәяләр дә тешләшми. Үз акчалары – динар бар. Россия акчасына күчерсәк, бер динар илле сигез тиенгә тигез.

Казанда вакытта ук «ВКонтакте» социаль челтәрендә «Мин Сербияне яратам!» дигән төркемне табып, виртуаль рәвештә әлеге ил белән таныша башлаган идем. Ил белән дә танышам, үземә дуслар да эзлим. Җирле кеше белән танышсаң, комачауламас: туристлар аягы басмаган почмакларны сорашырга, бәлки әле дусларча экскурсия үткәрүен дә сорарга мөмкин булыр. Шулай эзләнеп утырганда, Вук исемле серб егете белән танышып киттек. Ул миңа кызыклы гына тәкъдим ясады: егет мине Белград буйлап йөртергә, шәһәрнең истәлекле урыннарын күрсәтергә вәгъдә бирә, ә мин, үз чиратымда, аның белән фәкать рус телендә генә сөйләшергә тиеш булам. Шул рәвешле рус телен камилләштерәсе килә икән Вукның. Олы яшьтәге серблар мәктәптә рус телен укыган булса, хәзер ул укытылмый, теләге булган яшьләр рус телен мәктәптән тыш өйрәнергә мәҗбүр. Россиягә эшкә килергә теләгән Вук та менә шулар рәтендә. Әлбәттә инде, аның тәкъдимен бик теләп кабул иттем.

Яшәү урыны итеп кунак йортын сайладым. Кунак йорты – ул шәхси йорт, хуҗалар үзләре анда яшәми, бу йортның бүлмәләрен туристларга арендага биреп тора. Кунакханәләргә караганда арзанрак булуы белән җәлеп итте ул мине. Шул ук вакытта монда, хостеллардагы кебек, кеше өстендә кеше дә яшәми – берүземә бер бүлмә иде.

Кунак йортының хуҗабикәсе – Анна исемле математика укытучысы – мине бик җылы каршы алды. Ә мин әйберләремне калдырдым да тизрәк шәһәр карарга ашыктым.





Беренче көн шулай чыгып киттем, икенче көн... Өченче көнне Анна яныма килеп җитте. Нәрсәгәдер үпкәләгән сыман күренә. «Альбина, син ни өчен безнең белән каһвә эчәргә килмисең?» – ди. Аптырап киттем. Андый гадәт барлыгын белми идем бит. «Кайчан киләсе соң?» – дим. «Без иртән һәм кичен каһвә эчәргә җыелабыз, син дә кил!» – ди Анна. Бу мөлаем ханымны үпкәләтеп булмый бит инде – өченче кичне мин дә каһвә эчәргә килдем. Тик каһвә яратмавым гына эшне харап итеп ташлый язды. Анысы белән бер аптыратсам, чәй сорап Аннаны икенче тапкыр аптыраттым. «Кайдадыр чәй бар иде бугай инде, тик аны кайнатырга чәйнек юк бит», – ди. Серблар авырган вакытта гына чәй кайнатып эчәргә мөмкиннәр. Шуңа күрә минем чәй соравым Аннаны гаҗәпләндергән дә инде. Биредә чәй, гомумән, кадерсез эчемлек булып чыкты. Кафеларда һич очратырмын димә. Кибетләрдә дә юк. Зурракларында гына почмактагы иң кечкенә киштәдә берничә кап чәй тезелеп торырга мөмкин. Минем кебек туристлар өчендер инде анысы да.

Шулай да ул кичне мин чәй эчтем. Анна шкафның караңгы бер почмагыннан анда әллә кайчаннан бирле яткан пакетлы чәй табып чыгарды. Каһвә пешерә торган туркада су кайнатып бирде. Анна һәм башкалар – каһвә, ә мин тәмсез чәй эчә-эчә җылы әңгәмә кордык.


Сербиядә бөтенләй дә чәй эчмиләр икән!

Шәһәр уртасында – хәрабәләр

Сербиянең башкаласы Белград – Европадагы иң борынгы шәһәрләрнең берсе. Кемнәр генә үз эзен калдырмаган монда: римлылар, византиялеләр, аварлар, славяннар, төрекләр... Бу халыклар Сербиянең милли йөзен булдыруда да катнашкан. Милли ризыклары, мәсәлән, төрекләрнекенә охшаган: серблар шулай ук ит яраталар, аны төрлечә пешерәләр (каһвә яратуларын да төрекләргә сылтарга була торгандыр). Буза дигән эчемлекләре бездәге квасны хәтерләтә. Бодай яки тарыны әчетү ысулы белән ясала ул. Ә сербларның үз-үзен тотышлары – итальяннарның күчермәсе. Серблар да сөйләгәндә куллары белән төрле хәрәкәтләр ясамый тора алмыйлар, бик хисчәннәр. Мин Сербиядә хәтта Һиндстан чалымнары да күрдем. Монда да искитәрлек гүзәллекләрдән башлап, кот очарлык күренешләргә

Фото: www.pixabay

PRESSA.RU



■ Югославиянең элекке лидеры Иосип Броз Титоның төрбәсе яшеллеккә, чәчәкләргә төренеп утыра. Ул шулай дип атала да – Чәчәкләр йорты. Тито үзе дә бик оста бакчачы булган, дип сөйлиләр.

■ Белградның йөзек кашы – Калемегдан кирмәне. Бөтен туристлар шунда агыла.



Язмыш җилләре Белград шәһәрен шактый кыйнаган.

хәтле тап булырга мөмкинсең – нәкъ Һиндстандагы кебек.

Сүземне Белградның тарихи шәһәр булуыннан башлаган идем бит әле. 1999 елда НАТО бомбалары салган «яра»лары һаман да исән әле. Шартлау нәтиҗәсендә бик күп биналар, шул исәптән Югославия Союздаш Республикасының Оборона министрлыгы бинасы (ул вакытта Сербия дигән аерым ил юк, Белград – Югославия башкаласы) да зыян күрә. Әлеге бина бүгенгәчә төзекләндерелмәгән. Махсус шулай эшләнгән бу. Ярым җимерек бина тере һәйкәл кебек – дәһшәтле көннәр турында үткәнбарганның исенә төшереп, «тарихыңны онытма» дип «кычкырып» тора. Мин яшәгән кунак йорты әлеге бина урнашкан урамның каршы ягында гына иде. Шуңа күрә көн саен һәйкәл-бина янынан узып йөрергә туры килде.

Вук мине Калемегдан кирмәненә алып барды. Борынгы архитектура үрнәкләре, ниндидер казылмалар күрермен дип әзерләнеп барган идем – ялгышканмын. Биредә тарих кына түгел, хәзерге заманга да урын бирелгән икән: динозаврлар паркы бар, шунда ук теннис корты, баскетбол мәйданчыгы. Әлбәттә инде, музейлар, күргәзмәләр дә бар. Кирмәнне тулысынча әйләнеп чыгу 6-7 сәгать вакытыбызны алды.

Биредәге бер храм игътибарымны җәлеп итте. XVI–XVII гасырда землянка рәвешендә тау куышын уеп ясалган ул. Икенче яктан карaганда, анда храм бардыр дип уйламыйсың да – тау гына күренә.


Храмнарны карап, тарихлары белән танышып йөрү ошый, тик минем мәчет күрәсем килә. Госман империясе астында яшәгәндә, Белградта 200 ләп мәчет булган диелә. Ә хәзер нибары берсе генә исән. XVIII гасырда бөтен мәчетләр дә җимерелә, император «Байраклы» дип аталган бер мәчетне генә калдырырга куша. Анысының да язмышы катлаулы. 2004 елда аңа ут төртәләр, аннары озак вакыт төзекләндерәләр. Менә шуны барып күрәсем килеп, телефонымдагы картада «мәчет» дип җыйдым. Тапмады. Шәһәр халкыннан юл сорарга уйлагач, бер гаҗәп хәлгә тап булдым: серблар мәчетнең кайда икәнен белмиләр! «Мәчет? Нинди мәчет?» – дип, үземне үк сорауларга күмделәр. Адашып йөри торгач, бер кечкенә генә мөселман кибетенә тап булып, шунда сатучы булып эшләүче кыздан гына юлны сорый алдым.

Мин мәчетне эзләп тапканда көн кичкә авышкан иде инде. Каравылчы мине берсүзсез эчкә уздырды. Мәчет дигәннәре бик кечкенә генә. Белградта яшәүче бөтен мөселман берьюлы килсә, монда сыймыйлар да, урамда басып торасы булачак. Эчтә караңгы. Тәрәзәләр кечкенә, тар гына, шуңа күрә көн яктысы мәчет эченә бер күзе белән генә карый. Шулай да мәчет – мәчет инде. Сәдака салып, күңелемә тынычлык табып чыктым.

«Тере» манара

Ниш дигән кечкенә генә шәһәрчеккә бер танылган манараны күрү өчен махсус бардым. XIX гасырда Госман империясенә каршылык күрсәткәндә серблар җиңеләләр. Меңләп серб үтерелә. Император, аларның башларын кисеп, тиреләрен салдырып, баш сөякләрен манара диварына «беркетеп» чыгарга фәрман бирә. Госман империясенә каршы чыгарга теләүчеләрне шушындый язмыш көтә, дип, шом таратып торырга тиеш була ул. Диварда баш сөяге сыярлык кына тишекләр ясыйлар, сөякләрне шунда куеп чыгалар.

Мин бу вакыйга белән Казанда вакытта ук танышкан идем инде. Тик Челе-Кула манарасын үз күзләрең белән күргәч, тәннәр чемердәп китә. Ул заманнан соң шактый



■ Ниш шәһәрендә дә мәчет таптым мин. Мәчет дип, аның хәрабәләрен генә инде. Кайчандыр мөселманнарның гыйбадәт кылу урыны булган Аллаһ йортын җимергәннәр, шуннан соң төзекләндереп тормаганнар.

Аэропортта ук: «Белградка рәхим итегез! Сезгә монда ошар дип өметләнәбез», – дип каршы алганнар иде, озатканда: «Ошаттыгызмы? Без бик шат! Тагын килегез!» – дип озатып калдылар. Сүз уңаеннан, Сербиядән Черногориягә чыгарга уйлаганнарга бик җиңел: таможняда паспортыңны гына карыйлар, мөһер дә сугып тормыйлар, чыгарып җибәрәләр. Серблар үзләре Черногория халкын яратмый гына (югыйсә әле күптән түгел генә бер дәүләт булып яшәгәннәр бит инде). Черногориянең диңгезе бар шул – зур суы булмаган күршеләрне көнләштерә торган диңгезе.

сулар аккан, баш сөякләрен алып, кадерләп күмүчеләр табылган. Сөякләрнең бер ише музейларга тапшырылган. Ә 50 ләп баш сөяге бүген дә манара диварыннан сиңа текәлеп тора. Серблар өчен бу тарих та әһәмиятле. Ил азатлыгы өчен көрәштә бабаларының нинди бәһа түләгәнен күрсәтеп тора торган символ ул.

Шәһәрнең үзәк урамы буйлап барасың-барасың да, крепостька килеп «төртеләсең». Шунысы кызык: тыштан бик борынгы күренгән кирмәннең эченә керүгә, замана алмашына: заманча рестораннар, кибетләр, граффити белән чуарланган диварлар чолгап ала.

Ниш шәһәрендә дә мәчет бар, ләкин ул эшләми. Аның җимерекләре койма белән уратып та алынмаган, беркем тарафыннан сакланмый да. Шуңа күрә монда кереп йөрүчеләр, артларыннан бер өем чүп калдыручылар да бар. Гомумән, Белград та, Ниш та чүпкә «бай». Һиндстан белән чагыштыруым да шуңа бәйле инде.

Тәмле тел, киң күңел

Начар тәэсирләрне юып төшерергә Сербиянең гүзәл табигате ярдәм итте. Биредә бер генә минутка да яшеллеккә сусамадым. Парклар, урманнар, таш урам уртасында чәчәккә күмелеп утырган клумбалар...

Шәһәр урамнары туп-туры бара-бара да, кисәк борылып, таудан түбән таба төшеп китә. Анда инде атлап түгел, йөгереп барасың. Серблар күперләрне бик ярата – кайда корып була, шунда корып чыкканнар. Һәм, әлбәттә инде, сүз арасында милли каһарманнары – танылган уйлап табучы Никола Тесланың исемен кыстырып куялар. Аның белән бик горурлана серблар. Музеена һәрчак чират була, ул чиратта туристлар гына түгел, серблар үзләре дә тора.

Серблар урамда аптырап басып торганыңны әллә каян күреп алалар да: «Барысы да яхшымы? Ярдәм кирәкмиме?» – дип килеп эндәшәләр. Юлны да бик теләп күрсәтеп җибәрәләр. Тик алар «прямо» дигәндә турыга түгел, уңга китәргә генә кирәк.
Тел үзенчәлекләре инде бу: аларда «прямо» русча «направо» дигәнне аңлата икән. Берничә тапкыр дөрес китмичә адашып йөргәннән соң, тәки истә калдырдым мин моны.

Мондагы автобусларда кондуктор, контролерлар юк. Шуңа күрә рәхәтләнеп «куян» булып йөри аласың. Тик халыкның күпчелеге түләп йөри, транспортка билет алып керә. Бу да тәрбиядән килә инде. Сербларның тәмле телле булуы да игътибарны җәлеп итә.

Серблар бик кунакчыл, ярдәмчел халык.

Сербиядә русча белүчеләр шактый. Автобуста телефоннан русча сөйләшкәнемне ишетеп, олы яшьтәге кешеләр борылып-борылып карый, үзләре дә сүзгә кушылып китәләр иде: «Син Россиядәнме? Без дә русча беләбез бит, мәктәптә өйрәнгән идек». Ә иң кызыгы «Мин Россиядән, ләкин рус түгел» дигән теманы аңлатырга тотынгач башлана. Ничек инде, дип аптырыйлар, сорашалар, кызыксыналар. Андагы кешеләргә татарлар турында сөйли алуыма шатланып кайттым.

Яшьләр инглиз телен бик яхшы белә. Үзем өчен бер ачыш та ясадым: Белград кинотеатрларында фильмнар серб теленә дубляж ясап күрсәтелми, оригинал телендә күрсәтелә. Экран астында сербча субтитрлар гына чыгып бара. Бу да телне өйрәнгәндә бик зур ярдәмче, әлбәттә.

...Сербиядә булып кайтканыма байтак вакыт үтте инде. Шулай да мин һәр көнне Сербия кыйпылчыгы белән очрашмый калмыйм, чәй яки квас эчкән саен Сербияне искә төшерәм. «ВКонтакте»дагы «Мин Сербияне яратам!» төркеменнән дә чыкмадым. Нигә чыгарга, мин, чыннан да, Сербияне яраттым бит!

PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Хәзер күпләр үз авылларының тарихы белән кызыксына. Пенза өлкәсендә зур бер татар авылы – Индерка бар. Аның да барлыкка килү тарихы бик кызыклы.

XVI гасырның икенче яртысында, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, татарлар тарихында яңа чор башлана. Картлар сөйләве буенча, безнең авыл тарихы да шушы еллардан башлана. Татарлар, Явыз Иваннан качып, шушы җирләргә килеп утыра. Тарихчы Федор Чекалин язмасы буенча, бу җирләр йомышлы татарларга 1685 елның 17 маенда бирелә. Авылыбызның бер урамын әле дә Морза очы дип йөртәләр. Индерканың иң борынгы урыны да ул.

Авылның исеменә бәйле төрле фаразлар бар. Индерка – Ендырка елгасы исеменнән, диләр. Ендырка исә ындыр сүзеннән килеп чыккан, имеш.

Безнең халык борын-борыннан игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнгән. Алар алпавытка буйсынмасалар да, шул чордагы феодаль-крепостной дәүләтнең бөтен изүен үз җилкәсендә татучылар. Бигрәк тә Петр I заманында, йомышлы татарларның барлык өстенлекләре бетерелгәч, халыкның матди хәле аеруча начарлана. Күп кенә кешеләрне кораблар төзү өчен урман эшенә билгелиләр, лашманчыларга әйләндерәләр.

Соңрак авылда «Чаткы» колхозы оеша, Бөек Ватан сугышы чорында дәүләткә ит-сөт тапшырып тора. Узган гасырның 70 нче елларында анда чәшкеләр асраучы фермалар бар иде. Авыл төзүчеләре, такта яручылары белән дә дан тотты. Халыкның күпчелеге читкә китеп эшләп йөрде, чөнки авылдагы ир-атларга эш урыннары җитми иде. Безнең авылда кирпеч сукканнары да мәгълүм. Моның өчен яр буеның балчыгы бик кулай булган. Һәр өйдә туку станогы торган, чабата үргәннәр. Һәр атнада авылда базар узган. Базар ул сату-алу урыны гына түгел, дус-ишләрнең, очрашып, сөйләшү урыны да булып саналган.

Индеркада совет заманында да халык дин тоткан. 1912 елга кадәр авылда җиде мәчет эшләгән. Совет чорында инде аларның саны бергә генә калган иде. Кабат дин иреге килеп, авылларда мәчетләр салына башлагач, Индерка халкы да авылда мәчетләр санын арттырды. 2007 елдан бирле авылда биш мәчет эшли. Самараның беренче муллалары да – Индеркадан чыккан Мельзетдиновлар нәселеннән. Бабам Мельзетдинов Мөхәммәтҗан улы Али 70-80 нче елларда авылда имам булып торды.

Хезмәт сөюче Индерка халкы, кайда гына, нинди генә эш белән шөгыльләнмәсен, һәрвакыт тырышлык үрнәге күрсәтеп яши.

Рәшидә АБДУЛЛИНА.
Пенза өлкәсе, Индерка авылы.

«Эчтем, эчәм һәм эчәчәкмен!» Әлеге сүзләрне берәр сәрхуш авызыннан ишетсәм, аптырамас та идем. Бу сүзләрне шактый танылган язучының интервьюсыннан укыдым.

Алай гына да түгел, талантлы кешеләрнең эчүе табигый, талантсызлар нигә эчә икән, дигән үзенә күрә бер аклану да бар иде әле анда. Шуннан соң, нинди кыйммәтләрне алга сөрә соң бу каләм иясе дип, әлеге язучы белән ныклабрак кызыксынып киттем. Юк, ул да татар дип җан ата! Ул да милләтнең кимчелекләрен күрсәтергә тырыша. Ул зина кылуны рухи аклаган өчен берәүне шундый итеп тәнкыйтьли, син бу мәкалә авторы белән берсүзсез килешәсең! Тик шуны гына аңлап җиткерәлмим: зина кылу белән эчкечелек – исламда икесе дә гөнаһ санала икән, ничек берсен кабул итеп, икенчесен хурлап була? Уйлый торгач, барыбыз өчен дә хас бер нәрсәгә игътибар иттем. Дини белем сайлыгыннан ич бу фикер каршылыклары.

Бу урында Җәлил хәзрәт Фазлыевның «Йөз дә бер вәгазь» китабыннан бер өзек китерәсем килә: «Бер халык җир йөзендә үзенең урынын табарга теләсә, ул гүзәл әхлаклы булырга, балаларын шул гүзәл әхлак белән тәрбияләргә тиеш. Аларда яхшылыкка – мәхәббәт, начарлыкка карата нәфрәт уянсын. Аның сәнгать әсәрләре дә шуңа хезмәт итсен. Бүген безнең халкыбыз әхлак ягыннан шулхәтле түбән төште ки, югары сәнгатьне бөтенләй аңламас дәрәҗәгә җитте».

Татар – бу җирдә мәңгегә яшәргә килгән милләт ул, дип, ялган горурлыкларны ташлап, тирә-юнебезгә күз ташласак, телен чиле-пешле генә белүче, татар әдәбияты, сәнгате белән бик аз кызыксынучы яшь буынны күрмәбезме? Менә шул җиңел җырлар, тозсыз мәзәкләр белән генә туенган яшь буынны әхлаклы итеп тәрбияләүче көч бармы соң ул? Гаилә дисәк, күбрәк дөнья көтү белән мәшгуль, эштән арып кайткач, сериаллар һәм спорт карап ял итүче ата-аналарның үрнәгеме ул? Вакытлы матбугатмы? Менә шундый шартларда иң кулае һәм иң дөресе – дини тәрбия булыр иде.

Мөхәммәд пәйгамбәр аракы турындагы аятьләр индерелгәннән соң: «Без кешеләрдә булган бозык-

лыкны бикләп куйдык», – ди. Бөтендөнья Сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, мөселманнар күпчелекне тәшкил иткән илләр эчкечелек буенча соңгы урыннарда тора. Алга киткән, кеше хокукларын беренче урынга куйган Европада эчкечелек чәчәк ата. Анда бит инде ул «кемнең нәрсәгә ышануы – аның шәхси эше»! Анда хәзер бер җенес вәкилләренең никахлары да канунлаштырылып тора, андый гаиләләрнең асрамага бала алуы да гаепләнми...

Дин белгечләре белән килешми мөмкин түгел: совет чорында, дингә зур һөҗүм ясалганнан соң, денсезләнү белән бергә телсезләнү дә башланган. Дин исән вакытта тел дә сакланып килгән, гореф-гадәтләр дә буыннан-буынга күчә барган.

Иң үтемле тәрбия барыбер дә дини тәрбиядер. Әгәр бала чакта октябрят-пионер-комсомол мәктәбен үтмичә, әбиемнең догалары тәрбиясендә булсам, мин хәзер «дер» дип утырмас идем. Бүгенге көндә минем башта төрледән-төрле тәгълиматлар кушылып-аралашып беткән, һәм алар ислам кануннарын бер икеләнүсез кабул итәргә комачаулый: әледән-әле шик туа, әледән-әле кайсы да булса кагыйдәгә каршы килеп, бәхәсләшәсе килә.

Бернинди шикләнүләрсез дин кануннары белән яшәп ятучылардан ак көнләшү белән көнләшәм мин. Әгәр дә сүзе белән гамәле туры килүчеләр булса, әлбәттә. Иң мөһиме: дини фанатизмсыз һәм яңа гасыр кешеләренең карашларына таләп бирерлек аңлатмалар аша үтеп керсен иде тормышыбызга ислам. Дөньяга мәгълүм француз океанографы Кусто исламга күчкән икән, Коръәндә язылганнарның фән белән дәлилләнүе сәбәпче булган бит моңа.

Ә каләм ияләренә, Крылов мәсәлендәгечә, төрлегә каермыйча, «атадан калган хата»бызны – таркаулыгыбызны онытып тору да ярар иде. Акыллы, үтемле чыгышлар белән дини тәрбиянең зарурлыгына төшендерергә вакыт яки, теләкләре юк икән, кирегә сукалаган антивәгазьләре белән комачауламасалар да ярар иде әлегә. Әдәбиятыбызда да төшенкелек мотивлары күбрәк булмасын иде.

Коръәндәге «Гыймран» сүрәсендә шундый юллар бар: «Сездән шундый бер өммәт булырга тиеш ки, алар һәркемне хәерле эшләргә, игелеккә өндәрләр, яманлыктан ваз кичәргә чакырырлар. Менә шундыйлар морадларына ирешкән булырлар». Күпләребез ишетеп белгән Пенза өлкәсендәге Урта Әләзән авылы мисалында дини тәрбиянең уңай йогынтысын танымый булмас, килешәсездер. Россия уртасында чәчәк атып утыручы таза тормышлы татар авылында эчкечелек һәм җинаятьчелек юк диярлек; яшьләр авылда кала, рәхәтләнеп дөнья һәм дин эшләрен бергә алып баралар. Шулай дип язуга, Такташыбызны биргән Сыркыдыйның Соркудька әйләнүе һәм анда инде бөек якташлары иҗатын ана телендә укый белүчеләрнең юк дәрәҗәсендә булуы турында әрнеп язылган мәкалә искә төште. Уйлансаң, уйланырлык нәрсәләр бар шул...

Лилия ФӘТТАХОВА.
Чаллы шәһәре.

Карабаш бистәсенең Тау Очы ягында Насыйров исемендәге урам бар.

Кем соң ул авылдашлары күңелендә якты эз калдырган Шакир Вәлиәхмәт улы Насыйров?

Ул 1899 елның 15 июнендә Әлмәт районы Тайсуган авылында мулла гаиләсендә туа. Җиде ел Уфа мәдрәсәсендә укый. Әмма илдәге вакыйгалар аның бар өметен чәлпәрәмә китерә. Алай да сәләтле егет югалып калмый, башта «Сәйяр» труппасына артист булып урнаша, аннары укытучылар әзерли торган курсларны тәмамлап, Карабаш мәктәбенә эшкә кайта. Аның гомуми эш стажы – 52 ел, шуның 40 елдан артыгын балаларга музыкаль белем бирүгә багышлый. Аның тырышлыгы белән, сугыштан соң районда иң беренче пианино да безнең мәктәптә барлыкка килде.

Искиткеч талантлы кеше иде Шакир абый. Берничә тел белә, курайда, тальянда, баянда, мандолина, скрипка, фортепианода уйный. Авылда концерт, спектакльләр оештыра. Ул татарның бик күп күренекле кешеләре, артистлар, композиторлар, җырчылар белән якыннан аралаша иде. Хәтта Тукайны да үз күзләре белән күреп белгән. Шагыйрь, мәдрәсә эшчәнлеге белән танышырга килгәч, аларда туктала. Шакир абыйга ул вакытта 11-12 яшьләр тирәсе була. Ә «Сәйяр» труппасында эшләгәндә драматург Таҗи Гыйззәт белән бер бүлмәдә яши. Танылган артистлар Хәлил Әбҗәлилов, Хөсәен Уразиков, Хәким Сәлимҗановлар белән дус булган.

Без аның җыр дәресләрен бик көтеп ала идек. Ул безгә атаклы композиторлар белән очрашулар оештыра иде. Заһид Хәбибуллинның, күңел кылларын сыкратып, скрипкада уйнавы әле дә күз алдымда тора. Әгәр дә Казанда яшәсә, Шакир абый күренекле композитор була алган булыр иде.

...Дәресләр тәмам, мәктәп тыптын. Бары тик Шакир абый бүлмәсеннән генә үзәк өзгеч скрипка моңы агыла. Шәкертләре күңеленә дә скрипка моңы булып кереп калды ул. Һәм... тагын, аның истәлеге, аның хәтере булып, йөрәкләребездә җырга-моңга мәхәббәт калды.

Шакир абыйның алты баласы да матур җырлый. Арадан берсе – татар халкының яраткан җырчысы – Бәширә Насыйрова.

Мәгариф өлкәсендәге уңышлары өчен Шакир Вәлиәхмәт улы Насыйров 1947 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Шакир абый 1970 елда вафат булды. Хәзер Карабашта аларның төп нигезе урнашкан урам аның исемен йөртә.

Флюра ИСМӘГЫЙЛЕВА.
Бөгелмә шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU

16+

КҮЗЛӘР БАРЫСЫН ДА СӨЙЛИ...

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән?
Сүзне аларга бирик.



Данил ГЫЙНИЯТОВ,
«Татарстан–Яңа гасыр» телеканалы генераль директоры урынбасары;
өйләнгән;
гаилә стажы – 22 ел;
Ике малай атасы.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Үзгәреп торадыр ул, мөгаен. Яшьрәк вакытта нәрсәләргә игътибар иткәнемне хәзер инде төгәл әйтә алмыйм. Бүген исә хатын-кызларның, иң беренче чиратта, күзләрен «күрәм». Кешенең күзеннән күп нәрсәне аңларга, укырга була. Аннан инде үз-үзен тотышына игътибар итәм. Сөйләменә! Иң соңыннан гына, мөгаен, киеменә игътибар итәмдер. Кием белән хәзер беркемне дә шаккаттырып булмый. Әмма чиста һәм пөхтә киенгән икән, кеше үзеннән-үзе ышаныч һәм хөрмәт уята.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Яраткан кешеңнең барлык җитешмәгән сыйфатларын да гафу итәргә мөмкиндер дип уйлыйм. Соңга калуын, онытып җибәрүен, телефоннан күп сөйләшүен, интернетта, социаль челтәрләрдә озак утыруын...

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хыянәтнедер... Юк, төгәл генә әйтә алмыйм. Беренчедән, шөкер, гаиләмдә андый хәл белән очрашканым юк. Икенчедән, тәүбә-тәүбә, хәтта мондый хәл булса да, өздереп кенә җавап бирә алмас идем. Чөнки һәрбер очракның үз сәбәбе булырга мөмкин. Шуларны белмичә, ниндидер нәтиҗә чыгару дөрес булмас иде. Әйе, күп вакыт ирләр хыянәтне гафу итми. Алар тормышта, табигатьтә доминант рольдә бит – бу, бәлки, шуның белән дә бәйледер. Мин – гаилә башлыгы, лидер, минем рөхсәтемнән, хәер-фатихамнан башка гаиләдә бернәрсә дә эшләнергә тиеш түгел дип саный ул. Гәрчә хәзер ир-атларның да төрлесе бар.

4 Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

– Була ала! Мәхәббәттән нәфрәткә – бер генә адым, диләр. Димәк, ир белән хатын бер-берсенә гашыйк җаннар гына түгел, дуслар да булсалар, бу аларның аралары тагын да якынрак дигән сүз. Дустыңнан инде эч серләреңнең берсен дә яшермисең, ике арадагы барлык пәрдәләр ачыла. Дус кешегә ышаныч тагын да зуррак, тагын да күбрәк.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Казан дәүләт университетының татар теле факультетында без Гөлназ белән бер чорда укыдык. Беренче тапкыр кайда күрдем икән аны, хәтерләмим... Университетның Гвардия урамында урнашкан 5 нче тулай торагында студентлар советы рәисе идем. Бер группадаш егет: «Минзәләдән ике кыз бар, аларның 3 нче тулай торактан бик тә безгә күчәселәре килә, әйдә, урнаштырыйк әле», – диде. Мөгаен, беренче очрашу шунда булгандыр. Кап-кара чәчле иде Гөлназ. Элек чәчләре бик озын булган: толымнарын, бөтен кызлар кебек, Казанга килгәч, кистергән. Әмма кискәннән соң да матур иде.

...Тулай торакта Яңа ел каршыларга йөрибез. Егетләрнең барысының да кызы бар. Минем генә беркемем дә юк... Шул вакыт Гөлназны күрдем дә: «Әйдә, Яңа елны бергә каршылыйбыз», – дидем. Ул ризалашты! Минзәлә ерак – бәйрәмгә барыбер авылга кайтмый икән. Безнең бергә Яңа ел каршылау стажы шуңа күрә дә очраша башлау, өйләнешү стажыннан зуррак. Минзәләдә итле бәлеш пешерәләр икән – кызлар бәлеш салды. Гөлназның бик вак итеп суган тураганы истә калган.

Шуннан йөреп киттек... Үзенә әйтмәсәм дә, «мөгаен, шушы кызга өйләнермен», дигән уйны башта ук күңелгә салып куйган идем. Ә аннары бергә буласыбыз инде сүзсез дә аңлашылды. «Миңа кияүгә чыгарга ризамы?» – дигән сораулар бирмичә дә.

Минзәләгә кыз сорарга кайту – үзе бер тарих. Башта Чаллыга кайттым. Анда бергә укыган дус егетләр Илшат Әюпов белән Нияз Вафин эшли. Гөлназның бертуган абыйсы Айрат машинасына утырып, дүртәү юлга кузгалдык. Башта Сарманга әле. Ниязларда бер кич кунып, кунак булып чыктык. Икенче көнне Мөслимгә – Илшатларга киттек. Аның туган авылы Мөтрәй район үзәгенә

терәлеп үк тора. Кич клубка чыктык. Мөслим егетләре дә килгән иде, алар нигәдер безне ошатмадылар – чәкәләшеп киттек. Минем борынга каты гына эләкте... Шул шешкән борын белән кайтып кердем инде мин Татар Мөшегесенә кыз сорарга. Ул елны абыйсы Айрат та өйләнергә йөри иде, җәй башында аларның туе булды, аннары гына безнеке. Яшьләр туе, өлкәннәрнеке, килен токмачы... Әти-әниләр бу кадәр табынны ничекләр үткәреп бетерделәр икән, бүген шуңа шаккатам.

Ул заманда күпләр тормышны тулай торактан башлады. Безнең дә олы улыбыз Айзат шунда туды.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр.

– Юк, алай дип әйтә алмыйм. Беркем дә «әнигә охшасын» дип эзләмидер. Әмма... Гөлназга карап: «Әнидә дә шундый сыйфатлар бар бит!» – дип уйлап куйган чаклар була! Мин өлкән бала булсам да, Гөлназ әнинең беренче килене түгел – энекәш алданрак өйләнде.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Мин үземне бик әйбәт тотар идем. Моның ни начарлыгы бар инде?! Иң мөһиме – аңлашып яшәү. Анысы һәркемнең үзеннән тора. Акыллы хатын булса: «Мин синнән күбрәк табам», – дип, тавыш чыгармый, әлбәттә. Әмма ир ниндидер тәртипсез тормыш алып бара икән, хатыны: «Мин көн-төн чабам, мал табам, ә син таратып ятасың», – диячәк. Һәм хаклы булачак.

Без үзебез акчага табынып яшәүчеләр түгел. Икебез дә гел бюджет өлкәсендә эшләдек – монда зур акчалар юк. Хәер, бизнес безнең өчен түгел дә... Күп тә бетә, аз да җитә, ди өлкәннәр. Дөрес әйтәләр. Бәрәкәте булмаса, күп акча да җитми.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Хәзер эшләр шуңа бара бугай инде. Һәрхәлдә, бүген хатын-кызлар бу мәсьәләдә күпкә активрак. Кайчак урамда яшүсмер кызларга карагач, ирексездән шулай уйлыйсың. Егетләр өчен сугышырга да күп сорамыйлар лабаса.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә?

– Безнең вакытта кызларны егетләрнең физик көче җәлеп иткәндер. Әйе, элек шулай иде. Заман үзгәргәч, хәзер башка кыйммәтләр өскә чыккандыр. Хатын-кызлар ир-атның җәмгыятьтә тоткан урынына, статусына карыйдыр, байлыгына, нинди гаиләдән чыгуына (хәер, анысы элек тә булган: нәсел-нәсәбен белмичә, татарда кызны да кияүгә бирмәгәннәр, малайны да өйләндермәгәннәр)...

10 Хатын-кызлардан үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Бәлки моны алдан әйтмәскәдер? Болай кызыграк та – минем башкаларга охшамаган нинди дә булса өстенлегемне үзләре күрә алырлармы, юкмы?

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да.

– Гөлназда нигәдер урында ориентлашу бөтенләй юк диярлек. Әйтик, Казан буйлап барабыз, мин – рульдә. Бертуктамый: «Бу кайсы урам әле?», «Син кая борылдың?» – дип, сорау арты сорау яудыра ул. Очып йөргән кебек тоела миңа Гөлназ. Әллә ничә тапкыр үткән юлны ничек истә калдырмаска була икән? Үзен рульгә утыртып чыгарып җибәрсәң, адаша инде ул. Торган җиребез эшкә якын булгач, балалар янәшәдә генә укыгач, Гөлназга машина йөртергә кирәкмәде шул – мохтаҗлык булмады.

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Үземнең хаклы икәнемне расларга тырышып караулар булды... Ләкин хатын-кыз бик сирәк очракта гына үз фикерен үзгәртә – аның психологиясе шундый. Факт күзгә күренеп, «кычкырып» торганда гына үз сүзеннән кире кайтырга мөмкин ул. Шуңа күрә хәзер бәхәсләшеп тормыйм. Әйткәнемчә, мәгънәсе юк. Кычкырышуга китүе дә бар.

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: Сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Тотам да үзем пешерәм! Суыткычта барыбер нидер була инде ул. Йомырка тәбәсе булса да кыздырып ашый алмаган ир-ат юктыр. Без бит тулай торакта яшәдек – аз-маз булса да тәҗрибә бар. Элегрәк өйдәгеләрне «мясо по-французски» пешереп сыйлый идем. Гөлназ: «Син кыздырган бәрәңге тәмлерәк була», – ди. Сере – гади! Табага да ябышмасын, тәмле булып кызсын да дисәң, табага салганда ук тоз сибәргә ярамый аңа.

Ир-ат кына булган гаиләдә хатын-кызга авыррак, әлбәттә. Без үзебез дә гаиләдә биш малай үстек. Әти белән алтау... Идән дә юдык, кер дә үтүкләдек, табын да җыйдык... Шуңа күрә эшне бүлгән юк. Гөлназ белән өйгә бергә кайтып керсәк, ашарга икәү әзерлибез. Малайлар да булыша. Кечкенәсе бу арада, хирысланып, йомырка тәбәсе пешерә әле. Нинди тәмләткеч бар – һәммәсен сала. «Тәмле булган, улым!» – дип ашыйсың инде аннары...

14 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Моның белән көрәшү шулай ук мәгънәсез эш. Баштарак канәгатьсезлек белдереп караган идем – нәтиҗәсе булмады. Бу аларның геннарына салынган бугай. Ире әйткән вакытка җыенып чыккан хатын-кызны мин белмим дә.

15 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша...

– Бер-беребезгә бүләк еш бирешмибез. Алай гадәтләнмәгән. Гөлназ миңа гел парфюм ала. «Бетмиме әле?» – дип аны карап кына тора. Мин исә чәчәкләр алам. Аның иң яраткан бүләге – чәчәкләр: көн саен алып кайтсам да, сүз әйтмәс иде, мөгаен. Кайчакта үзе әйтеп исемә төшерә әле: «Елга бер булса да, чәчәк аласыңмы, юкмы?» – ди.

ЯШӘҮ

PRESSA.RU

АЙ-КОЯШ ЙӨЗЛӘРЕҢ...



Елның һәр фасылы үзенчәлекле. Безнең организм да, урамда нинди фасыл булуына карап, аңа үзенчә җайлаша. Бит тиресе аеруча да нәзберек: үзенә һәрвакыт аерым игътибар таләп итә.
Февраль-март айларында бит тиресен карау тәртибе үзгәрә. Бу айларда, беренчедән, һавада дым аз була, икенчедән, кояш нурлары тәэсире көчәя. Нәтиҗәдә, бит тиресе корый, кытыршылана, пигментлы таплар барлыкка килә. Аларны булдырмас өчен, бит тиресен дөрес итеп тәрбияләргә Республика клиник тире-венерология диспансеры дерматовенерологы, косметолог Гөлназ ФӘТХЕТДИНОВА өйрәтә.

15-20 яшь

Яшүсмер һәм җитлегү чорында коры бит ияләре сирәк очрый. 15-20 яшьтә тиренең регенерация (организмдагы тукымаларның табигый рәвештә яңаруы) функциясе яхшы эшли, шуңа күрә бу яшьтә, гадәттә, бит тиресе майлы, еш кына бетчәле дә була. Кызганыч ки, күп кенә кызлар, бит тиресен дөрес итеп тәрбиялисе урында, бетчәләрдән, битнең чамадан тыш ялтырап торуыннан оялып, катлам-катлам тональ крем, кершән, төрле лосьоннар һәм башка косметика сөртә. Шул рәвешле, битләрендәге җитешсезлекне яшерәләр янәсе. Ә чынлыкта, проблемаларын арттыра, яшь һәм йомшак бит тиресен бактерия оясына әйләндерә.

Тирене дөрес итеп карау җайлы гына югыйсә: май бизләре эшчәнлеген киметү өчен – ретинол кремнар, бактерияләргә каршы көрәшү өчен составында антибиотик булган кремнар һәм юыну чаралары кулланырга кирәк. Гигиена таләпләрен дә үтәү зарур: иртә-кич битне махсус гельләр һәм тониклар ярдәмендә чистартырга, макияжны юып төшермәгән килеш йокларга ятмаска кирәк.

25-30 яшь

25 яшьләрдән бит тиресенең регенерация эшчәнлеге кими. Шуңа күрә бу яшьтә биткә саклый һәм дымландыра торган кремнар тидерергә киңәш ителә. Бит тиресе коры һәм сизгер булса, аның тире барьеры бозылган булуы ихтимал. Бу очракта тиренең өске катламын тергезә торган кремнар кулланырга кирәк, аларның составында майлы кислоталар, холестерол, церамид, глицерол булырга тиеш.

Составында глицерин, сорбитол, натрий гиалуронаты, сидекчә (мочевина), пропиленгликоль булган кайбер җиңел кремнар (аларны икенче төрле «гумектантлар» дип атыйлар), атмосферада дымлылык 80 процентган ким булса, тиредәге дымлылыкны үзләренә алалар. Шуңа күрә, өйдә һава коры булмасын өчен, дымландыра торган җайланмалар куярга кирәк.

30 яшьтә тире үзе коллагеннар һәм гиалурон кислотасы бүлеп чыгара әле, шуңа күрә тирене картаюдан саклый торган кремнар һәм процедуралар белән мавыкмагыз.

Биткә боз шакмаклары ярдәмендә массаж ясау да бик файдалы. Бу ысул кан-лифма йөрешен тизләтә, бит тиресен, аның төсен яхшырта. Боз шакмакларын минераль судан ясарга мөмкин. Ә тире майлы булса, яшел чәй, имән кайрысы яки пәйгамбәр тырнагы гөле төнәтмәсеннән ясагыз. Бозны чамасын белеп кенә кулланырга кирәк: еш кулланганда бит тиресе кипшерә, өстәвенә, боз кисәкләре битне җәрәхәтләргә дә мөмкин.

30-40 яшь

«Бальзак ханымнары» яшендә картлык билгеләре – җыерчыклар күренә башлый. Шуңа бәйле рәвештә тирене тәрбияләү процедуралары исемлеге дә арта.

Шәхси гигиена, саклау һәм дымландыру процедураларына тирене тукландыру һәм тонуска кертү чаралары да өстәлә, чөнки бу яшьтә бит тиресендә иң мөһим компонентлар – коллаген, эластин, гиалурон кислотасы кими.

Кызганыч ки, составында коллаген, эластин, гиалурон кислотасы булган кремнар куллану гына тиешле нәтиҗәне бирми, чөнки бу матдәләр тиренең тышкы катламы (эпидермис) аша үтеп керә алмый. Бит тиресен әлеге компонентлар белән тулыландыру өчен косметологик процедуралар – биоревитализация, биорепарация, контур пластикасы ярдәмгә килә. Ә кремнар составында антиоксидантлар булырга тиеш, болар – C һәм E витаминнары, ферулий кислотасы, коэнзим Q_{10}, яшел чәй.

45-50 яшь

Яшь чактан ук бит тиресен дөрес итеп тәрбияләсәң – даими рәвештә чистартып һәм дымландырып торсаң, 45-50 яшьтә дә бик күркәм була аласың. Игътибар иткәнегез бардыр: 50 яшьлек кайбер ханымнарның йөзенә карасаң, һич кенә дә үз яшьләрен биреп булмый, битләре алсуланып тора, бит тиресе салынып төшмәгән, җыерчыклары да буразна булып сузылмаган, ирен һәм күз читләрендә мөлаем гына булып беленер-беленмәс кенә сызылганнар. Әлеге ханымнар пластик опера-

ция ясаткан дигән сүз түгел әле бу. Димәк, алар беренче өч баскычта үтәргә кирәкле чараларны үтәгән, бит тиресен яшьтән үк дөрес итеп тәрбияләгән.

Әгәр инде ул өч баскычны ычкындыргансыз икән, өй шартларында маска ясап кына бит тиресен яшәртеп булмый. Мондый очракта бит тиресен косметологлар кулына тапшырырга киңәш ителә. Тирән пилинг, контур пластикасы, интенсив тукландыру чаралары булышачак: тирене тарттырып, кан әйләнешен яхшыртып җибәрәчәк, җыерчыкларны чагыштырмача «тигезләячәк».

Бу яшьтә тиренең үзлегеннән гиалурон кислотасы бүлеп чыгаруы бөтенләй диярлек кими, шуңа күрә, белгеч белән киңәшеп, капсулалы гиалурон кислотасы эчәргә мөмкин.

Бит тиресен кремнар, маскалар ярдәмендә генә дымландырып, тукландырып булмый, үзегезнең ничек туклануга да игътибар итәргә кирәк. Менюга ит-балык, ярмалар, яшелчәләр кертегез. Сәламәт яшәү рәвеше алып барыгыз.

Саф һавада булу, көч җиткән кадәр физик эш башкару бит тиресен алсуландыра.

Әгәр безнең киңәшләрне тотсагыз, тирегез сезгә рәхмәт кенә әйтер.

Фәнзилә МОСТАФИНА әзерләде.



15-20 яшь

ЯРЫЙ

Майлы бит тиресе өчен яшел чәй, имән кайрысы, ромашка төнәтмәләре файдалы. Аларны өй шартларында да ясарга мөмкин. Моның өчен үзегез сайлаган үләнгә кайнап кына чыккан су салып, 20-25 минут төнәтергә, суына төшкәч, шуны биткә сөртергә кирәк. Бу процедураны иртә-кич кабатлыйсы. Бетчәдән калган эзләрне бетерәсегез килсә, төнәтмәгә берничә тамчы лимон суты да кушыгыз.

ЯРАМЫЙ

Бит тиресе майлы булганда спиртлы тониклар, скраблар кулланырга, сабын белән юынырга ярамый. Алар тирене ялкынсындыралар. Составында вазелин, минераль майлар булган кремнарны да читләтеп үтәргә кирәк – андый кремнар бетчәләрне азындырырга мөмкин.



25-30 яшь

Өй шартларында ясалган иң файдалы маскаларның берсе – ул каймактан ясалганы. Каймакны кибеттән сатып алырга да була, өйдә үзегез әзерләгәне дә ярый – иң мөһиме: сыйфатлы булсын (кибеттән алганда игътибар итегез: порошоктан гына ясалмаганмы). Каймакка солы ләвәче ярмасы, бал яки җиләк-җимеш тә өстәргә мөмкин. Каймаклы маска биттә 10-15 минут торганнан соң, аны җылымса су белән юып төшерегез. Нәтиҗәле булсын өчен, әлеге масканы атнага 2-3 тапкыр ясарга (тулы курс – 10 тапкыр) кирәк. Мондый маска бит тиресен тукландыра, сафландыра, пигментлы таплардан арындыра.

Составында парафин, свален, диметикон, солы мае, виноград төше мае, ланолин, балавыз булган кремнарны еш кулланырга тырышмагыз. Алар тире өстендә пленка булдырып, дымлылыкны гына саклыйлар, тирегә «суларга» ирек бирмиләр, бактерияләргә үрчү өчен уңайлы мохит тудыралар. Бит тиресе коры булса, озак итеп хлорлы бассейнда йөзүдән тыелыгыз.



30-40 яшь

Биткә сөртү өчен каһвәдән скраб ясарга мөмкин. Ул кан әйләнешен җайга салырга ярдәм итә, битнең тонусын яхшырта. Тик купероз булганда мондый скрабны кулланырга ярамый. Шулай ук биткә массаж ясарга була. Кемдер, интернеттан карап яки махсус курсларга йөреп, аны үзе ясарга өйрәнә, кемдер массаж эшләтү өчен матурлык салонына баруны хуп күрә. Дөрес һәм даими рәвештә ясалган массаж пластик хирургия эшлисе эшне башкара.

Бит тиресе картаюда 80 процентка кояш нурлары «гаепле». Шуңа күрә кояшка рәхәтләнеп битне куеп утырырга ярамый. Кояш нурларыннан саклый торган крем тидермичә, урамга чыкмаска тырышыгыз.



45-50 яшь

Өй шартларында да билгеле бер төрдәге маскалар ясарга була, әлбәттә. Тирене яшәртеп җибәрәсегез килсә, составына антиоксидантлар һәм микроэлементлар кергән маскалар ясагыз. Алар һәрберебезнең кул астында бар: томат, грейпфрут, виноград, зәйтүн мае, яшел чәй, бал, каймак.

Февраль-март айларында агрессив процедураларны бик саклык белән генә эшләргә кирәк, чөнки кояш нурлары көчәю сәбәпле, пигментлы таплар барлыкка килү ихтималы зур. Шуңа күрә кояш нурларыннан саклый торган кремнар тидерергә онытмагыз.

PRESSA.RU

ӘТИ-ӘНИЛӘР ӨЧЕН БИШ КАГЫЙДӘ



Балалар сәламәтлегенә багышланган махсус сәхифәбез хәзер ай саен чыгып барачак. Аны Республика балалар клиник хастаханәсенең баш табибы Рафаэль ШӘВӘЛИЕВ алып бара. Кызыксындырган сорауларыгыз булса, рәхим итегез! Аларны баш табибка җиткереп, җавапларны журналда, сайтыбызда урнаштырып барачакбыз. Йөрәк парәләребез сау-сәламәт булсын!

Салкын тию, грипп, ОРЗ, ОРВИ... Болары әле халык телендә йөргәннәре генә, табиблар телендә тагын да күбрәк алар. Үзең авырсаң, бер хәл әле, менә балаң авырый башласа, бик яман...

Иң яхшы дәва ул – профилактика. Профилактиканың гади генә биш баскычын истә тотсак, балабызның организмы да какшамый, үзебезгә дә җиңелрәк була.

БЕРЕНЧЕ БАСКЫЧ Иммунитетны ныгытабыз.

Күкрәк баласына ана сөте белән бергә организмны саклаучы антитәнчекләр дә керә. Шулар иммунитетны барлыкка китерә дә инде. Шуңа күрә аналарга күкрәк баласын имидән иртә аермаска киңәш ителә.

Мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларның тукллануына зур игътибар күрсәтегез. Аларга җиләк-җимеш һәм яшелчәләр (аеруча суган, сарымсак, шалкан, кабак) бирегез, натураль соклар ясап эчертегез. Йокларга ятканда җылы сөткә бал болгатып эчертергә мөмкин. Бал иммунитетны ныгыта. Тик анда көчле аллергеннар барлыгын да онытмагыз.

ИКЕНЧЕ БАСКЫЧ Дөрес итеп киенәбез.

Кечкенә баланы белеп киендерергә кирәк. Ул туңмасын да, тирләмәсен дә. Бүлмәдә дә мунча ясамагыз – уртача гына җылылык көйләп куегыз.

Тәпи йөри башлагач, баланың аягы туңмасын һәм юешләнмәсен. Урамда салкынча булганда муенына шарф урарга онытмагыз.

ӨЧЕНЧЕ БАСКЫЧ Инфекциялардән сакланабыз.

Бүлмәне даими рәвештә җилләтеп торыгыз. Грипп вирусы ябык, җилләтелми торган бүлмәдә, коры һавада, эсседә активлаша. Шуңа күрә бүлмәдәге һава артык коры булса, аны дымландырырга кирәк.

Грипп һәм ОРВИ эпидемияләре вакытында күп кеше җыела торган урыннарга чыкмаска тырышыгыз. Ә саф һавада йөрергә була. Салкынча һавада вирус үлә.

Урамнан кергәч, бала кулын сабын белән яхшылап юсын, борын эчен юдыруны да гадәткә кертергә кирәк.

Чыныктыру да мөһим. Төнгә баланың аякларын бүлмә температурасындагы су белән юарга, тәнен юеш сөлге белән сөртергә яисә душта коендырырга киңәш ителә. Зуррак балаларга, педиатр белән киңәшеп, контраст душ тәкъдим итәргә мөмкин.

Чамасын белеп кенә кояшта йөрү дә файдалы. Ә кечкенә балаларга – һава ваннасы. Баланы бүлмәдә берничә минут ялангач яткырып торыгыз. Бу вакытта бүлмәдә җил уйнап торырга тиеш түгел, билгеле.

ДҮРТЕНЧЕ БАСКЫЧ Файдалы матдәләр.

Балаларга, иммунитетны ныгыту максатында, һәр көнне 30 мг аскорбин кислотасы бирергә, борынга көнгә ике тапкыр вируска каршы махсус тамчылар тамызырга киңәш ителә. Витаминнары булган җиләк-җимешләр турында да онытмагыз.

Балага җиләк-җимеш һәм яшелчә боткаларын вакытында ашата башларга кирәк.

БИШЕНЧЕ БАСКЫЧ Прививка.

Вакцина ясаткан балаларның вируска каршы торучанлыгы арту белгечләр тарафыннан дәлилләнде инде. Прививка ясаткач, саклык чараларын күрегез.

ИСТӘ ТОТЫГЫЗ: грипп яки ОРВИ булганда, үз белдегең белән дәваланырга ЯРАМЫЙ!

Әгәр бала авырып киткән икән, берничә киңәшне истән чыгармагыз:

- бала авыруны аягөсте кичермәсен, күбрәк ятып торсын. Хәтта температурасы төшсә дә, аны тизрәк бакчага яки мәктәпкә җибәрергә ашыкмагыз. Берничә көн өйдә калып, дәваланып бетү киңәш ителә;
- баланың температурасы 38 градустан түбән булса, аны дарулар ярдәмендә төшерергә кирәкми. Бу организмның чир белән көрәшүен аңлата. Ә температура 38 градустан артса, участок педиатрын чакыртыгыз;
- кайбер әниләр авыруның беренче көнендә үк балага антибиотик бирә башлый. Болай эшләргә ярамый! Антибиотикны табиб кына билгели;
- балага күбрәк сыеклык эчерегез: җылы чәй, морс, компот, үлән яки гөлҗимеш чәе;
- баланың гигиена кагыйдәләрен үтәвен контрольдә тотыгыз. Кулларын ешрак юсын, йөткергәндә һәм төчкергәндә авыз-борынын капласын. Авыруга аерым савыт-саба тотыгыз;

СӘЛАМӘТЛЕК САТЫП АЛЫНМЫЙ

Редакциябезгә хат килде. Укучыбыз киңәш сорап мөрәҗәгать иткән. Аның соравына Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе Казан территориаль органының үсеш һәм эчке базарны координацияләү бүлеге җитәкчесе Марсель ШАҺИДУЛЛИН җавап бирә.



«Улымның аягы авырта башлады. Ортопедка мөрәҗәгать иттек. Ул оча сөяген һәм тез буыннарын да кертеп, туры проекциядә рентгенография ясатырга кушты. Шәхси клиникага язылдык. Рентгенография ясадылар, әмма тез буыннарын һәм бот сөяген аерым-аерым төшергәннәр. Сәбәбен сорагач, бу яшьтә мондый процедураны эшләп булмый, дип җавап бирделәр. Кабат ортопедка киттек. Ул исә: «Бу рентгенография бернинди мәгълүмат та бирми: миңа оча сөяген һәм тезләрне бергә күрергә кирәк иде», – дип, безне кире борды. Шәхси клиника төшергән рентгенография ярамады булып чыкты бит инде – моның өчен түләгән акчаны алар безгә кире кайтарырлармы?»

– Сәламәтлекне саклауның дөньяда берничә моделе бар: болар башлыча – дәүләт-бюджет оешмалары, шәхси клиникалар һәм катнаш вариантлар.

Медицина оешмалары арасында көндәшлек көннән-көн үсә, бигрәк тә бу хәл хосусый клиникалар арасында күзәтелә. Телевизор экраннарыннан, газета битләреннән, йорт диварларына эленгән зур-зур реклама язуларыннан, игъланнардан алар безне үзләренә чакыра. Әмма үзеңнең сәламәтлегеңне аларның теләсә кайсына тапшырырга ярыймы икән? Медицина клиникалары хәзер, әйткәнемчә, адым саен – әмма үз өстенә алган бурычларны аларның барысы да үтәми шул.

РФ «Кулланучылар хокукларын яклау турында»гы законның 4 нче маддәсе буенча, башкаручы үз өстенә алган эшне (яки хезмәтне) шушы эшкә куелган таләпләр нигезендә башкарырга тиеш.

Шул ук законның 10 нчы маддәсе буенча, кулланучы үзенә туры килгәнен дөрес итеп сайлап ала алсын өчен, тәкъдим ителә торган барлык эш (хезмәт) турында дөрес мәгълүматны башкаручы аңа вакытында бирергә бурычлы.

Тиешенчә күрсәтелмәгән хезмәт – закон буенча каралган таләпләргә яки килешүдә күрсәтелгән шартларга, хезмәтнең мондый төренә куелган яки килешү төзү вакытында кулланучыга әйтелгән максатларга ирешмичә күрсәтелгән хезмәт.

Үзе тәкъдим иткән эш (хезмәт) турында тулы һәм дөрес мәгълүмат бирмәгән башкаручы, шул сәбәпле кулланучыга тиешле хезмәтләр күрсәтелмәгән өчен, «Кулланучылар хокукларын яклау турында»гы законның 29 нчы маддәсенең 1 нче пункты нигезендә җаваплы санала.

Медицина хезмәте сыйфатсыз күрсәтелгән очракта нишләргә?

Күрсәтелгән хезмәт тиешенчә башкарылмаган яки кимчелекләре бар дип табасыз икән, шунда ук бу хакта клиникага хәбәр итәргә кирәк. Дәгъвагызны ике нөсхәдә язмача да алып барыгыз. Әлеге шикаятьтә килеп туган хәлне төзәтү өчен, законда каралган таләпләрнең берсе күрсәтелергә тиеш. Сез алардан, түбәндә тәкъдим ителгәннәрнең берсен сайлап:

- эшләнгән эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) кимчелекләрен бушлай төзәтүне;
- эшләнгән эш (күрсәтелгән хезмәт) өчен түләү хакын киметүне;
- шундый ук материалдан, шундый ук сыйфатлы икенче әйберне бушка эшләү яки эшне кабат башкаруны;
- эшләнгән эшнең (күрсәтелгән хезмәт) кимчелекләрен төзәтү өчен тотылган чыгымнарны кире кайтаруны таләп итә аласыз.

БЕРНИЧӘ КИҢӘШ

- Түләүле клиника сайлаганда танышларыгыз киңәшенә колак салыгыз – «чыбыксыз телефон» күбрәк ярдәм итәргә мөмкин. Ачыклагыз: анда исемнәре билгеле белгечләр эшлиме – бу клиниканың дәрәҗәсе турында сөйли.
- Клиника хезмәткәрләре үзләренә мөрәҗәгать иткән кешеләрне ничек каршы ала – боларына да игътибар итегез. Медицина оешмасын, чират юк, дип кенә сайлау дөрес түгел.
- Кайбер клиникалар, пациентлардан күбрәк акча саву өчен, өстәмә тикшерүләр билгелиләр. Шуңа күрә теге яки бу процедураның ни өчен кирәк икәнен табибтан сорарга тартынмагыз.
- Медицина хезмәте күрсәтү – нәкъ менә ХЕЗМӘТ күрсәтү ул: сезнең белән килешү төзү, акча түләгәнгә кулыгызга документ бирү клиника өчен мәҗбүри. Килешүдә, клиника сезгә тәкъдим иткән хезмәт эчендә нинди гарантияләр каралганлыгы, сезгә нинди куркыныч янавы – барысы да күрсәтелергә тиеш.
- Лицензиясе булмаган клиниканың халыкка хезмәт күрсәтергә хокукы юк. Гадәттә, бу документлар белән мәгълүматлар язылган стендта танышып була. Хезмәткәрләрнең лицензия номерын яшерүләре, клиникада да, сайтта да бу хакта бер мәгълүмат та булмау сезне шикләндерергә тиеш.

PRESSA.RU

Театр сөючеләрне Ләйсән ФӘЙЗУЛЛИНА белән таныштырып торуның кирәге юктыр, мөгаен. Әйе, әйе, нәкъ шул үзе – Камал театры артисты. Әйе, әйе «Миркәй белән Айсылу»да (Н. Исәнбәт) – Айсылу, «Кыю кызлар»да (Т. Гыйззәт) Миләүшәне уйнаган Ләйсән. Аның хакында «Сөембикә» журналыннан да укыган булгансыздыр әле. «Алтын куллы кызыбыз ул безнең», – диләр театрда Ләйсән турында. Ул чиккән чыбылдыклар, ул бәйләгән кардиган-свитерлар – Камал сәхнәсендә куелган спектакльләр бизәге. Киләчәктә остаханәбезгә чакыртып, берәр кул эшенә өйрәтүен дә сорарбыз әле аннан, ә бүгенгә без үзебез Ләйсәннең кунагы – бәйрәмдә егетләребезне сыйларга шулкадәр тәмле салат әзерләп күрсәтмәкче ул. Рестораннарда бирелә торган бу ризыкны өйдә дә әзерләргә мөмкин. Ризыкның тәме аның нинди савытта бирелүенә дә бәйле бит ул. Матур, затлы савыт-саба табынга бәйрәм төсе кертә, күңелне күтәрә. Бүгенге мастер-классыбызда кулланылган тәлинкә-чүлмәкләр Казандагы «Савиново» сәүдә үзәгенең өченче катында урнашкан «Божья коровка» кибетеннән алынган (реклама хокукында). Польшаның Болеславец осталары кулдан ясаган керамик савыт-сабалар бөтен дөньяга билгеле. Алар матур гына түгел, сыйфатлы һәм чыдам булулары белән дә аерылып тора. Ялгыш бәреп алсаң да, ватылыр дип куркасы юк. Бу тәлинкәләр хәтта пычак эзеннән дә курыкмый.



РИБАЙ – РЕСТОРАН СЫЕ



Кирәк:

- 300-400 г сум ит;
- 2-3 тотам руккола үләне;
- 3-4 помидор; (сусылын, йомшагын сайлагыз);
- 1 баш кызыл суган;
- 4-5 аш кашыгы соя соусы;
- 3-4 аш кашыгы үсемлек мае;
- бер чеметем борыч;
- 50 г пармезан сыры (башка төрле каты сыр да ярый);
- бәлзәмле серкә (бальзамический уксус);

Рибай йомшак булсын дисәгез, яшь тана ите кулланыгыз. Итне суыткычтан алдан ук алып куеп, бүлмә температурасында тотарга кирәк.



Эш барышы:

■ Иң мөһиме: итне дөрес кисәкләргә бүлү. Аны, җепселләрен аркылы итеп, 2,5 см калынлыгында һәм уч төбе зурлыгындагы өлешләргә кисәбез. Иттә сеңерләр, яргагы калмасын.

■ Итне киң тәлинкәгә салып, өстеннән соя соусы, үсемлек мае агызабыз. Бер чеметем кара борыч сибәргә була. Тоз салмыйбыз. Маринад итне каплар-капламас булсын. Шул рәвешчә 4-5 сәгать торсын ул.

■ Гриль табаны кыздырып (ул булмаса, гадәти таба да ярый), ит кисәкләрен кыздырып алабыз. Табага май салырга кирәкми. Тагын бер мөһим кагыйдә: итне салыр алдыннан, табаны яхшы ук кыздырырга кирәк, итнең сүле агарлык булмасын. 1 минут көчле утта кыздыргач, утны киметәбез. Ике ягын да бишәр минут чамасы кыздырабыз. Ит йомшак булырга тиеш. Әгәр дә ит үзе катырак булса, 10 минутка кайнар мичкә тыгасы.

■ Әзер итне алдан ук җылытылган тәлинкәгә (без кулланган калын тәлинкәләр җылыны яхшы тотулары белән дә әйбәт) алып куеп торабыз. Фольгага төреп куярга да мөмкин. Аннары аны бер илле (бер бармак) калынлыгында озынчага теләбез.

■ Зур тәлинкә төбенә юылган руккола үләнен түшибез. Аның өстенә ит телемнәрен салабыз. Ит өстенә помидор телемнәре тезелә, бик юка итеп туралган суган боҗралары салына. Яшелчәләр өстенә уылган сыр сибелә.

■ Салат соус белән тагын да тәмлерәк булачак. Аны әзерләү өчен бәлзәмле серкәне төбе калын кәстрүлгә салып, куера башлаганчы кайнатабыз.

■ Әзер соусны чәй кашыгы белән салат өстенә матур итеп агызабыз. Соус савытына салып, ризык янына гына бирергә дә мөмкин.

■ Салаты җылы килеш табынга чыгарыла. Ашларыгыз тәмле булсын!



Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU


Фото: Газинур Хафизов

Урамда әле февраль булып, җирдә калын кар ятса да, сизәсезме: һавада яз исе. Аны без түгел, бүлмә гөлләре дә тоя. Әнә, тәрәзә төбендәге яраннар яшь тармаклар чыгарып, яңа тормышка җан өрергә тырышып утыра. Хәзер аларның игътибарга иң мохтаҗ чаклары.

АЛ ЯРАН, КЫЗЫЛ ЯРАН...

Элегрәк яраннарны кышын идән астына яки салкынча караңгы урынга куялар иде. Суны да бик сирәк кенә сибеп, гөлләрне шулай ял иттерәләр иде. Безнең әбиләр үсемлекләр дөньясын каян шулай яхшы белгәннәрдер – яраннар чынлап та ялга мохтаҗ. Кыш көне аларга җылылык ун градустан артмаган караңгы һәм коры урын кирәк.

Кыш азагында яраннарны җылы, якты урынга чыгаралар. Тамыры тере булса, ул бик тиз яшәреп китә. Көздән гөл куагын кыскартып кисмәгән булсагыз, хәзер беренче эш итеп шуны башкарырга кирәк.

Күпләрнең хатасы – гөлне артык кыска калдырырга җәллиләр. Гөл төбеннән ике бөре өскә менеп (элеккеге яфрак урыннары шул бөре инде), карт сабакларны һич кызганмый кисәбез. Кисеп алган сабакларны кабат тамырландырырга була. Әгәр дә яран бик озын булып сузылып үссә, озын тармакны берничә өлешкә бүләләр. Өске очын өзеп алырга кирәк. Һәр өлештә 2-3 кенә яфрак калырга тиеш. Чөнки яфраклар тармакның үсәргә дигән көчен ала.

Күп очракта өзеп алган тармакларны тамырландыру өчен сулы стаканга утырталар. Тармакның агачланган каты өлеше тамыр җибәрер анысы, тик уртадан киселгән сусыл өлешләре тамырланганчы ук чери. Шуңа күрә аларны турыдан-туры туфраклы чүлмәккә утырталар.

Бу эшнең кечкенә генә серләре бар. Туфракка утыртканчы, тармакның баш-башлары кипшерергә тиеш. Шуңа аны ике сәгатькә өстәлдә калдырып торабыз. Яфраклары сулып китсә дә, куркыныч түгел.

Яран гөле бик зур, иркен савытларны өнәми. Һәм тагын бер бик мөһим кагыйдә: ул чүлмәк төбенә су җыелып торганны бер дә яратмый. Артык су тәлинкәгә агып чыксын өчен, чүлмәкнең тишекләре кечкенә булмасын.

Чүлмәк төбенә дренаж салып калдырыла. Дренаж өчен керамзит бөртекләре, чуерташ, кирпеч ватыгы, вакланган кокос кабыгы кулланыла. Аннары инде чүлмәккә туфрак салына.

Туфракның гөлләр өчен махсус әзерләнгәнен сатып алсаң

БЕЛӘСЕЗ МИКӘН

- Пеларгония (яранның икенче төрле атамасы) кояшлы урынны ярата, әмма җәй челләсендә тәрәзә төбендәге яраннарны бераз күләгәләргә кирәк.
- Ул корылыктан түгел, артык дымнан курка. Яранның яфраклары су тидергәнне яратмый.
- Яран үскән йортның микроклиматы уңай була. Ул өйдәге авыр исләрне бетерә. Яранлы йортта көя күбәләге булмый икән.
- Әгәр дә кайнатма өстенә яран яфраклары салсаң, күгәрми.
- Алсу яран өйгә мәхәббәтне җәлеп итә, имеш.

Яранны тармактан гына түгел, орлыктан да үстерергә була. Моны хәзер – февральдә эшләсәң яхшы. Төрле кеше төрле ысул куллана. Орлыклар тизрәк тишелсен өчен, кемдер аларны наждак кәгазе белән җиңелчә генә ышкып, кабыгын юкарта. Кемдер юеш чүпрәккә төреп, ике-өч көн бөрттерә.

әйбәтрәк. Розалар өчен әзерләнгән туфракта да яхшы үсә яран. Әгәр дә туфракны үзегез әзерлисе булсагыз, 8 өлеш кәсле туфракка 2 өлеш черемә, 1 өлеш ком кушарга кирәк. Шулай ук 1 стакан чамасы көл дә салына. Иң мөһиме: туфрак көпшәк булырга тиеш.

Туфракка фитоспорин порошогы салынган җылымса су сибеп, йогышсызландырабыз. Чүлмәккә утыртыр алдыннан гөл тармагының аскы очын «Корневин»ише тамырландыргыч порошокка тыгып алабыз. Ул ботак очына ягылыр-ягылмас дәрәҗәдә аз булырга тиеш. Чүлмәк уртасына карандаш белән чокыр ясап, ботакны туфракка батырабыз. Кул белән тыгызлыйбыз. Тагын бер кат җылы су сибәргә була (суга чәчәк атучы гөлләргә сибә торган ашлама кушсаң яхшы). Су сеңгәч, өскә аз гына коры туфрак салабыз.

Гөлнең кискәннән калган тамыр өлешен дә яңа туфракка күчереп утыртабыз. Яраннарның үсә-үсә аскы ягы шәрәләнүчән. Моны бик җайлы гына төзәтеп була. Элеккеге яфрак урыны өстеннән үткен пәке белән кәүсәдә бик тирән булмаган кисем ясыйбыз. Тиздән бу бөреләрдән яңа тармаклар үсеп чыгар.

Яранны купшырак итү өчен бишалты яфрактан соң сабакның очын чеметеп алырга кирәк. Шуннан соң ул буйга үсүдән туктап, ян тармаклар чыгара. Ян тармакларда чәчәкләр күбрәк була.

Бүлмәдә һава артык коры булмаса, чүлмәкне ачык килеш кенә дә калдырырга ярый. Ә инде эссе һәм коры икән, өстеннән полиэтилен кап кидереп, кап авызын скотч белән чүлмәккә ябыштырып куябыз.

Яранны матур чәчәкләре өчен генә яратасызмы? Аның файдалы үзлекләрен дә белә идегезме?

- Башыгыз ярылыр чиккә җитеп авыртканда, ике чигәгезгә яран яфрагы куеп карагыз әле. Кайберәүләр яфракны бөтәрләп, колакка тыгып куйганнан шифа күрәбез, диләр.

- Ике зур яфракны 1 стакан салкын суда төнәтеп, шунда чылаткан мамыкны чигәгә кысып бәйләп кую да булыша. Икешәр тамчы төнәтмәне борынга тамызырга да була. Алай иткәндә, сызлау тагын да тизрәк басыла.

- Тешегез сызласа да, уртыгызга яран яфрагы куеп торыгыз. Тешнең эмале бозылып, тишек барлыкка килгән булса, шунда бер-ике тамчы яран мае тамызыгыз.

ЯҢА ТӨР ЯРАННАР



Роза чәчәкле яран
Катлы-катлы таҗ яфракларыннан оешкан вак-вак чәчәкләр бер тармакка берегеп, нәкъ бәләкәй роза гөлләмәсен хәтерләтә. Яранның бу төре инде күптән билгеле булса да, бездә аны сирәк кешедә генә очратасың. Бик иркә гөл. Яктыга һәм тәрбиягә мохтаҗ, гел кисеп торырга кирәк.



Асылмалы яран (ампельная төре)
Талымсызлыгы, тиз үсүе, җәй дәвамында чәчәк атып утыруы белән кыйммәтле ул. Яранның бу төре җәен кашпога утыртып, биегрәк җиргә элеп кую, вазонга, тәрәзәнең тышкы ягына беркетелгән чүлмәкләргә утырту өчен бик матур. Кышын өч айлык ялга мохтаҗ.



Лалә чәчәкле яран
Бергә тупланган вак чәчәкләре ачылып килүче лаләгә охшаш. Чәчәген атып бетергәндә дә таҗ яфраклары тулысынча ачылып бетми. Лалә чәчәкле яранның төрле төстәгеләре була. Үстерүенең кыенлыгы шунда: тармактан үрчеткәндә, сорт үзлекләре сакланмаска да мөмкин.



Хан яраны (королевская төре)
Башка төрләрдән аеруча купшылыгы белән аерылып тора. Куагы буйга артык үсми, сабагы шәрәләнми. Әмма тәрбиягә бик талымлы. Купшы чәчәкләре белән дә артык озак сөендерми ул, тиз атып бетерә. Ачык һавада үсүне яратмый, тармактан үрчетүе кыен.

Фото: www.pixabay

PRESSA.RU

Җир шарының гомерлек юлдашы булган айның бар тереклеккә тәэсир итүен кешелек инде күптән белә. Планетабыздагы диңгез-океаннар да, елга-күлләр дә, хәтта агач-үләннәрнең тамырлары буйлап яккан яшәү суты да ай ритмына буйсына. Үзебез сизмәстән, безнең организм да ай ритмына көйләнеп эш итә. Ай урагының үсүгә таба барган мәлендә аның энергиясе өскә, югарыга әйди, тизрәк үсәргә этәрә. Ә ай кими барганда, киресенчә, энергия аска таба омтыла. Тәҗрибәле бакчачылар ай энергиясенең шушы тәэсирен истә тотып, орлыкларны чәчү, үсемлекләрне күчереп утырту, кисү-сирәкләү кебек эшләр өчен кулай чакны сайлый.


Фото: www.pixabay

ҺӘР ЭШНЕҢ ҮЗ КӨНЕ

Үсемлекләр	**февраль** (16 – яңа ай)	**март** (2 – тулы ай, 17 – яңа ай)	**апрель** (16 – яңа ай, 30 – тулы ай)	**май** (15 – яңа ай, 29 – тулы ай)	**июнь** (13 – яңа ай, 28 – тулы ай)
Баклажан, борыч, помидор	23–26	24–25, 28–30	25–29	23–28	20–26
Башлы суган	2–6	3–8	1–7	1–5, 30–31	1, 29–30
Бәрәңге	4–6, 7–12	6–8, 8–11	5–7, 12–14	2–5, 10–13	1, 6–11, 29–30
Борчак, фасоль	23–26	24–25, 28–30	25–29	23–28	20–26
Кабак, ташкабак, карбыз, кавын	17–22, 23–26	19–23, 24–25, 28–30	18–21, 25–29	17–19, 23–28	15–19, 20–26
Кәбестә	17–22	19–23	18–21	17–19	15–19
Кишер, чөгендер	2–6, 7–12	3–8	1–7	1–5, 30–31	1, 29–30
Кыяклы суган, порей суганы	17–22, 23–26	19–23, 24–25, 28–30	18–21, 25–29	17–19, 23–28	15–19, 20–26
Кыяр	17–22	19–23	18–21	17–19	15–19
Редиска, ачы торма, шалкан	2–6	3–8	1–7	1–5, 30–31	1, 29–30
Салат, шпинат	17–22	19–23	18–21	17–19	15–19
Тамыр сельдерей, тамыр петрушка	7–12, 17–22	3–8	1–7	1–5, 30–31	1, 29–30
Яшел аш тәмләткечләре	17–22	19–23	25–29	17–19, 23–28	15–19, 20–26
Орлыктан үсүче чәчәкләр	17–22, 23–26	19–23, 24–25, 28–30	18–21, 28–29	17–19, 23–28	15–19, 20–26
Суганнан үсүче чәчәкләр	2–6	3–8	1–7	1–5, 30–31	1, 29–30


Кучкар. Уй-фикерләрегезне тагын бер кат анализларга туры килер. Гомумән алганда, ай уңышлы. Иң мөһиме: энергиягезне булмаган проблемаларны чишүгә сарыф итмәгез һәм хыялга бирелүдән сакланыгыз.


Үгезбозау. Айның беренче яртысы шактый ыгы-зыгылы, мәшәкатьле булыр. Шул ук вакытта көч-куәтегезнең дә артуын тоярсыз. Үз максатыгызга ирешү өчен зур көч куярга туры килер. Тырышлыкның нәтиҗәсе дә озак көттермәс.


Игезәкләр. Нинди генә эшкә алынсагыз да, тиз һәм җиңел хәл итәрсез. Креатив һәм оригиналь идеяләргә чумарсыз. Әгәр дә аларны тормышка ашырсагыз, финанс ягыгыз шактый ныгыр. Айның беренче яртысында күңелле вакыйгалар көтелә.


Кысла. Хәл итәсе мәсьәләләр шактый. Уңышка ирешү түземлегегезгә бәйле. Кыенлыклардан курыкмагыз. Март аенда планеталарның тезелеше сезнең файдага, барысын да көткәннән дә яхшырак итеп башкарырсыз.


Арыслан. Таулар күчерерлек тәвәккәллек сездә. Нәкъ менә шушы сыйфатыгыз куйган максатларга җиңел генә ирешергә булышачак та. Планеталарның уңышлы тезелүе яңа эшләргә әйдәр.


Сөмбелә. Күп мөмкинлекләр, һөнәри үсеш белән каршы алырсыз бу айны. Хыялларыгызны, ниятләрегезне чын итәр форсат чыгар. Бу ай яңа эшкә өйрәнү, яңа белем үзләштерү өчен дә яхшы вакыт. Күңел сизгерлегегез гаҗәеп.


Бизмән. Тормышыгызга тынычлык һәм гармония хуҗа. Айның беренче яртысында яхшы хәбәр алырсыз. Бу исә күңел күтәренкелеге, көч өстәр. Финанс ягы да куандырыр, күптән хыялланып йөргән берәр әйбер сатып алу ихтималы зур.


Чаян. Гадәти мәшәкатьләр белән мәшгуль булырсыз. Яңа эшләр көтелми. Алай да күптәнге танышыгыз яки туганыгыз белән күрешү ихтималы бар. Иҗат эшчәнлеге белән шөгыльләнүчеләргә бераз ял итеп алырга кирәк. Алдан план корып яши белүегез финанс ягыгызны җайларга бик булышачак.


Укчы. Тормышның кискен борылышларына әзер торыгыз. Үзегезне басып торган җаваплылыктан, сезне файдаланырга гына торучы танышлардан арынырсыз. Сезнең өчен тормышның яңа этабы башлана.


Кәҗәмөгез. Бәхет йолдызыгыз кабынган ай бу. Нинди эшкә алынсагыз да, илаһи көчнең ярдәмен тоярсыз. Моңарчы тотынырга куркып торган теләсә кайсы мәсьәләне кузгата аласыз, бар да җиңел хәл ителер.


Сукояр. Кызык вакыйгаларга бай булып истә калыр бу ай. Сезне алыштырып куйганнар диярсең, күңел күтәренкелеге, тырышлык бөтереп алыр. Бәхетегезгә таба беренче адым ясаганыгызны үзегез тоясыз микән? Моңарчы йоклап яткан сәләтегез уяныр.


Балык. Тормышыгызны җайлау белән мәшгуль булырсыз. Яңа эшкә урнашу ихтималы бар. Планеталарның торышы сезнең өчен бик уңышлы. Кәефегез дә яхшы булыр, сәламәтлегегез дә. Ай башында җитди сынаулар, зур мәшәкатьләр көтелми.

Февраль дә кабынган йолдызлар

Татарстан



Гөлзадә Бәйрәмова (26.02.1963) – **шагыйрә, публицист-язучы, язучыларның С. Сөләйманова исемендәге кызыксындыру премиясе лауреаты.**

Татарстанның Саба районы Сабай авылында туып-үсә. 1980 елда Олы Шыңар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының журналистика факультетында белем ала. Мәктәптә укыган елларында ук шигырьләре, кыска язмалары район һәм республика газеталарында басыла. 1989 елдан бүгенге көнгәчә «Казан утлары» журналында эшли. 2007 елдан – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. 2006 елда «Әле кайчан гына...» дип аталган беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга. 2013 елда чәчмә әсәрләре һәм әдәби-публицистик язмалары тупланган «Син һаман шул сандугач» китабы, «Дөнья шигырь яздыра» шигъри җыентыгы дөнья күрә.

Россия



Любовь Толкалина (16.02.1978) – **театр һәм кино артисты.**

Рязань өлкәсенең Савватьма авылында туа. Кечкенәдән синхрон йөзү белән шөгыльләнә. Әле мәктәптә укыганда ук балалар театрына эшкә керә. Судагы театр була ул. 12 яшеннән төрле спектакльләрдә уйный, 16 яшендә синхрон йөзү буенча спорт мастеры исемен ала. Репетицияләрнең берсендә булачак артистны реклама режиссеры күреп алып, үзенә чакыра. Соңрак ВГИКка укырга керә – Алексей Баталовта укый. 1999 елда Россия Армиясе театрына эшкә урнаша. Тәүге тапкыр экраннарга «Затворник» фильмындагы кечкенә генә бер роль белән күренә. 2002 елда аны «Антикиллер» фильмына чакыралар. Фильмның икенче кисәгендә Толкалина инде төп рольне башкара. Үзе исә, тормышындагы төп вакыйга дип, «Я люблю тебя» фильмын атый.

Чит илләр



Силвия Пфайфер (24.02.1958) – **актриса, топ-модель.**

Бразилиянең көньягында, Атлантик океан яры буендагы шәһәрдә туа. 14 яшендә, мәктәпне дә тәмамламас борын, Рио-де-Жанейрога күчеп китә. Зифа буйлы чибәр кызга модель бизнесы белән шөгыльләнү өчен монда инде мөмкинлекләр күп була. Коко Шанель, Джорджио Армани, Кристиан Диор белән хезмәттәшлек итә. Алай да артист буласы килү теләге җиңә – актерлык курсларына языла. Кинога ул беренче тапкыр 1990 елда төшә. Без исә аны 1993 елда төшерелгән «Тропиканка» сериалы аша беләбез. Шулай ук Россиядә яратып каралган «Клон» фильмында Синира ролен башкаруы да мәгълүм.

Фото: phttp://djinjik.ru, http://ego.globo.com

PRESSA.RU





ИҖАТ ЮЛЫНДА – «АК БҮРЕ»

Бүредән курыксаң, урманга кермә. Марат әле бар мөмкинлекләре дә, мәшәкатьләре дә тиз генә аңлашылып та бетмәгән үзгәртеп кору елларында ук үз язмышында ирекле рәссам буларак юл салган кыю иҗатчы. Һәм ул – бу уңышлы иҗат юлында «Ак бүре»не сурәтләп күрсәтергә дә алынган, бик борынгы морзалар нәселеннән. Яушевлар – Россия империясендә үзләренең морзалыкларын беренче булып рәсми рәвештә раслаткан затлы нәсел. Марат Яушев исә әлеге нәселнең кыпчак тармагына карый. Билгеле булганча, кыпчак күчмә кабиләләре һәм башка төрки халыклар мәдәниятендә дә Ак бүре символы бар, ул – тотем да. Бик чыдам, түзем, хөр һәм батыр, үз-үзенә ышаныч булуны аңлатучы бу символны рәссам, әйтерсең лә, Патагония бозлыкларының бер кисәгеннән уйган! «Ак бүре» картинасы бик күп еллар элек язылган булса да – сәнгатьсөярләрнең күңелендә. Моңа охшаш һәм башка төр символларны барлык әсәрләрендә дә сурәтли бара Марат.


Ул – бик ябык, ягъни үз эченә бикләнгән диярлек, җитди рәссам, менә озак еллар инде яңа әсәрләре белән бары тик бик якын, үзенең иҗатын яраткан кешеләрне генә таныштыра килә. Җәмәгате Динә Яушева белән алар моннан берничә ел элек Иске Татар бистәсендәге Ф. Кәрим урамында урнашкан борынгы йортны, янгыннардан йолып, күп мәшәкатьләр аша узып, шәһәрдән сатып алдылар. Кайчан да булса биредә татар халкының узган гасырларда кулланылган көнкүреш әйберләре музееен һәм Марат Яушевның шәхси галереясын ачарга уйлыйлар. Бу көннәр җиткәч, рәссам да, ниһаять, үзенең «эчке эмиграция чоры»ннан чыгар. «Әлегә миңа шушы халәттә иҗат итү уңайлырак», – ди ул. Илһам чыганагы, чибәр ханым Динә Яушева аның бар эшләре буенча директор вазыйфаларын да башкара. Кайчандыр бар шәһәргә мәгълүм аяк киеме тегү остасы, туганнары кәүешче Кәрим (Садыйк Кәримов) яшәгән йортны, XIX гасыр архитектурасы һәйкәлен саклап калуда аның да өлеше зур. Остаханәнең ике каты да тарихи экспонатлар белән дә һәм рәссамның берсеннән-берсе матур әсәрләре белән дә тулы. Аларга сокланмыйча карау мөмкин түгел! Арадан «Чыгышлары белән безнең шәһәрдән» дип аталучы өр-яңа циклы үз эченә танылган, талантлы хатын-кыз образларын да шактый туплавы белән аерыла. Әлеге портретларны язганда рәссам, гадәттәгечә, нинди дә булса символларны да сурәтләмичә калмаган. Талантлы иҗат иясе үзенең фәлсәфи-хиссиятле кичерешләрен сынлы сәнгатьнең бар төр жанрлары аша да яза. Үз иҗат юлында реализм, сюрреализм, декоратив ысулдагы һәм фантастик реализмга караган картиналар да тудыручы бу татар рәссамының исеме бар цивилизацияле илләрдә дә мәгълүм. Эшләре дөньяның бөтен континентларына да таралган.

Марат Яушев үзе турында: «Мин – ялгыз инсан», – дип тә аңлатты, ләкин мин бу ялгызлыкның бары уңай якларын гына күрәм: татарның талантлы рәссамы Марат Яушев үз шәхси галереясын ачкач, моның шулай булуына башкалар да инанып һәм рәссам күңелендәге ирек хисе, әсәрләре аша, аларның да күңелләренә орынып, кайтаваз булып кабатланыр һәм үзе кебек эчке ялгызлык хисен татыган иҗат инсаннарын да юатыр әле!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА








«Софья Гобәйдуллина»

«Көмеш джаз»
«Борынгы савытлар»
«Соло»
«Пионнар»
«Балык»

МАРАТ ЯУШЕВ

PRESSA.RU



КОТЛЫЙБЫЗ!



Инесса СМОЛЯР, ҖЧҖ, «ТД «Керамик Центр» директорының беренче урынбасары



Эльмира ВАСИЛЬЕВА, Татар хатын-кызларының Пенза төбәкара «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы рәисе

Котлау сүзләрем Ватанны саклаучылар көнендә барлык ир-егетләргә барып ирешсен! Сез – көчле ихтыяр символы! Сез – Ватанны, гаиләне, хатын-кызларны яклаучылар һәм саклаучылар! Сез – безнең горурлык! Кайда да гел беренче, гел җиңүче булыгыз! Кылган игелекле гамәлләрегез, егетлегегез, зирәк акылыгыз, тәвәккәллегегез безне һәрчак сокландыра. Матур булып йөрүләребез, тәмле итеп пешерүләребез, ягымлы итеп сөйләшүләребез, сөйкемле елмаюларыбыз – барысы да сезнең өчен! Янәшәбездә сез булганда гына, дөньябыз ямьле, рәхәт!

Бәйрәм белән, егетләр!

23 февраль!.. Ул безгә балачактан таныш кадерле бәйрәм. Үзенә бер тантанага төренгән бу көн – егетлекне, батырлыкны зурлау көне ул. Ватанны саклаучылар көне дигән тирән мәгънә салынган аңарга. Сакаллы бабайлар да, чал чәчле агайлар да, армия мәктәбе узган ирләр дә, солдат формасы кигән егетләр дә, батыр булырга әзерләнеп үскән малайлар да бу көнне үзләренең чын-чынлап яклаучылар булуын тагын бер кат тояр. Белеп торыгыз, безгә – йомшак-нәзберек затларга – һәрдаим сезнең кайгырту, яклау, җылы сүз кирәк. Сез генә безне үстерә, канатландыра беләсез: уңышларга, җиңүләргә ирешүебезнең бөтен сере шунда. Сезнең янда гына без чәчәк кебек нәфис булып кала алабыз.

«Сөембикә» журналы – иң әйбәт бүләк
Язылу индексы: 73002 (РФ регионнарында), П2204 (Татарстан буенча)